www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 1 (1366) 14 гыйнвар 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga

2

Туку сәнгатенә багышланган симпозиум бу тармакта чишелмәгән мәсьәләләрнең күплеген анык күрсәтте.

12

Сынчы Салават Фидаи иҗатын бар матурлыгы белән бәяләү өчен, куәтле лупа кулланмыйча мөмкин түгел.


17

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле биючесе Айрат Заһидуллинга хәтта сынган аяк белән дә чыгыш ясарга туры килә.

Күңелләр дә акка алгысына, Тау шуганда аклык иркендә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Казах шагыйре Жакан Сыздыков тәрҗемәләреннән гыйбарәт «Габдулла Тукай. Тәндамалы шыгармалары» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы басылып чыкты.
- Татнетны үстерү фонды һәм Татарстан Язучылар берлеге оештырган XVIII «Әдәби марафон» 21 гыйнварга кадәр дәвам итә.
- Әлмәт театрының Камил Тукаев куйган «Җил артыннан» спектакле Россиянең кече шәһәр театрлары фестиваленең конкурс программасына керде.
- Казан дәүләт яшь тамашачы театрының «Сказки от бабушки Нины» дип аталган онлайн-проекты кысаларында Татарстанның халык артисты Нина Калаганова Казан авторларының әкиятләрен укый.
- Алабуга районының Морт авылы клубында балалар өчен оештырылган чыршы бәйрәмен Германия иҗтимагый телеканалы фильм өчен видеога төшерде.
- Анкара университеты аспиранты, Төркия телерадиокомпанияләренең югары советында эшләүче Әхмәт Акалын «Ак барслар илендә бүтән президент булмаячак» дигән мәкаләсендә Татарстанда президент атамасының бетерелүенә борчылу белдергән.
- Яшел Үзәннең Каратмән авылында «Нигъмәтҗан» мәчетенең 30 еллыгы уңаеннан мәдрәсә ачылды.
- Татарстан Милли музее виртуаль чынбарлык шлемы ярдәмендә 1910-1920 еллардагы Казан буйлап сәяхәт тәкъдим итә.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Илфат ФӘЙЗРАХМАНОВ, “Безнең гәҗит” газетасының баш мөхәррире:

“Татар журналистикасы мәктәбе авыр хәлдә. Мин телевидениедә баш редактор булып эшләгәндә ул кадрларны педагогика институтлары, филологлар хисабына да баеттык. Хәзер бу мөмкин түгел диярлек. Өстәвенә татар мәгарифе бүген татар телле балаларны тәрбияләми башлады. Русчасы шәп булган яшьләр русчага күчәргә тырыша. Ул мәгълүмат табу ягыннан җайлы, бик тиз танылырга мөмкинлек бирә, аудитория зур дип уйлаулар да бар”.

СЫНАМЫШЛАР

Искечә 1 гыйнварда (хәзер 14 гыйнвар) көн җылы булса – арыш уңар; җил дуласа – тары уңар; томан төшсә – солы уңар ● 20 гыйнварда җылы булса, кырда ашлык куе булыр; ябалак кар яуса, иген бик уңар ● Егермесендә көн салкын – уракта сугар ялкын ● Егермесендә бик салкын булса, урак вакытында бик эссе булыр; җылы булып, кар яуса – һәртөрле ашлык уңар; ябалак кар яуса – борчак белән чикләвек уңар.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 04 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 40 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 36 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты 23 минутка озынаячак һәм киләсе җомгада, ягъни **21 гыйнварда 7 сәгать 59 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

15 гыйнвар – театр рәссамы Габделәхәт Кадыйр улы Закировның тууына 80 ел (1942–2003).

16 гыйнвар – Актёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәрим Ибраһим улы Гыйльмановның тууына 110 ел (1912–1964).

20 гыйнвар – шагыйрь Галимҗан Шакирҗан улы Латыйповның тууына 110 ел (1912–1986);

– балет биючесе, мөгаллим, Г.Тукай ис. Дәүләт премиясе лауреаты бүләге Ревдар Фәез улы Садыйковның тууына 85 ел (1937-1989);

– Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фонды Химаячеләр советы рәисе, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә 85 яшь (1937).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Гыйнварның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(9-18 гыйнвар)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: 1**6 гыйнвардан 17 февральгә кадәр** ашказаны, ашказаны асты бизе, талак актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген җөмәдел ахир аеның 11 нче көне

АСЫЛЫБЫЗГА КАЙТЫП БАРЫШЛЫЙ

Төрки дөньяда туку сәнгате

Казанызның А.С.Пушкин исемендәге мәдәният үзәгендә туку сәнгатенә багышланган ике көнлек халыкара симпозиум үтте. Аны Татарстан Мәдәният министрлыгы ярдәме белән Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Тасвирый һәм гамәли бизәү сәнгатьләре бүлеге әзерләгән иде. Чара колачлы. Мәскәү, Санкт-Петербург, Ижау, Йошкар-Ола, Саранск, Сыктывкар, Уфа шәһәрләреннән, Әзәрбайҗан, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстаннан белгечләр килгән.

Мәдәният үзәгенә кергәч үк Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты һәм халык һөнәрчелеге техникумы әзерләгән күргәзмә башлана. Аннан туку станоклары тезелеп китә. Секция утырышлары арасында станокларда тукырга өйрәнү мөмкинлеге булды. Симпозиум кунаклары алып килгән келәм, тастымал, сөлгеләр һ.б. күрсәтеп куелган иде. Тамаша залында тукылган күлмәк, костюмнардан дефиле тезелгән. Эскәтер, сөлгеләр сандыкта гына ятмый, заманча киемнәр дә тукып була икән.

Симпозиумны ачарга мәдәният министры Ирада Әюпова килеп, чараның республикабызда үткәрелгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына очраклы гына туры килмәвен, орнаментлар, сөйләм теле кебек үк, бай тарихлы һәм тотрыклы булуын искәртте. ТӘһСИ исеменнән кунакларны директор урынбасары Олег Хисамов сәламләде. Сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова туку осталарына иң изге теләкләрен җиткерде, чөнки симпозиум Гүзәл ханымның этисе Идел буенда беренче сәнгать фәннәре докторы Фоат Вәлиевнең 100 еллыгына багышланды.

Чараның оештырылу дәрәҗәсенә караганда, бездә туку сәнгате югары үсеш алган булырга тиеш. Әмма хәлләр мактанырлык түгел. Сәнгать фәннәре доктор, ТӘһСИнең Тасвирый һәм гамәли бизәү сәнгатьләре бүлеге җитәкчесе Рауза Солтанова чыгышын тыңлаганда үкереп еларлык иде. Республикабызда туку сәнгатен өйрәнү, халыкка тарату белән шөгыльләнгән оешмалар бармак белән санарлык. 2003 елда оештырылган Халык һөнәрчелеген саклау, үстерү үзәген 2020 елда ябып куйдылар. Аның урынына Татарстан Мәдәният министрлыгы каршында оешкан Традицияләрне саклау һәм инновацияләр кертү үзәге хәзер бүтән сәнгать төрләре белән бергә тукучылыкны да торгызу өчен төрле чаралар күрә. ТӘһСИнең республикабыз районнарына оештырылган экспедицияләре һәм нәтиҗә буларак нәшер ителгән мәҗмугалар әйтеп бетергесез зур кыйммәткә ия. Әмма тукучылык өйрәтелгән уку йортлары да бик аз. Халык һөнәрчелеге техникумы һәм Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында тукырга өйрәтсәләр дә, эш тәртипкә салынмаган. 2012 елда мәктәпләрдән беренче буларак Казаныбызның 7 нче гимназиясендә тукучылык музее ачылган. Әмма оештыручысы һәм җитәкчесе Ирина Ивановна Зайцева үлеп киткәч, ул музейның эше ни дәрәҗәдә алып барылуы билгесез. Лениногорскида рәссам Мәснәви Хәйретдинов исемендәге рәсем мәктәбендә чигү, туку, батик һәм курчак сәнгатьләрен үз эченә алган биш еллык программа тормышка ашырылып килә. Мәктәпне тәмамлап, осталыкларын арттырырга теләүчеләр өчен Лениногорск педагогика көллиятенең гамәли бизәү бүлегендә гобелен сәнгате буенча 30 сәгатьлек программа бар.

Казан рәсем сәнгате училищесында 2002 елда күн сәнгате бүлеген оештырган кебек, нигә туку бүлеген дә гамәлгә куймаска? Дөрес, шул вакыттан бирле укып чыккан биш төркем күнчеләрдән берсен дә, көпә-көндез шәм кабызып эзләсәң дә, таба торган түгел. Өстәвенә, балалар бакчасыннан башлап югары уку йортларына кадәр туку сәнгате даими өйрәтелмәсә, без аны барыбер торгыза алмаячакбыз.

Туку буенча республикада төп берләшмә Алексеевски фабрикасының хәле дә мактанырлык түгел. Бүген анда нибары җиде тукучы калган. Иң яшенә – 39, иң олысына 56 яшь. Җиде миллионлы татарга – җиде профессиональ тукучы. Ни аяныч, осталарның берсен дә исемләп белмибез. Республикабызда, ил буенча орден, медальләрне артист, җырчы, спортсменнарга гына бирәләр. Берәр келәм тукучыга, бизәк чигүченең түшенә орден-медаль такканнары бармы? Шулай булгач, этсә бишенче аяк артык булган кебек, кул осталарыбызның да хөкүмәткә хаҗәтләре юк дигән фикер туа.

Туган илләренә 1980 еллар ахырында гына кайтып егылган Кырым татарлары да тукучылык эшендә безне узып киткән. Украинаның атказанган рәссамы, кул остасы Мамут Юсыф улы Чурлу, мәсәлән, Кырымда келәм сәнгатен ничек торгызганы турында бәян итте. 1944 елда илләреннән Урта Азия, Урал якларына куылгач, халык һөнәрчелеге юкка чыкса да, кызлар бирнәсендә мөһим урын биләгән келәм сәнгате саклана. Башта Үзбәкстанның Әндиҗан өлкәсе Палванташ авылына экспедициягә барып Кырым келәмнәре тукучыларны барлыйлар. Кырымга кайткач исә Судак районы авылларына келәм эзләреннән икенче сәфәр оештырыла. Шуннан соң бер ел үткәч COUNTERPART Америка донор фонды ярдәме белән келәм сәнгатен торгызу мөмкинлеге туа. Арендаланган мәйданнарга станоклар куеп, Кырымның төрле районнарыннан алтмыш хатын-кызны келәм тукырга өйрәтәләр. Фонд өч шарт куя – келәмнәр тарихи технологияләр буенча, борынгы орнаментларны файдаланып, табигый материаллардан гына тукылган булырга тиеш. Нәтиҗәдә, тукучылардан Шәфыйка Баймәмбәтова ярты ел эчендә 24 квадрат метр зурлыктагы һәм бер-берсен кабатламый торган 240 төр төсле композицияләрдән гыйбарәт келәм тукый. Кырымда фонд финанслаган программа буенча күпләгән күргәзмәләр оештырыла. Бүген Россия белән Украина Кырым өчен җан талашса да, чынлыкта Кырым халкы, аның сәнгате, мәдәнияте аларның берсенә дә кирәк түгел, берсенең дә беркайчан тырнак очы кадәр дә ярдәм күрсәткәннәре юк. Америка фондының да ярдәме озакка бармый – 1996 елда финанслау туктагач, алтмыш тукучыдан нибары унысы кала. Тагын сигезе кияүгә чыккач, Шәфыйка Баймәмбәтова һәм Нияра Решатова гына келәмнәр тукуын дәвам итә. 2007 елда күзләренә көч килеп, алар да тукучылыкны ташларга мәҗбүр була. Бүген аларның эшен Сабрие Әюпова дәвам итә. Мамут Чурлуның сүзләренә караганда, иң авыры – әзер продукцияне сату. Бу максатта күпләгән күргәзмәләрдә катнашалар, заманга яраклашып, мендәрләр, зур булмаган янчыклар, башлыклар тукыйлар. Интернетны аркылыга-буйга йөреп чыгалар. Эшмәкәрләрне эшкә җигәләр. Хәзер Кырымда гына түгел, Германиядә дә келәм сату кибетләре бар. Берочтан Германиядән буяу нечкәлекләренә өйрәнәләр, әйтик, элегрәк келәмнәрне Кырымда үскән үсемлекләрне файдаланып, җылы төсле буяуларга гына буйый торган булсалар, Германиядән салкын төсләр барлыкка китерү серләренә төшенәләр. Мамут Чурлу Татарстанга буяу серләренә өйрәткән лазер тәлинкәләр, бөтен технологияләрне генә түгел, бизәк мәгънәләрен дә өйрәтеп, үзе чыгарган китаплар алып килгән. Тукылган эшләнмәләрне сатуда бизәкләрнең асыл мәгънәләре онытылуы да кыенлык китереп чыгара, диде ул.

Әгәр дә орнаментларның нәселне дәвам итүгә ярдәм иткәннәрен һәм явыз көчләрдән саклаганнарын искә төшерсәк, келәмнәрне сатып алучылар да күбрәк булыр иде, дип сыкрана. “Эшебезнең төп нигезләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт, – дип таныштырды рәссам, – тукучы хатын-кызга җайлы булсын өчен станокны өендә урнаштырабыз, җепләрне үзебез китереп торабыз һәм эшне тәмамлауга ук Америка доллары белән хезмәт хакы түлибез. Келәмнең бер квадрат метры 50 доллар тора”.

(Дәвамы 5 нче биттә).

МИЛЛӘТАРА КАРШЫЛЫКНЫ КЕМ КУЕРТА?

Яңа, 2022 елга аяк бастык. Кызганыч, Татарстанда бәйрәм рухы Мәскәүдә республиканың хокукларын чикләгән законнар кабул ителүе, аисә пандемиягә бәйле чикләүләр белән генә түгел, ә Актанышта урын алган күңелсез вакыйга тирәсендә купкан җәнҗалга бәйле рәвештә дә сүрелде. Сүз бу очракта Чаллыда бакыйлыкка күчкән нәсара динендәге рус кешесенең җәсәден, Актанышка илтеп, зиратның мөселманнар ягына җирләү һәм аның каберенә куелган тәресен билгесез вандаллар кисеп алуы турында бара. Әлбәттә, саф татар районында булган, әмма татар рухына бөтенләй ят мондый вәхшилек, ислам динендәгеләргә генә түгел, милләтебезгә тулаем да тап төшерә. Шул ук вакытта, Ставрополь краенда туган һәм Чаллыда яшәгән кешенең җәсәде 130 км ераклыктагы татар районында җирләнүе, моңа бәйле һәм мантыйкка сыймый торган кайбер башка гамәлләр, шулай ук әлеге вакыйганың бериш мәгълүмат чаралары ярдәмендә Россия күләмендә дә яңгыраш алуы кемдер тарафыннан яхшылап әзерләнгән провокациягә дә хәтерләтә. Аның төп башкаручысы И.Грегоржевская (мәрхүмнең балдызы) Актанышта мондый хәл килеп чыгуында район башлыгы Э.Фәттаховны гаепли, аның министр чагындагы тел сәясәтен искә төшерә һәм бу очракта да шәхсән ул җавап тотарга тиеш, дип саный. Районның рус милли-мәдәни җәмгыяте җитәкчесе исә Актанышта беркем дә русларны рәнҗетмәве, район халкын һәм аның башлыгын милләтчелектә гаепләү нигезсез булуы турында әйтә.

Ә татарга каршы провокацияләр колачлы һәм дәвамлы булып чыкты. Янә бер әшем иясе, төбәк опера театрларында спектакльләр куеп кәсеп итә торган опера режиссеры, М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында куйган «Шагыйрь мәхәббәте» операсы өчен хәтта Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге алган М.Панджавидзе, шундый ук мәкерле ният белән, О.Юхновская атлы кемсә Актаныштагы вакыйга турында «Фейсбук» битенә куйган сылтама астына татарлар турында үзенең шәрехләрен урнаштырган. Анынча, мәктәпләрдә үз телләренә өйрәнү мөмкин булмагач, татарлар аны өйләрендә өйрәнә икән дә, әле җитмәсә (ah, син аларны!), үзара да татарча гына сөйләшәләр икән. Моны ул аларның толерантсызлыгы белән аңлата. Русчалары да көннән-көн начарая бара, имеш, һәм ул инде алар өчен туган тел булмый да башлаган. Бу исә татарның сепаратизмга омтылу билгесе дә булып тора икән... Менә бит нинди хәлләр! Ә режиссер-провокатор кармагына бу юлы Бөтендөнья татар яшьләре форумы (БДТЯФ) да эләккән. Анда аның, Тукай бүләге лауреаты исемен йөртергә лаек булмавын дәлилләп, Татарстан Президенты Р.Миңнеханов һәм мәдәният министры И.Әюпова исеменә ачык хат юллаганнар.

Хәлбуки, әлеге провокацияләрне хәтәр кавемнең татар-рус мөнәсәбәтләрен катлауландыруга исәпләнгән мәкерле сәясәте дәвамы, дип карарга кирәктер. Чөнки аның илдә татар телен чикләү һәм милли мәгариф системасын җимерү буенча русларны кулланып кылган мәкерле гамәлләре дә, элеккеге мәдәният министры В.Мединскийның, тарихи чынбарлыкны бозып, татарга яла ягарга омтылган опусы да, ул гына түгел, хәтта татар хатын-кызының әхлагын вә рух ныклыгын бозып күрсәтү ниятендә, төрле телләрдә һәм зур тираж белән чыгарылган провокацион «роман» һәм аның буенча куелган «сериал» да, татарга хас гадәттән тыш сабырлык нәтиҗәсендә, мәгълүм кавем көткән нәтиҗәне бирмәде: татар-рус мөнәсәбәтләре, зурдан алганда, какшамады. Ә Россия тарихында төп урын биләгән бу ике халыкның алдынгы карашлы өлешләре мондый шартларда аңа лаеклы җавапны уртак максат тирәсендә берләшеп кенә бирә ала. Бу җәһәттән, илдәге барлык дин вә милләтләр арасында гармониягә ирешүне максат иткән «Рухи вә милли бердәмлек хәрәкәте»нә (РМБХ) ихтыяҗ зур булуы тагын бер кат раслана. Асылы белән ул тәүге метасәяси (илаһи яшәешкә күчү сәясәтен аңлаткан) проект та булып тора («МҖ», 16.04.21, «Бәрәкәтле хәрәкәт»). Әйтик, шул ук БДТЯФ иҗтимагый берләшмәсенең бу проектка кушылуы аның үз эшчәнлеген дә күпкә нәтиҗәлерәк итә алыр иде. Иң мөһиме - моның өчен бернинди киртәләр дә юк, өстәмә чыгымнар да кирәк түгел. Хәрәкәтнең киңәюе исә тормышта актив булу, мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә, үз төркемнәрен булдырып, максатчан эш итү аша теләктәшләр туплау белән генә билгеләнә.

Фоат УРАЗАЙ.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм актив иҗтимагый хезмәте өчен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе акционер җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Вәлиев Разил Исмәгыйль улы** «Дуслык» ордены белән бүләкләнде.

Күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен, шагыйрь **Гатауллин (Гаташ) Рәдиф Кәшфулла улы** «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнде.

Татар китаплары – төрек укучысына

Төркиядә татар әдәбияты классигы Әмирхан Еникинең хикәяләре төрекчә китап буларак дөнья күрде. Аны Бартын университетының яшь төрек галиме Альп Әрән Дәмиркая тәрҗемә итеп бастырган.

Китап «Онытылмас минутлар» дип исемләнгән. Анда татар әдибенең адәм баласындагы психологик халәтне сурәтләгән «Җиз кыңгырау», «Шаяру», «Яшьлек хатасы», «Фәридун белән Фирая», «Бабайлар», «Әҗәл дигәнең» һ.б. хикәяләре урын алган.

«Бу китап өчен Еникинең мәхәббәт, көнчелек, ялгызлык, үкенү, сагыну, курку кебек темаларга караган хикәяләрен сайладым. Аларда мәхәббәтнең төрле чагылышларын, хакыйкать артына яшеренгән ялгышны күрүдән барлыкка килгән күңел кайту халәтен күрергә мөмкин. Бу әсәрләр диалогларга яшерелгән мең төрле сораулар аша комсызлыкның, дошманлыкның нинди буш һәм мәгънәсез әйберләр булуы турында уйландырта», – ди тәрҗемәче.

Альп Әрән Дәмиркая кереш сүз өлешендә Әмирхан Еникинең тормышы һәм иҗаты белән таныштырган. Ул әлеге китабын, татар әдәбиятының нечкәлекләрен һәм байлыгын күрсәткән укытучым дип, остазы галимә Дания Заһидуллинага багышлаган.

Шушы көннәрдә Марат Кәбировның фантастик романы да төрекчә китап буларак дөнья күрде. «Убырлар уянган чак» дип аталган әсәрне дә Альп Әрән Дәмиркая тәрҗемә итеп бастырган.

Төрекчә «Вампирлар уянганда» дип исемләнгән әсәр «Парадигма академи» нәшриятында басылган.

«Төркиядә төрек язучылары нигәдер фантастика әсәрләр язарга алынмый, бу төр романнар безгә Көнбатыш әдәбиятыннан килә. Минем төрек укучыларын бу жанр буенча бер төрки язучының әсәре белән таныштырасым килде», – ди Альп Әрән.

Рушания АЛТАЙ.

Яңа театрлар берлеге

Карелиянең Петрозаводск каласында Милли театрлар ассоциациясенең беренче зур җыелышы узды. Гамәлгә кую конференциясендә Россия Федерациясенең төрле республикаларыннан 31 театры вәкиле катнашты. Алар арасында – Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев, Әлмәт театрының директоры Фәридә Исмәгыйлева, Буа театры директоры Раил Садриев, Кариев театры директоры Луиза Янсуар бар. Татарстан делегациясе составында утырышка мәдәният министры Ирада Әюпова да барды.

Ассоциация төзү инициативасы белән 2019 елда үзен Россиянең беренче милли театры дип таныткан Александр театры чыккан иде.

Яңа оештырылган Милли театрлар ассоциациясенең беренче чаралары июнь аенда Казанда «Нәүрүз» төрки театрлар фестиваль-форумы кысаларында узачак.

«Бу бик җитди форум. Без анда үзебезнең җәйге программа оештырачакбыз. Театрның әдәби бүлек мөдирләре, әдәби менеджерлар, продюсерларны укытачакбыз», – диде Милли театрлар ассоциациясе советы рәисе, Санкт-Петербургның Александр театры сәнгать җитәкчесе Валерий Фокин оешманың гамәлгә куелу конференциясендә.

Утырышта Милли театрлар ассоциациясенең Советы да сайланды. Әлеге Советта Казаннан Фәрит Бикчәнтәев, Башкорт драма театры директоры Иршат Фәйзуллин, Чечен дәүләт театры сәнгать җитәкчесе Һава Әхмәтова, Карелия Милли театры директоры Ирина Шумская һ.б. бар.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Очрашулар дәвам итә

Еллар алмашынган көннәрдә Казандагы «Аксу» студиясендә Мәскәү татарлары штабының узган елгы эшчәнлегенә багышланган матбугат очрашуы булып узды. Журналистларны Штабта алып барылган эшләр белән аның җитәкчесе Рөстәм Ямалеев таныштырды.

Узган ел һәркайсыбызның хәтеренә Халык санын алу кампаниясе уздырылуы белән кереп калды. Бу уңайдан Мәскәү татарлары штабы да шактый мактаулы эшләр башкарды. Әйтик, милләтебезне күтәрү, телебезне саклау, халкыбызның асыл егет-кызларын башка халыкларга күрсәтүдә Штаб әзерләп чыгарган «Үз җиремдә – үз телем» дигән китап аеруча әһәмиятвә ия. Галимнәребезнең, язучыларыбызның, күренекле затларыбызның татарлар турында әйткән фикерләрен туплап нәшер ителгән китап теләсә кемнең өстәл әсбабы булырлык. 10000 тираж белән дөнья күргән басма иҗтимагый оешмаларга, уку йортларына, китапханәләргә, мәчетләргә, мәктәпләргә бушлай таратылды. Штаб халык санын алуга әзерлек барышында Мәскәүдә һәм татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә халык белән күп кенә мәгърифәти кичәләр, җыеннар да үткәрде. Гомумән алганда, Штаб җитәкчелеге, 20 шәһәрдә булып, милләттәшләребез, активистлар белән очрашты. Ә инде Мәскәү татар штабы әзерләп чыгарган өстәл календаре мәгълүматлы булуы белән аерылып тора.

Штаб интернетта тагын да популярлашкан, YouTube-каналда аларга язылучылар саны 15 меңгә җиткән, инстаграмда 42 меңнән арткан. Бу инде милләттәшләребез турында Штаб төшергән 20ләп роликны бик күп кеше каравын да белдерә. Моннан тыш YouTube-каналда «Тел бел» дигән рубрика белән видео материаллар да куеп барыла. Штаб Россия төбәкләрендә нәшер ителгән газета-журналларны милләттәшләребезгә, мәчетләргә, мәктәпләргә, ветераннарга яздыруны да дәвам иткән. Быел 16 мең әбүнәче штаб яздырган матбугат белән танышып барачак.

«Башкарылган эшләрне күрүләре һәм бәяләүләре дә сөендерә», – диде Р.Ямалеев. Әйтик, Штаб эшчәнлеге быел Мәскәүнең һәм Татарстанның күп кенә оешмаларының бүләкләре һәм Рәхмәт хатлары белән бәяләнгән. Алар арасында Татарстан Диния нәзарәтенең Мактау грамотасы да бар.

Мәскәү татарлары штабы быел да милләттәшләребезне берләштерү, телебезне саклау юнәлешендәге эшчәнлеген дәвам итәчәк. Ниятләнгән проектлар арасында «Бөтендөнья татар конгрессының оештырылуына 30 ел тулу уңаеннан активистлар һәм оештыручылар белән 30 очрашу» дигән проект та бар. Аңлашыла ки, бу конгресснең өч дистә ел дәвамында алып барган гаять олы һәм киңкырлы эшчәнлеген күрсәтү дә булачак.

Сөембикә КАШАПОВА.

1 нче биттә – кышкы ял мизгеле. Фото: pxhere.com

Якты истәлеге онытылмый

Казанның Чехов урамындагы 53 нче йортта 1991-1995 елларда Татарстанның вице-президенты, ә 1995-1998 елларда Татарстан Дәүләт Советының Рәисе булган Василий Лихачевка мемориаль такта ачылды. Тантанада республиканың Дәүләт Киңәшчесе, Татарстанның беренче Президенты, РФ Хезмәт Герое Минтимер Шәймиев һәм Дәүләт Советының хәзерге Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

«Без барыбыз да республикабызның үсеше өчен көрәшәбез. Әмма Василий Лихачев бу планда үзенчәлекле, бик укымышлы кеше иде», – дип искә алды М.Шәймиев.

Гыйнвар салкынына карамастан, ачылыш тантанасына Татарстанның күп кенә дәүләт эшлеклеләре, В.Лихачевның хезмәттәшләре һәм туганнары җыелды.

«Без бик истәлекле вакыйга – Василий Лихачевның: зур дипломат, галим, җәмәгать эшлеклесе һәм үз иленә һәм Татарстанга тугрылыклы хезмәт иткән гражданинның туган көнендә җыелдык. Аннан башка республикабызның хәзерге тарихын күз алдына китерүе кыен, ул аның елъязмасы битләрендә якты эз калдырды. Ул эшчән, югары профессиональ һәм зыялы кеше иде. Аның уникаль сәяси биографиясе шуның турында сөйли», – дип билгеләп үтте Ф.Мөхәммәтшин.

Ул ассызыклап үткәнчә, Василий Лихачев Татарстанда парламентаризм үсешенә зур өлеш керткән, Дәүләт Советы формалашуның башында торган һәм аны республиканың сәяси тормышы катлаулы чорында җитәкләгән.

«Без бер төркемдә укыдык. Барыннан да бигрәк, аның беркайчан да үчле кеше булмавы хәтеремдә калды. Ул һәрвакыт, тыныч кына, үз фикерләрен ахырына кадәр җиткерде. Ул кыска, әмма бик төрле тормыш кичерде (В.Лихачев 2019 елда озак авырудан соң вафат булды). Һәм Аллага шөкер, аның истәлеге сакланып калды», – диде сәясәтченең хатыны Наилә Лихачева.

Яңа фотокүргәзмә

Казанның халык фотостудиясе ел саен яңа елны яңа күргәзмә белән башлый. 2022 елның беренче фотокүргәзмәсе белән танышырга Казанның танылган профессиональ фотографлары да килде.

«Казан» фотостудиясе инде алтмыш елга якын Дәрвишләр бистәсендә урнашкан Сәетгалиев исемендәге Мәдәният сарае карамагында эшли һәм фотография сәнгатен сөюче төрле яшьтәге, төрле һөнәр ияләрен берләштерә.

Фотостудиянең җитәкчесе, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының фотохәбәрчесе Солтан Исхаков яңа күргәзмәдә унбиштән артык авторның хезмәтләре куелганын хәбәр итте.

Һәвәскәр фотографларны күргәзмә белән Мәдәният сарае директоры урынбасары Рафис Фазылҗанов котлады. Шулай ук ул капиталь ремонт үткәрелгәннән соң бу бинада мәдәни чаралар оештырырга бөтен шартлар тудырылганын искәртте.

Фоторәссам Рифхәт Якупов бирелә Казанның профессиональ фотографлары күргәзмәләрен дә оештырырга тәкъдим итте. «Безнең шәхси архивларыбызда бик күп фотография саклана. Аларны халыкка күрсәтәсе килә. «Казан» халык фотостудиясенең күргәзмәләр оештырырга якты заллары бар, монда бик күп кеше килә. Фотография сәнгатен таныту өчен бергәләп эшлик», – дип мөрәҗәгать итте ул. Бу фикергә КФУ профессоры, фотограф Эдвард Хәкимов та кушылды.

Лилия ГАДЕЛШИНА.

Рәссам музее

Буа районының Черки-Килдураз авылында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган рәссам, монументалист Шамил Нигъмәтуллин музее ачылды. Ул авыл мәдәният йортының икенче катында урнашкан. Бирелә рәссамның шәхси әйберләреннән тыш, биш дистәгә якын картинасы урын алган.

Музей ачылышында Россия рәссамнар берлегенең Татарстандагы бүлекчәсен җитәкләүче Анатолий Крылов чыгыш ясады. Аның фикеренчә, Шамил Нигъмәтнең таланты авыл табигате тәэсирендә бөреләнгән. Шуңа да бер төркем кылкаләм осталары җәй көне Черки-Килдуразга кайтырга исәпли. Әлеге фикергә Татарстан рәссамнар берлеге рәисенең беренче урынбасары Мөдәррис Минһаҗев та кушылды.

Шамил Нигъмәтуллинның мәңгеләштерү эшендә якыннары – хатыны Рафидә Нигъмәтуллина һәм балаларының өлеше зур. Әлеге музей-бүлмәне ачарга ярдәм иткән өчен, алар җирле хакимияткә, Буа якташлык җәмгыятенә рәхмәтләрен җиткерде.

Юбилей елының тәүге җыены

Болгарда тантаналы рәвештә Россия-күләм мөселман җыены узды. Ул – Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысаларында тәүге чара. Шул рәвешле, форум Россия һәм Татарстанда әлеге зур тарихи датаны билгеләп үтүгә старт бирде. Татарстан мөфтияте тарафыннан оештырылган форум Әтил елгасында Россия мөселманнары корылтае рәвешендә үтә. Анда катнашу өчен Татарстан, Мәскәү, Ленинград һәм Свердловск өлкәләре, Кузбасс, Башкортстан, Мари Иле республикаларыннан һәм башка төбәкләрдән дин кардәшләр җыелды.

4 көнлек форумның эшендә күренекле экспертлар, галимнәр, атаклы вәгазьчеләр катнашты. Җыен Кемерово өлкәсе Югра шәһәреннән килгән Хөсәен Дарвозиевнең Коръән укуы белән башланды. Катнашучыларны әүвәл Болгар ислам академиясе ректоры вазифаларын башкаручы Айнур Тимерханов сәламләде. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үз чыгышында Нәзарәт тарафыннан башкарырга ниятләнгән проектлар белән таныштырды һәм тарихи датаның Россия мөселманнары өчен әһәмиятен аңлатып үтте. 1100 еллык кысаларында тормышка ашыру планлаштырыла торган проектлар арасында ул «Казан басмасы»н чыгаруны, рус телендә онлайн-мәдрәсәне, кульязма Коръән Мөсхафен, «Даруль-кутуб» электрон китапханәсен, «Ибне Фадлан» документаль-нәфис фильмын һ. б. атады.

Сүз уңаеннан, форум әлеге кинопроектның кыйнәйтелгән трейлерын күрсәтү өчен үзенчәлекле премьера мәйданчыгына да әверелде: бирелә тамашачылар өчен беренче тапкыр «Ибне Фадлан» фильмының тизеры күрсәтелде.

Россия ислам институты һәм Казан ислам университеты җитәкчесе Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин фәнни лекциясендә Россиядә ислам тарихы, ил территориясендә ислам дине таралуның яңа этабы булarak, җәдитчелек һәм кадимчелек карашларының татарлар арасында ислам үсешенә йогынтысы турында сөйләде. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Россия өммәте тормышында барган процессларны мисалга китереп, ул шушы елларны илебездә ислам дине тарихында чәчәк атучы этап булуын ассызыклады һәм хәзерге мөселманнарның үз проблемаларын хәл итү өчен эчке ресурслар эзләргә, игътибарны тышкы факторларга юнәлтү кирәкмәвен билгеләп үтте.

Форумның тагын бер кызыклы чарасы – татар батыры образын торгызучы «Туган батыр» милли проектын тәкъдим итү булды. Проектка консультатив ярдәм күрсәтүче шәхесләрнең берсе – озын корал һәм фехтование буенча белгеч Виктор Тарасов. Ул форумда катнашучыларга артефактлар ярдәмендә татар сугышчысының бимеханик хәрәкәт моделен торгызу мөмкин булуын, һәм үз мисалында шул хәрәкәтләрне ясап күрсәтте.

Форум кысаларында катнашучыларга осталык дәресләре, квестлар, тренинглар, спорт чаралары да тәкъдим ителде.

Эльмира СИРАҖИ.



● Gravity Industries компаниясе гендиректоры Ричард Браунинг Бөекбританиядәге күргәзмәдә солдатны «Тимер кешегә» әйләндерә торган шәхси очу аппаратын үзе сынап күрсәткән – беренче тапкыр һавага күтәрелгән һәм төшкән. Биш газ турбинасы белән җиһазландырылган футуристик костюм кешене 3,5 км биеклеккә күтәрә һәм сәгатенә 130 км тизлеккә бара ала. Баштарак Браунинг мондый оча торган костюмны күпләп җитештерергә җыенган булган, әмма бик кыйбатка төшкәнгә күрә, нияте барып чыкмаган.

● Канадада Cobionix компаниясе кеше катнашыннан башка вакцина ясарга сәләтле роботны тәкъдим иткән. Ул мускулга инъекцияне энәсез кадый – югары басым астындагы дару препаратын тиредәге диаметры чәч бөртегенекә кадәр генә булган тишеккә кертә. Сынауны уңышлы үтсә дә, күпләп җитештерү тагын ике елдан соң гына башланачак – өстәмә тикшерүләр һәм сертификатлаштыру узасы бар әле.

Төрки дөньяда туку сәнгате

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Шушы елның җәендә Г.Ибраһимов исемендәге институтның бүлек җитәкчесе Р.Солтанова Мәдәният министрлыгы ярдәме белән Татарстанның сәнгать мәктәпләрендә, югары уку йортларында укытучы һәм музейларда хезмәт итүче берничә остабызны Мамут Чурлу янына Кырымга алып барып, келәм туку серләренә өйрәнү мөмкинлеген тудырды. Осталарыбыз яңа һөнәр өйрәнүләреннән бик канәгать кайтты. Кырымнан соң тукылган келәмнәрен симпозиумдагы күргәзмәдә дә күрергә мөмкин иде.

Гомер бакый үз илебездә яшәгән без Идел буе татарларына илле елдан артык гомерен Урта Азиядә мөһаҗирлектә үткәргән Мамут Чурлудан китапларга басылган әзер технологияләрне кабул итеп алу сөенеч тә, көенеч тә. Йосыф улы торгызган келәм сәнгатен без 1990 елдан башлап утыз ел буена да кайтара алмавыбыз гарьлек түгелмени? Акчабызны "Үзгәреш җилләре"нә очыргач, тукучылыкка калмыйдыр шул. Безгә дә Америка фонды ярдәм итсә генә инде...

Әзәрбайҗан милли келәм музее директоры, сәнгать фәннәре докторы Ширин Яшәр кызы Меликованың сөйләгәнен тыңласаң, алар безнең галәмдә түгел, бик алга киткән бүтән бер галактикада яши кебек. Шуның бер билгесе – гамәли бизәү музейларыннан тыш аерым келәм музее булуы. Ул дөньяда иң беренче келәм музее булып 1967 елда ачыла. 2014 елда президентлары И.Алиевнең указы нигезендә Австрия архитекторы Франс Янс проекты буенча төзелгән өр-яңа бинага күчәләр. Биредә 10 меңнән артык экспонат саклана. Келәмнәрдән кала милли костюмнар, чигелгән бизәкләр, металл эшләнмәләр, зәркән әйберләре бар. Музейда бер бүлек борынгы келәмнәрне һәм электән килгән технологияләрне торгызу, техникаларга өйрәтү, иске экспонатларны кабатлап ясау белән мәшгуль. Биредә 5 рәссам, 13 туку остасы хезмәт куя. Беренче каттагы Әзәрбайҗан келәменең үсешен күрсәткән бүлектә дә бөтен келәмнәр диярлек музейда торгызылган. Келәм музееның үзенчәлеге – сукырлар өчен махсус программалар эшләнгән булу. Бөтен мәгълүмат, мәсәлән, Брайль шрифтына күчерелгән.

Карвәт техникасын торгызу исә боларга калку беленеп торган бизәкле келәмнәр тукып, сукырларга белем бирү эшен тагын да киңрәк җәелдерергә мөмкинлек биргән. Дөньяның матурлыгын күрү бәхетеннән мәхрүм булган һәркем музейдагы калку бизәкле унике келәмне тотып карый ала.

Бу гына аз тоелгач, Санкт-Петербург Эрмитажында сакланган дөньядагы иң борынгы, 2, 5 мең еллык тарих юлы кичкән Пазырык келәменең техникасына охшатып, төсләрен туры китереп, келәмнәр тукыганнар, бер өлеше – дәүләт Эрмитажында, тагын берничәсе үзләрендә саклана, ди. Шул рәвешле сукырлар Пазырык келәме белән дә таныша ала икән.

Безнең музейда исә борынгы әбиләребезнең күңел җылысын тоярга теләп, XX гасыр башы тастымалына кул сузсаң да, саклаучылар ата каз сыман ысылдап килеп җитә. Сукырга түгел, сау-сәламәт тамашачыларга да музей программасы бик чикле һәм заманнан артта калган дип уфтанырга гына кала.

Тагын бер проектлары – буялмаган келәмнәр тукудан гыйбарәт. Моның өчен ике ел дәвамында Әзәрбайҗанның төрле районнарында сарык йонының сыйфатын, төсен өйрәнеп йөргәннәр, ахыр чиктә үз төсендәге борынгы келәмнәргә иң туры килгәнне сайлап биш келәм тукыганнар.

Әзәрбайҗанда сарыкның бик кадерле булуын, йонын махсус лабораторияләрдә өйрәнүләрен белсәләр, безнең бөдрә башлы дүрт тояклы үз сарыкларыбыз көнләшеп йөрәкләре шартлап үләр иде, мөгаен. Пазырык келәмен тотып карау бәхетеннән мәхрүм мескен сукырларыбыз турында әйткән дә юк.

Сәнгать фәннәре докторы, Удмурт университеты доценты Елена Ковычеваның сөйләвенә караганда, Удмуртиядә шулай ук туку сәнгатен торгызу эше бик алга киткән. Алар безнең кебек йоклап ятмаган, 1991 елда ук туку эшен торгызу хәстәрен күрә башлаган. Моның өчен 23 һөнәр йорты оештырылган. Гамәли бизәү сәнгате һәм һөнәр үзәге аларның башында торган. Беренче эш итеп туку мәктәбен булдыралар. Һәм шуның өчен Россия хакимияте премиясе белән бүләкләнәләр. Бу аларга осталар санын – 150 гә, остаханәләрнекен 50 җиткерергә мөмкинлек бирә. Бер үк вакытта борынгылары үрнәгендә станоклар ясарга өйрәнәләр. Удмурт дәүләт университетында һәм мәдәният көллиятендә гамәли бизәү бүлекләре ачу, сәнгать һәм гомуми белем бирү мәктәпләрендә туку буенча факультативлар кертү, моның өчен методик ярдәмлекләр булдыру борынгы һөнәрне торгызырга нык ярдәм итә. Удмуртия осталары башларны әйләндерерлек уңышларга ирешә. «Буран әбиләре» ансамбле өчен яңа костюмнар тегәләр. Егерме дүрт туй костюмын торгызалар. «Удмуртия келәмнәре» проекты кысаларында борынгыларына охшатып һәм элекке технологияләрне кулланып егерме тугыз келәм тукыйлар.

Утыз ел дәвамында егерме өч һөнәр остаханәсе мәдәният оешмасы сыйфатында бюджеттан акча алган булса, моннан ике ел элек аларны үзфинанслауга күчерәләр, башларында торган гамәли бизәү һәм һөнәрләр үзәген исә Мәдәният министрлыгы канаты астыннан чыгарып, һөнәрчелекне туризм белән кавыштыру максатыннан, Икътисад министрлыгына бирәләр. Ковычева бу вакытларны исенә төшереп еламады гына. Утыз ел буе булдырган остаханәләр язмышы кыл өстендә кала. Байтагы ябыла. Осталар китә. Ярты еллап хакимият органнарына хат язганнан соң, ниһаять, быел остаханәләргә бюджет учреждениесе дәрәҗәләрен кире кайтаралар, әмма утыз процент финанслауны кисәләр һәм, акча елдан-ел кимеп, кабат үзфинанслауга кайтачаксыз дип, хакимияттә кисәтеп куялар. Боларны ишетеп, симпозиумдагы халык шатланыргамы, көенергәме белмәде...

Чаллыда «Стильные традиции» бизәкләп туку остаханәсен оештырган Наталья Уразгильдина чыгышы эчкә бераз җылы кертте. Бу ханым үзе остаханә ачу өстенә, даун һ.б. психик һәм физик авырулы балалар белән эшләүче һәм шул сәбәпле талчыккан мөгаллимнәрне туку эшенә тарткан. Күп санлы тикшеренү, тәҗрибәләр нәтиҗәсендә тукучылыкның кешене рухи сәламәтләндерү сыйфатына ия булуын, психикага уңай йогынты ясавын ачыклаган һәм бүгенге көндә дә бу юнәлештә эшен уңышлы дәвам итә.

Туку эшен торгызуның бер дигән ысулы бит бу! Россиядә, шул исәптән безнең республикада халыкның күпчелеге ике-өч эштә эшли-эшли, авырлык белән тормыш өстерәп, бик арыган, менә-менә сүнәргә торган шәм уты кебек, пыскып яшәргә мәҗбүр. Һәрбер оешма, предприятие каршында шушындый рухи тернәкләндерү үзәге ачып, халыкның күңелен күтәрсән, күтәренке рухлы кешеләр исә бу һөнәрне ошатып, чынлап торып тукый башласа, илебезнең туку һөнәрендә беренчелеккә чыгуын көт тә тор.

Җитди итеп фикер йөрткәндә исә, тукучылыкны торгызабыз дисәк, мондый симпозиумнарны ике елга бер булса да үткәрергә кирәк. Туку техника, технологияләрен матди булмаган мәдәни мирас исемлегендә рәсмиләштерү мәслихәт. Удмуртиядәге һөнәр йортлары үрнәгендә, остаханәләргә мәдәният оешмасы статусы биреп, бюджеттан финанслау сорала. Укыту стандартларына милли компонентны кертү, Әзәрбайҗандагы келәм музее шикелле гамәли бизәү музейлары, алар каршында остаханәләр һәм җитештерелгән продукцияне сату кибетләре ачу – иң беренче хәл ителәсе чаралар әнә шул.

Осталарыбыз эшләгән сәнгать әсәрләрен бәясен бермә-бер арттырып сатуга кайчанга кадәр юл куячакбыз? Туку, тегү, чигү, күн каючыларыбыз, иҗат әсәрләрен сата алмагач, мәктәпләрдә, югары уку йортларында укытып чиләнә, иҗатка хәлләре дә, вакытлары да калмый. Җилекләрен суыру, ятсызларча талауга бер чик куелырмы? Симпозиумда боларны резолюциягә теркәп, хакимият оешмаларына җиткерергә карар кылдылар. Хәерле сәгатьтә!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Шигърияттә Разил Вәлиев

Разил Вәлиев – безнең иҗтимагый-сәяси дөньябызда җигелеп эшли торган шәхесләребезнең берсе. Әмма ул, барыннан да элек – әдип, ягъни әдәбиятның төрле жанрларында үзенең осталыгын күрсәткән язучы. Прозада дисәң, мавыгып укыла торган повестьлары, драматургиядә, публицистикада актуаль яңгырашлы, үтә дә төзек телле әсәрләре аның киң колачлы һәм күпкырлы каләм остасы булуы турында сөйли. Мәгәр барыннан да мөһимрәге, ул – шагыйрь, шигъри сүз остасы.

Хәзерге эстрадабызда зур урын биләгән матур җырлар арасында аның җыр шигърияте үзенең эчтәлеге, тематик колачы, аһәңле яңгырашы белән үзенчәлекле дөнья хасил итә. Җыр иҗатында каләменең йөгерек осталыгы аның бөтен лирикасына колоритлы төсмерен бирә. «Шигырьләре җырлап тора!» дигән бәяне мин тел галимнәреннән күп тапкырлар ишетеп киләм.

Разил Вәлиев – шигърияткә алтмышынчы еллар шигъри дулкынында калкып чыккан шагыйрь. Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Рәшит Әхмәтҗан, Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмнәр исеме белән бәйле шигъри эзләнүләр контекстында гына аның иҗатын тулы аңларга мөмкин. Алар әдәбиятка диңгез шавы булып килеп керде. Евгений Евтушенко, Андрей Вознесенский, Белла Ахмадуллина кебек Мәскәү шагыйрьләренең торгынлык буасын ерып җибәрүе безнең әлеге талантлы йолдызлыкка куәтле этәргеч ясады. Разил, – Рәдиф Гаташ кебек үк, Мәскәү мәктәбен дә узган иҗатчы. Җыр шигъриятендә аның остазлары итеп Илһам Шакиров белән Лев Ошанинны күрсәтәләр. Бу чыннан да шулай. Җырларының эчтәлек һәм форма җәһәтеннән җитлеккән булуын татарның үз милли сәнгатьчелек традицияләреннән һәм русның профессиональ җыр мәктәбеннән тыш аңлап булмас иде. Разилне әле күздән кичереп узган куәтле төркем белән бәйли торган сыйфатлар нәрсәдә чагыла соң? Барыннан да элек, шигырьләрендә гәүдәләнгән эчке хөрлек хисе һәм рухи гайрәт дияр идем мин. Табигый ки, бу фактор аның күз күреме киңлегендә, еш кына галәми колачында, фикерләвенең масштаблыгында чагыла. Иҗатының башында ук ул үзенә максималистик бурыч йөкли. Һәм моның төп этәргече итеп халкындагы, нәселендәге игенчелек традициясен күрә.

Нәселемә мин хыянәт итмәм! –
Игенчеләр безнең ыруда.
...Буразналар ярып барсаң иде
Шигъриятнең олы кырында.
(«Игенчеләр нәселе»)

Шагыйрьнең үсеше, яңарышы, эзләнүләре сафташлары, замандашлары белән бергә бара. Ирекле шигырьләрне дә ул байтак яза. Табигый ки, аларны романтик рух күтәрә, шигырь итә. Шагыйрьлек миссиясен ул гадәттән тыш җаваплы итеп күрә:

Бер мизгелгә
уч төбенә куеп тордым
бу Җир шарын.
Әйе, әйе,
мин бер мизгел
шагыйрь булып алдым.
(«Мизгел»)

Ирекле шигырь белән исә Разил артык мавыкмый, ул бик тиз пластик шигырьгә әйләнеп кайта. Әсәрләрендә ул дөньяның зур кайгыларын, тормышның тирән драматизмын үзенең һәм бик күпләрнең шәхси язмышына бәйләп бирә:

Мин – яшьтәше атом бомбасының...
Мин мәңгелек уйда утырам.
Галимнәр, сез бомба ясаганда,
Әниләр бит безне тудырган...
Җәй җиттисә, шомлы күк күкрәде,
Без яшенгә кушылып яшьнәдек.
Мин – яшьтәше атом бомбасының –
Икәү бергә чакта яшәү юк!
(«Мин – яшьтәше атом бомбасының...»)

Монда шартлауга якын антитеза егәре салынган. Ләкин дөньяның ышанычы лирик каһарман кебек тәвәккәл ирләрдә.

Без барда, бу дөнья
Әйләнмәс көлләргә!
Ил өчен без әзер
Елмаеп үләргә.
(«Көлү»)

Бу шигырьдә Мусалар шәүләсе тоемлана.

Разил бер очракта да үзенең шагыйрь икәнен онытмый, шигъри иҗатны ул ил алдындагы олы бурычын түләү дип аңлый.

Ә мин, җирем, син еласаң – елыйм,
Син шатланган чакта – гел көләм...
Ил алдында олы бурычымны
Түләрмен мин шигырь, җыр белән.
(«Күке авазы»)

Шагыйрьлекнең мактаулы һәм авыр йөген, күп очракта исә трагик рәвеш алуын шигърият тарихындагы фаҗигале гыйбрәтләр аша гомумиләштерә һәм Шекспир рухында глобаль сораулар куя. Ил һәм шагыйрь язмышларының диалектик һәм органик бердәмлеген чагылдырган «Агыйделдә боз китә» шигырендә ул мәнә болай ди:

...Татар-башкорт бәгыренә үтеп
Ишетелә Тукай ютәле.
Ил афәттә чакта шагыйрь – корбан,
Ил чирләсә, шагыйрь ютәлли, –
Ачы язмыш гел шагыйрьгә насыйп...
Ник сайламый язмыш бүтәнне?!

Россия тарихындагы шагыйрьләр язмышы хакында Разил мондый трагик икърар бәян итә. Сүз Лермонтов яшәгән йорт янындагы уйланулар рәвешендә бара:

Мылтык атып кошлар каршылыйлар,
Кошлар озаталар бу илдә.
Шагыйрьләр һәм кошлар бертугандыр –
Чын шагыйрьләр үлә дуэльдә.

Табигать темасы, табигать мотивлары Разилнең шигъри дөньясында иң зур урынны били. Әмма анда табигать тасвиры һич тә үзмаксат түгел, шагыйрь табигать сурәтләре аша тормышны, аның катлаулы коллизияләрен төшенергә тырыша, үзенең күзәтүчән карашы һәм йөрәге аша үткәргән тәҗрибәсе нигезендә төгәл икърар ясый, гомумәһәмиятле гыйбрәтләргә чыга. Ул, – гомумән, тирән хисле шагыйрь. Аның табигатьне сынландыруында сагышка сугарылган фәлсәфи юлларны күп очратырга мөмкин:

Бар иде гөлләр, таллары...
Ник китте икән ары?
Елга ярын сагынып елый
Диңгезнең дулкыннары.
(«Дулкын»)

Табигатьтә шагыйрь тормыш багланышларын күрә. Сынландыруларында әдәбиятның зур тарихына аналогия ярылып ята. Мостай Кәрим белән Муса Галигә багышланган «Урман җыры» шигырендә мондый юлларны укыйбыз:

Исән чыкты күпме давыллардан, –
Бу агачлар башын имәде...
Чөнки алар – Туфан наратлары,
Чөнки алар – Тукай имәне.
Безнең җырлар – кара урман җыры...
Бергә җырлап күпме барылган!
Иделләрдә, Уралларда шаулый
Кол Галидән калган карурман.
...Сал да мине ап-ак биләвеңә
Бишек җырын җырла, карурман!

Шигъри тел, шигъри бизәкләрдә эпик сулыш, эпик колач чагыла. Табигать фасыллары диалектикасында шагыйрь, сагышка батып, пессимистик хисләр әсирлегенә төшми, фасыллар алмашында юаныч өчен дә таяныч таба.

Көз китергән сары күлмәк киде
Җир шарының менә бу ягы.
Кышны уйлап моңсуланып йөрдем,
Каурыйларын койган казлардай.
Бар өметем минем кышта инде...
Кыш артында чөнки язлар бар.
(«Көз»)

Шагыйрьнең көр сулышында миләт халәтен ышанычлы итеп күрү төсмерләнә.

Такса таксын дошман төрле исем...
Бар табигать безне үз итә...
Безне сагынып кошлар килә бүген,
Күңелләрдә бүген боз китә.

Лирик каһарманның гамьле күңеле табигать парадоксында ил өчен хәтәр нәтиҗәләр күреп сызлый:

Каралды күптән инеш тә –
Елганың зәңгәр җиңе...
Диңгезгә барып егылды
Даланың кайнар җиле.
Кунды йөзгә җыерчыклар –
Җир-анага, һай, авыр.
Әлсери кырда игеннәр...
Диңгездә... ява яңгыр.
(«Диңгездә ява яңгыр»)

Табигый ки, Разилнең иң эмоциональ шигырьләре мәхәббәткә багышланган. Дөньяның бу хискә бәйле төрле сынаулары, каһарманның җанында дөрләгән шатлык тантанасы да, сагыну моңы да, үкенүләр, югалту әрнүләре дә әле өермә булып, әле якты нурларга күмелеп, аның җырларына, шигырьләренә агыла.

Разил Вәлиев – югары дәрәҗәдә җитлеккән иҗатчы. Әлеге зирәк юллар белән яңәшә мәхәббәт дигән олы хисне кичергәндә, аның бу мәсьәләгә үтә җаваплы карашын чагылдырган борчулы уйлар да, драматик эчтәлекле шигырьләр дә байтак очрый. Мондый әсәрләрдә, башка бик күп шигырьләрендәге кебек, шагыйрьнең шигъри тел белән иркен эш итүе сокландыра:

Зөһрәләрдән калган серне
Ул соң миңа сөтәрме?
Күлгә төшкән ай шикелле
Әллә соң тик үтәрме?..
Бер мәхәббәт табар өчен,
Бер яшьлегем җитәрме?..
(«Мажаралар дөньясында...»)

Әлеге хис җәһәтеннән җаны өзгәләнгән мизгелләр соңрак та шагыйрьдә очрап тора. Аның сизгер күңеле аз гына өмет билгеләрендә дә киләчәкнең якты, зур дөньясын күрә.

Гомернең уртасы, челләсе...
Җанымны ачыйм соң кемнәргә? –
Гомерем елгасы саегып,
Ярлары кавышкан көннәрдә...
Елгалар саеккан чагында
Утырдың көймәнең түренә...
Хисләрем рәшәсе эчендә
Мәхәббәт диңгезе күренә.
(«Елгалар саеккан чагында»)

Шагыйрьнең һәр әсәрендә өр-яңа метафорик сурәтләрдән торган шигъри тел яңгырый. Лирик каһарман сөеклесе белән мөнәсәбәтендәге драматик халәтне шушындый антитеза аша гәүдәләндерә.

Урман кочагына кереп чумдың...
Сүз әйтергә хәтта базмадым.
Сине миңа көз китергән иде,
Алып китәр, ахры, язлары.
(«Язгы шигырь»)

Мәхәббәт булган җирдә тирән сагыш та булу табигый. Шагыйрь Разил Вәлиевнең җырларында һәм шигырьләрендә сагыш, үкенеч мотивлары гаять тәэсирле, һәм аларны һәрчак органик шигъри тел тәгъбир итә:

Болын күкрәгендә сары чәчәк.
Елар идеммени, көлмәсәң.
Соңлаганмын, җилләр килеп киткән...
Миләүшәләр бәхет өләшкән.

Шагыйрьнең бигрәк тә җырларында шигъри тел органикасы көчле. Сагышлы мәхәббәт һәм борчулы язмыш аларга минор яңгыраш бирә.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Разил ВӘЛИЕВ, Татарстанның халык шагыйре

Әйләнә дөньялар, кешеләр, – Кышларым язларга әйләнә...

ӘНКӘЙГӘ ХАТ

Мне страх не нравится,
Что ты поэт...
С. Есенин

Ниләр языйм, әнкәй, ни җибәрим? –
Бар булганым – кара һәм каләм.
Җитмеш тиен юлы шигыремнең...
Шигырьләтә генә җибәрәм.

Үпкәләмим сөйләмәдең диеп,
Уитмен һәм Лорка турында.
Сорый идем: «Әнкәй, Зәй артында
Күк белән җир нигә орына?»
Матурлыкны аңлый белгәнсең син,
Белмәсәң дә якташ Шишкинны...
...Хәлең ничек, билең сызламыймы?
...Безнең монда алты эш көне.

Шәһәр матур, яшәү рәхәт, диеп,
Үткән хатта сине алдадым.
Моңсуланып банан ашап йөри
Балан ашап үскән малаең.
Ә бананнан кабак тәме килә...
Безнең якта кабак мул була;
Сарыкларга кабак алыр өчен
Базга төшкән чакта егылма.
Сарык дигәч... болыннарда ни хәл?
Гыймадимы һаман көтүче?

Көтүчесез калган көтү ничек,
Без дә шулай хәзер җир өчен.
Гүргә түгел илгә китәбез бит...
Елап бардык ләкин юл буе.

Озатып калды кое, синең өчен
Иң кадерле нәрсә шул кое.
Шул коеда синең бар фәлсәфәң:
Без – мәңгелек, дисең, кое күк.
Ә шулай да күз алдында йөзең
Еламсырап тора, боегып.

Тәрәзә артында, сиренага охшап,
Гүлимәлә һаман багана?
Тәрәз аша синең күз нурларың
Кояш нуры белән ялгана.

Киттек инде, киттек, теләп киттек,
Монысында беркем кумады.
Кая барсак, ай ияреп барды,
Һәр урманда бүре улады.
Без киткәнгә юллар сөенделәр,
Җирләр гизеп аяк арыды...
Уларыңны саклый алмадың шул...
Үз-үзеңне сакла, ярыймы!
Ниләр языйм тагын, ниләр салыйм?
Бар булганым – кәгазь һәм каләм.
Җитмеш тиен юлы шигыремнең...
Шигырьләтә генә җибәрәм.

ШАГЫЙРЬ

Ш. Бодлерга

Сабый чакта урындыктан егылды.
Көне буе әнисен көтеп,
еламыйча,
уч төбендә бер тамчы
кан саклап йөрде.
Аңламадылар.

Малай булгач,
беренче тапкыр
йолдыз атылганын күрде.
Кешелеккә яңалык сөйләр өчен,
йокламыйча,
төне буе таңны көтеп ятты.
Тыңламадылар.

Урам тутырып җырлылар да,
җырсызлар да җырлап үтте.
Күз яшенә малайлыгын кушып,
ул җыр язды.
Җырламадылар.

Кайгыларның
ак төстә дә, зәңгәр төстә дә
булуына инанып янды.
Еллардан ул бәхет үтенмәде,
тик ашыкмауларын сорады.
Еллар көлде, юллар көлде.
Кешеләр белде.
Еллар соңламадылар.

Менә бүген
барысы үтте, барысы бетте.
Кешеләр аны әрнеп тыңладылар...
Аңладылар... Соңладылар...
Каберенә башларын орып,
җырын җырладылар.

АВЫЛДА ТУЙ

Киереп ач урыс капкаларны!
Керсен кунак безнең өйгә дә!
Авылда туй. Тракторчы егет
Сыер савучыга өйләнә.

Урамнар тар бүген егетләргә,
Җыр агыла басу ягына.
Бии бабай. «Кеше көлдермә» дип,
Еламсырап әби ялына.

Коеларның суы эчелеп беткән,
Колхоз аты баткан күбеккә,
Иске җырлар яңа булып яңгырый,
Тургай кунганмыни күреккә!

Авылда туй. Гап-гади бер егет
Гап-гади бер кызга өйләнә.
Машиналар тынып калган бүген...
Атлар чаба, чаба... әл-лә-лә!

Калым да бар, бирнә дә бар туйда..
Нинди искелек бу? – димә лә.
Егет батырлыгы калым булса,
Кызның мәхәббәте – бирнәгә.

Чаба-чаба тезгеннәрне өздек,
Тик һаман да җырлар өзелми!
Гасырлардан күчә-күчә килгән
Кыңгыраулар ярсып зеңгелди.

Урамнарны иңләп шатлык килә,
Дус сөенә, дошман көенә.
Каерып ач урыс капкаларны! –
Керсен бәйрәм татар өенә.

БӨЕКЛЕК

Туган чакта – бөтенебез тигез.
Ә үлгәндә? – Белмим ул ягын.
Һәрбер аксак нигә Байрон түгел,
Һәр саңгырау – түгел Бетховен?

Һәр акыллы нигә бөек түгел,
Һәрбер батыр – түгел Газинур?
Һәр авыру Тукай булса әгәр –
Бер минутта мең том язылыр!

Һәр кешедә баш бар, кул, йөрәк бар,
Бөек фикер килә һәркемгә...
Ләкин аны күпләр таный алмый,
Таныганнар кыймый әйтергә.

Фикер җирдә шәрә килеш йөри –
Яңа туган сабый баладай.
«Асрамага бала бирәм», – диеп
Чыгаралар аны базарга.

Каксалар да, суксалар да күп чак...
Бөтен кеше аңа бик якын.
Итекче карт Вәли аңлый аны,
Ишетә аны саңгырау Бетховен.

Ашаталар, сөеп үстерәләр,
Кидерәләр тыйнак киемгә...
Ул дөньяга чыга. Килеп керә
Бәхет булып һәркем өенә.

Намуссызлар өчен намус була,
Өметсезләр өчен – ак өмет.
Җан өләшә җаны үлгәннәргә,
Ул терелтә тик бер кагылып.

Урамнарда йөри ятим фикер,
«Асрамага, – диеп, – кем алыр?»
...Һәрбер сукыр нигә Гомер түгел,
Батыр түгел һәрбер Газинур?!

ТЕАТР

Әйләнә карусель, әйләнә..,
Карусель корылган хәйләгә,
Мостай Кәрим

Әйләнә дөньялар, кешеләр, –
Кышларым язларга әйләнә.
Шаккатып, онытып торам мин
Йөрәгем ярасын бәйләргә.

Әйләнә авыллар, шәһәрләр,
Кайгылар шатлыкка әйләнә.
Чуалган, таралган уйларым
Тезелә шул вакыт сөйләнгә.

Сәхнәгә чыгуга, һәрвакыт
Нигәдер телләрем бәйләнә.
Әйтерсең язмышым шушында
Түгәрәк бәхеткә әйләнә.

Бу залга керүгә, бар кеше
Иң яхшы кешегә әйләнә, –
Кайгысын калдырып урамда,
Кергән күк илаһи бәйрәмгә.

Патефон табасы шикелле,
Театр сәхнәсе әйләнә.
Елата, җырлата, юата, –
Театр корылган хәйләгә.

ТАТАР МӨҺАҖИРЕ

Күпме татар, чит җирләргә китеп,
Тирләр түккән, даннар казанган...
Канатларым канап каерылса да,
Аерылмады җаным Казаннан.

Төп Ватаным чөнки шушы җирдә,
Яшәсәм дә әллә кайларда...
Татар булып пешеп житәр өчен
Казаннарда кирәк кайнарга.

Адашмадык язмыш юлларында,
Давылларда сынып аумадык.
Без яңадан илле, җирле булдык,
Без Казанны кабат яуладык.

Мин бәхетле – ил бәхетле булса,
Халкым булса азат, тәхетле.
Мин милләтем – татарларым белән
Бергә чакта гына бәхетле!

* * *

Күздә – моң, күңелдә – торгынлык,
Җанымны тилмертә аманат.
Кайда син, кай кабер ташында
Бабамнар калдырган әманәт?!

Телләрен өйрәндем җилләрнең...
Җил безнең ботакны каерган.
Чыклардан сорадым, әйттеләр:
«Болыттан сора син, яңгырдан».

Куерган болыттан сорадым –
Ул яшен теләндә сөйләде.
Иң олы юаныч – киләчәк
Колакка пышылдый: «Түз, яме!»

Сораулар, өндәүләр эчендә
Юл тапмый тилмерәм, каңгырам.
Торам да урамга йөгерәм,
Зеңгелди башласа кыңгырау.

Безнең җыр басынкы, безнең чор –
Тарихның минутлык тынлыгы...
Чормада моңаеп тик ята
Бабамның җәясе һәм угы.

Каеннар аклыгын күрә дә
Хәтерем каядыр ашыга.
Нинди сүз, әманәт язылган
Бабамның кабере ташына?!

БЕР КАЙТЫРМЫН ӘЛЕ...

Сибгат Хәким истәлегенә

Кытлык булмас җирдә шагыйрьләргә,
Туу белән үлем булган чакта.
Чәч агаргач шигырь язып кара...
Һәркем шагыйрь юләр балачакта.

Еллар йөге баскач иңнәреңә
Очып кара хыял канатында.
Гомер буе җыйган байлыгыңны
Син чәчәргә тиеш, таратырга.

Ай-кояшка тиңдәй Тукай барда,
Туфан барда шагыйрь булып кара...
Охшатам мин моңлы язмышымны
Кояш нуры иңгән болытларга.

Гашыйк идем язгы бураннарга,
Гашыйк идем җәйге рәшәләргә.
Исемемне онытмаслар әле
Гашыйк җаннар җирдә яшәгәндә.

Мин киткәч тә дөнья матур булыр.
Моңсуланыр Аккош күле генә...
Аккош булып бер кайтырмын әле,
Ышанмагыз минем үлемемә.

РЕДАКЦИЯДӘН. Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Разил ВӘЛИЕВкә шушы көннәрдә 75 яшь тулды. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.

СЕЗ БЕЛМӘГӘН

Без белгән, бөтен җәмәгатьчелек күптән таныган зат – татар халкының олуг шагыйре Зөлфәт бар. Шигырьдә ул – Зөлфәт-Хан.

Әмма шул шагыйрьнең шигырендә без әрнү катыш ялвару ишетәбез:

Мин хан түгел,
мин бары тик Зөлфәт...

Нигә шулай әрнеп кычкыру? Нигә шулай үзеңә лаек дәрәҗәдән баш тарту? Югыйсә, ул бит – татар шигырендә Зөлфәт-Хан. Моны беркая да куя алмыйсың! Моның өчен XXI гасырга кереп карау хаҗәт түгел!

1947 елның салкын гыйнвар кичендә дөньяга килгән Дөлфәт Госман углы Маликов XX гасыр дип исемләнгән болгавыр вә фаҗигале бер дәвердә, Зөлфәт исеме белән, 35 ел буена татар шигырендә ат уйнатты.

Бу җәмәгатьчелек күз алдында булды.

– Озак тартырсыңмы, егет? – дип көлеп торучылар да шактый иде.

Шигърияттә 35 ел ат уйнаткан Зөлфәт 35 ел буена ат урынына авыр йөк тә тартып бара. Ә ул йөк гаять авыр. Бер караганда, олуг шагыйрьгә йөк өстерәп бару төс тә түгел сыман. Әле аның яшәешенең бу өлкәсенә артык игътибар да итмиләр сыман. Югыйсә, аның бу өстерәп барган йөге күп тармаклы. Татар театры, татар балалары язмышы, гаилә, татарның сатира-юморы, журналистикасы, җыйнап әйткәндә, безнең катмарлы татар дөньясы. Ул өстерәгән бу йөкне аңа беркем дә көчләп такмады. Үзем шаһит. Ул аны үз теләге белән үзенә алды. Менә ничә еллар инде Намус, Вөҗдан белән өстерәп бара. Әнә шунда инде сез белмәгән Зөлфәт башлана.

* * *

Моннан 25 ел элек шагыйрь дустым җитди эшкә алынды. Татар балалары өчен беренче операны иҗат итәргә кирәк иде. Ул аның либреттосын язарга керешә. Талантлы яшь композитор Луиза Хәйретдинова аны көйгә салды. Зур бер коллектив белән эшләү дәверендә шагыйрь янды-көйде, кипте, ялыкты, әмма сер бирмәде. Ниһаять, әсәр сәхнәгә менде. Бу татар баласы өчен бик авыр чор иде. Татар мәктәпләре Казанда гына түгел, авылларда да, «атааналар теләге» дигән сылтау белән, бетерелгән чор. Әнә шул вакытта татар телендә татар баласы өчен опера әзерләү үзе бер фидакарьлек иде. Һәм бу – сез белмәгән Зөлфәт...

* * *

Аның белән без Казанга бер пароходта килгәнбез. Имтиханнар бирергә килүебез. Мин берүзем. Алар хәлфәләре шагыйрь Рәдиф Гаташ белән. Бер төркем. Соңыннан, укый башлагач та, Зөлфәт шул төркем тирәсендә кайнашты. «Кеше сөйләшеп, эт иснәшеп таныша», диләр. Безнең этлек көчле булгандыр, без иснәшеп таныштык. Ул минем мәктәп баласы чакта

● Зөлфәт Госман Садә белән.

«Татарстан яшьләре»ндә чыккан шигырьләрне укыган, мин аның «Казан утлары»нда чыккан (шулай ук мәктәптә укыганда язылган) шигырьләрен укыганмын.

«Елатты язмыш егетне...» дип башланган шигырен укыдым да, тулай торактагы кием үтүкләү бүлмәсенә кереп еладым. Чөнки үземнең дә беренче язылган шигырьләремнең берсе әнкәм үлеменә иде. Минеке әле сабыйларча, биредә Зөлфәт җитди, зур шагыйрь, ә бу 1966 ел. Мәртәбәле «Казан утлары» журналы. Нигә ул шигырьләрне Зөлфәт соңыннан бер китабына да кертмәде икән? Хәтта яңа чыккан сайланма әсәрләре басмасында үрнәк итеп тә китермәгән. Бу да сез белмәгән Зөлфәт.

***

Безгә Уфага, яшьләрнең шигъри бәйрәменә барырга туры килде. 1967 елның көзе иде. Безне, хәстәрләп, Нури Арсланнар, Туфан-Хәкимнәр озата. Безнең киләчәгебез хакында хәбәр салынган. Каршы алдылар. Кунакханәдә аерым-аерым бүлмәләр алынган. Килеп төшү белән, суыткычларны затлы эчемлекләр, ризыклар белән тутырып куйдык. Кунак өзелми. Барысы да мөхтәрәм затлар. Соңыннан белдек: Казаннан Хәсән ага Туфан да, Сибгат ага Хәким, Нури ага Арслан да хәбәр итеп куйган икән: «Без сезгә бүгенге Такташ белән Тукайны җибәрәбез, лаеклы каршылагыз!»

Төнге уннарда-унберләрдә безне «хуҗалар» эзләп тапты. Хуҗалар дигәнебез Башкортстан комсомолының өлкә комитеты җитәкчеләре – Идел-Урал арасындагы республика яшьләренең шигырь бәйрәмен оештыручылар. Безгә уңайсыз булып китте. Алар безне иртәдән бирле эзли икән инде.

Шигырь бәйгесе башланды. Зал тулы кунаклар. Кичәне шагыйрь Рәми Гарипов алып бара. Идел белән Урал арасында яшәгән халыкларның вәкилләренә сүз бирә. Кичә нигездә урыс телендә алып барыла. Бер сәгать үтте... Ике сәгать... Инде бәйге бетүгә якыная. Без Зөлфәт белән бер-беребезгә карашабыз, һәм кинәт Рәми Гарипов игълан итә:

Патшаларга баш имәгән
башкорт

Башкаларга гына баш имәс!

Слово предоставляется казанцам!

Каушап калдык. Бер-беребезгә карашабыз. Юк, мөмкин түгелдер, безгә сүз болай бирелергә тиеш түгел кебек. Ничек инде?! Беренче рәттә утырган Нәҗар ага Нәҗми безгә чаларган башын кагып дәрт бирде. Кинәт сикереп торганымны сизми дә калдым:

– Патшаларга баш имәгән башкорт

Шигърияткә, бәлки, баш ияр! – дидем. Мин сезгә бүген Казаннан татарның бүгенге Такташын алып килдем. Ул – шагыйрь Зөлфәт!

Зал башта шаулап көлде. Шагыйрь чыгып баскач: аның кыяфәтен, аның киеренкелеген күреп зал тып-тын калды. Чебен очкан тавыш та юк. Кинәт, бомба шартлаган кебек, сүзләр шартлады:

● Мөдәррис Әгъләм белән.

– Чакырылмаган кунак – татардан да яман...

Татар халык мәкале...

Зөлфәттән бу сүзләрне беренче ишетәм. Куырылып килдем. Болай да киеренке хәлдә ямьсезлек килеп чыга күрмәсен. Менә шагыйрь, тирән сулыш алды да, тезеп китте:

Үз-үзеннән яманрак татар,
Дошман барда җирдә,
үч барда...
Чакырылмаган кунак —
дошманнарга,
Чакырып алган
кунак – дусларга!

Залдагы ул мәхшәрне күз алдына китереп булмый. Зал гүли. Тетри. Күз алдымда, ап-ак җилкән кебек, Нәҗар ага Нәҗми тирбәлә...

Бу да сез белмәгән Зөлфәт...

* * *

Шагыйрь көндәлек татар матбугатына бик иртә хезмәт итәргә керешә. Бигрәк тә балаларга. Иң беренче адымнарын ул «Яшь ленинчы»да (бүгенге «Сабантуй») атлады. Әле аның егет чагы. Булачак хатыны – чибәр, сылу Фирая туташ шунда эшләп йөри. Кечке мәктәптә укый. Казан кызы.

Мин Чаллыдан Зөлфәткә киләм. Яңа шигырьләремне укырга. Каләмдәшемне тыңларга. Миңа Казандагы әдәби хәрәкәтнең барышын белү, әчке гайбәтләрне ишетү кирәк. Зөлфәт аларны бик мул белә, алай гына түгел, үзенә хас юмор белән, кирәк икән тоз һәм борыч өстәп, һәйбәт итеп тасвирлап бирә дә белә. Аның гадәтен яхшы белгәнгә, үземә кирәкле фактларны гына илэп алам. Безнең аерылышасы килми, без редакциядә кунарга калабыз. Бу – тыела. Аста бик усал вахтер карт утыра. Карт булса да, колаклары бик сак, күзе үткер. Шуңа күрә яланаяк йөрибез. Тын гына сөйләшәбез. Авызларны каплап, эчләрне кысып тәгәрәшеп көләбез. Фирая туташ төнгелеккә тәмле-тәмле

ЗӨЛФӘТ

● **Зөлфәт, актер Х. Җәләлев, М. Әгъләмов, Р. Фәйзуллин.**

ризыклар әзерләп, чәй кайнатып калдыра. Беребез – өстәлдә, беребез иске төпләмәләр өстендә йоклыйбыз.

Бик авыр чор иде. Мәктәпләре бетерелгән чорда татар баласын ничек кенә булса да матбугаттан аермыйча, бу афәттән түкми-чәчми алып чыгарга кирәк. Зөлфәтнең ул чакта әйткәне хәтердә: «Бу максатта безгә Иблиснең үзен хезмәт иттерсәк тә гөнаһ түгел». Моны бары тик Ленин исеме белән генә эшләп була иде. Зөлфәт әнә шул көрәшкә ташланды. «Яшь ленинчы» газетасында «Алар Ильичка ант итте» сәхифәсен татар балалары өчен саф татар телендә алып барды, һәм әлеге газета СССРда чыга торган йөзләгән газеталар арасында беренче урынны алды, Мәскәү дөньясын таң калдырды.

Бу җиңү «Яшь ленинчы» газетасының гына түгел, татар телле балалар матбугатының зур җиңүе булды. Әлеге җиңүнең үзәгендә җанының да җанында Зөлфәт иде.

Бу да сез белмәгән Зөлфәт!..

* * *

Зөлфәтнең тагын бер сыйфаты, халык алдында йөз аклыгы булырлык хезмәте бар - ул татар театрының күренекле эшлеклесе, рәсми рәвештә дә расланган атказанган сәнгать эшлеклесе.

Беренче татар балалар операсы хакында сүз булды. Бу әле аның беренче адымы гына булган икән. Тукай әйтмешли, ул әле коеп куйган шагыйрь генә түгел. Ул – артист, драматург, драматург-тәрҗемәче дә. Бүгенге көндә курчак театрында аның берничә әсәре бара. Әмма биредә дә хикмәтләр бар. Хикмәтләре дә гыйбрәтле. Ул беркайчан да: «Менә мин сезгә әсәр яздым, куясызмы-юкмы?» – дип йөри торган кеше түгел. Татар халкына, татар баласына кирәк икән, ул кырыкка ярылачак. Аның бу «йомшак» ягын беләләр. Курчак театрының баш режиссеры Илдус Зиннуров та моны белеп алган, аңа сөлек урынына ябышкан. Өендә дә үз кеше булып алган, эшендә дә.

● **Оныгы Камилә белән.**

Кеше кебек кенә «суырса» икән. Юк! Берничә вариант яздыра. Нормаль зат бер, күп булса ике вариант эшләр иде дә, «Җитте, хватит, брат!» – дияр иде. Ә Зөлфәт дистәләгәнне эшли. Кайчагында кызганып та куям. Зөлфәт түзем, Зөлфәт күтәрә. Инде берничә әсәре сәхнәдә бара. Алар кору кәмиткә генә корылмаган. Аларда – балалар фәлсәфәсе. Бүгенге заман балалары таләп иткән хикмәтле фәлсәфә. Түз, дустым! Бәлки, кайчан да булса бу мәнсез халык рәхмәтен дә әйтер әле.

Шагыйрь дустым – олуг Камал театрында да үз кеше. Аның өчен татар тамашачысын дөнья классикасы белән таныштырып бару – зур бер эш. Алар, нигездә, шигырь белән язылган. Шигырь белән язылмаганнарының да һәр юлы мәкаль, әйтем.

Шекспир, «Укрощение строптивой». Бу әсәр шагыйрь тәрҗемәсендә «Йөгәнсезгә авызлык» исеме белән безнең төп театрда гөрләп барды, һәр геройның телендә, сөйләмендә татар теленең чиксез мөмкинлеге.

Лопе де Веганың 1593 елны язылган «Учитель танцев» әсәре дә «Биюче» исеме белән Камал театрында, Зөлфәт тәрҗемәсендә барды. Шигырь белән язылган, шигырь белән тәрҗемә ителгән. Бу инде шигъри осталыкның Фудзиямасы дигән сүз.

Шиллернең «Разбойники» әсәре дә хәзер Зөлфәт тәрҗемәсендә Камал театрында уйнала.

Берсе – инглиз, берсе – испан, берсе – немес. Дөньяның өч мәшһүр классигы бүген татар телендә сөйли. Дөрес, безнең татар театры электән үк дөнья классикасына йөз тотты. Тәрҗемәчеләргә да бигүк мохтаҗ булмады. Соңгылары Нәкый ага Исәнбәт, Габдулла ага Шамуковлар белән аралашып, гыйбрәтләр дә алып калды. Зөлфәт – шуларның дәвамы.

Бу да тар даирә генә белгән, сез белмәгән Зөлфәт.

* * *

Университетның татар бүлегендә беренче курсны тәмамлагач, безне Свердловски өлкәсенә, Өфе елгасы буйларына фольклор җыярга җибәрделәр. Җитәкчебез – Нил абый Юзиев. Безнең белән шагыйрь Шәүкәт Галиев тә бар. Без бер ел уку дәверендә, нигездә, урысча укыдык. Юк, дәресләрне түгел, алар, әлбәттә, татарча баргандыр. Без дөнья әдәбиятын урысча укыдык. Испан телле шагыйрьләр – Гарсиа Лорка, Рафаэль Альберти, Мигель Эрнандес, Пабло Неруда..., мадьяр Шандор Петефи, шотланд Берне, инглиз Байрон, француз Шарль Бодлер, төрек Назыйм Хикмәт... санап бетерерлек кенәме? Бу җәһәттән, Зөлфәт әзерлеклерәк иде. Чөнки аның хәлфәсе – Рәдиф Гаташ. Ул аңа мәктәптә укыганда ук инде уңдырышлы орлыклар салган. Мөмкинлектән файдаланып, Мөслимдәге Яңа Сәет авылыннан шундый асыл затны табып Казанга алып килгәне өчен мин аның алдында пеләш башымны иям.

Әнә шулай, Казанда кыш буе көне-төне укып ятканнан соң, без иркенлеккә чыктык. Төннәр буе тулай торакның кухнясында, үтүкләү бүлмәсендә, кер юу бүлмәләрендә укып, язып, кайда туры килсә шунда йоклап йөргән Зөлфәткә канат үсте. Без иркенлеккә чыктык. Биредәге «кый» татарлары бераз сәер сөйләшсә дә – барыбер туган тел. Үзебезнең тел. Минем Бабич белән җенләнеп йөргән чагым. Аның «Исемнәр бакчасы» бәйләме белән. Зөлфәт үзенең «Исемнәр бакчасы»н коя гына.

Үрмәкәй авылында Гөлчәчәк исемле кыз. Зөлфәт үзе бу шигырьләрен югалттымы, әллә китабына кертергә теләмәдеме?

Безгә биек тау башындагы Шәкүр авылына менәргә кирәк. Без өчәү. Люзия, ул һәм мин. Матайда бер агай безне борма-борма юллардан биеккә, һаман биеккә, әйләнгеч юллардан алып менә. Куа да куа... Ниһаять, авылга менеп җитәбез. Безне фатирга кертәләр. Илсөяр исемле нәни кызлары бар. Чибәр, матур телле. Әтисе җирле татар, ул шивәдә дә (диалект) әйбәт сөйләшә. Әнисе Казан татары – безнеңчә дә матур сукалый. Зөлфәт яттан шигырь укый да, Илсөяргә дә өлеш чыгара.

Бу гаҗәп авылда без ике көн булдык, ике кич кундык. Тоташ яңгыр, тоташ яшен. Әз генә башыңны күтәрсәң дә, тау өсләрендә тәгәрәп йөргән яшен шарлары башыңа килеп бәрелер сыман. Ә биредәге халык, шулар белән бергә Илсөяр сеңел дә, яшенне-яңгырны бар дип тә белми, безне җитәкләп атлый бирә. Тау башында тәгәрәп йөргән яшен ташлары үзәнгә төшми икән ләбаса. Зөлфәт, моны белгәч, яшеннәргә сикерә, сабыйларча аларга кулын суза.

Бу сәяхәттә без халкыбызның гүзәл табигатенә дөнья әдәбиятының гүзәл шигъриятен кушып кайттык. Өстәвенә, Нил абый да, Шәүкәт абый да аралашучан, искиткеч нечкә җанлы затлар булып чыкты. Соңгы көн, иртәгә кайтып китәсе көн. Һәммә төркем бу авылга, бер ишек алдына җыелдык. Инде үз булып беткән авыл халкы безне озатырга килгән. Шул заман халык алдына Зөлфәт белән Нил абый Юзиев чыгып баса.

– Җәмәгать! Без бүген тантаналы минутлар кичерәбез. Менә, сезнең каршыда мунча. Без бүген биредә истәлекле такта ачарга рөхсәт алдык. Тактаны ачу яшь шагыйрь Зөлфәткә тапшырыла!

Зөлфәт мунчага беркетелгән такта өстендәге сырманы тартып төшерә. Анда тактага кара күмер белән түбәндәге сүзләр язылган: «Биредә, тарих мең дә тугыз йөз дә алтмыш алтынчы әдә татарның бөек шагыйре Шәүкәт Галиев мунча керде».

Мондый кәмитләрне оештыруда Зөлфәткә тиңнәр юк.

* * *

Шагыйрь Мәскәүгә Югары әдәби курсларга киткәнче (1977) алты ел «Чаян»да эшләде. 1983 елдан соң да шул журналда эшли. Ул әдәби бүлекне дә алып бара, тәрҗемә дә итә, рәсем аслары язудан алып иң вак эшләргә кадәр эшли... эшли.

Шагыйрь Зөлфәтнең иҗатында чаянлыкның эзе дә юк. Лирик шигырьләрендә дә, эпик балладада, поэмаларында да... үзе сатира-юморга бай кешеләрнең берсе ул. Татар халык мәкаль-әйтемнәренең, мәзәкләренең, тапкыр тәгъбирләренең дистәләгән вариантларын белә. Ә инде журнал өчен кирәк булганда, аларны үзенең йөгерек акылы белән кырыкка төрләндерә. Әз генә юмор, сатир чаткысы булган дүртьюллык шигырь дә аның кулына килеп керсә, кылыч кебек ялтырап китә. Алмаз кылыч кебек. Шуңадыр да, кош теледәй генә әйбер язса да, авторлар аның янына йөгереп килеп җитә. Зөлфәт – алар өчен бер мәктәп.

Безнең Рәис Даутов атлы галим-редакторыбыз бар. Рәсми исем бирелмәгән халык академигы. Борынгы әдәби хәзинәбезне, классик әдәбиятыбызны аның дәрәҗәсендә белүче башка зат бар микән? Без – бик күп шагыйрьләр – Рәис аганы үзебезнең остазыбыз саныйбыз. Үз гомерендә бер генә юл да шигырь язмаган Рәис ага – шигырь төзелешен иң камил белгән галимнәребезнең берсе.

Аның белән китап әзерләгән шагыйрьләр бәхетле. Мин үземне әнә шуларның берсе саныйм.

Сатира-юмор кебек нечкә, нәзберек өлкәдә Зөлфәт әнә шундый. Бу өлкә аның өчен сәнгать. Һәм ул аны сәнгать дәрәҗәсенә күтәреп редакцияли белә.

Бу да сез белмәгән Зөлфәт.

(Дәвамы киләсе санда).

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ.

1997 ел.

Нәкыйп КАШТАН

Кеше нидән яралган?



Хатип, балта остасы Сафуан улы, Зирекле елгасы ярында утыра. Аның кулында кызыл, үзле балчык. Изгәләгән саен, балчык адәм затына охшый бара. Шунда келт итеп әбисенең сүзе исенә төшә: янәсе, кеше балчыктан яралган. Кызык бит, ничек булган икән бу? Ул да бит балчыкны ярата, аны изә, әвәли, үзле хәлгә китерә. Бәлки аңа жан өрәсе генә каладыр?..

Менә шундый уйлар белән Басыйр абыйсы остаханәсендә үзле балчыктан зу-у-ур итеп адәм сыны ясый ул. Хәзер, ял итеп утырганда, ул кулында балчык әвәли, су өстендә уйнаган кояш нурларын күзәтә. Тик менә әтисе генә аның балчык белән мавыгуын аңлап бетерми. Балчык әвәләп йөргән күрсә:

– Тагын шул сыбызгыларыңны ясап вакыт үткәрәсеңме? – дип ачуланып куя, башка эш куша…

Бүген дә Басыйр абыйсы остаханәсендә адәм сурәтен әвәли, сылый. Балчыгына жан өрә алырмы? Матур кызыл төстәге үзле балчыгында җыру туармы? Балчыгын Басыйр абыйсы белән бергә әзерләделәр. Әлеге балчыкны кулга аласы, әвәлисе дә әвәлисе генә килеп тора.

Ул, бөтен күңелен биреп, чыныгып җитмәгән кулы, сиземле нечкә бармаклары белән балчыкны шәпләп изә, үзләндерә, аны формага кертә. Сихерләнеп эшли ул. Балчык, малайның омтылышын сизгәндәй, аның кулына буйсынып, матурлана бара. Кулындагы җиһазлар да, аның ни эшләргә теләгәнен белгән сыман, әвәләнгән балчыктан артыгын кисеп ала, чокый, сылап куя.

Аның остазы да янәшәдә. Ул зур өметләр белән өйрәнчеген күзәтә. Гүя аның Басыйр абыйсы дөньяга бүген яңа йолдыз кабынасын, яңа оста туасын тоя. Ул йолдыз Зирекле елгасы өстендә кабынса да – балкышы өметле. Остаз, олпат гәүдәсен, нык кулларын кая куярга белмәгәндәй, сакалын сыйпап уйланып кала. Бераздан үзе кебек үк юан бармаклары белән әле эшләнеп бетмәгән Кол Галиенә тотына, сылый, чокый, кисә, изә… Кол Галинең күзләре тирән тарих чоңгылыннан карый сыман. Зирәк…

Хатип һәм остазы Басыйр шулай, бирелеп, балчыктан образ тудыралар – гүя алар үзләре дә шул балчыктан яралган.

Хатип остазга күз салып ала, ә остазы аңа карый:

– Йә, ничек? – дияләр кебек алар бер-беренә. Һәм, елмаешып, янә балчыкка кагылалар…

Басыйр абыйда дәвалап булмый торган чир. Йөрәге соңгы сәгатьләрен саный.

Шул чак ишек шакыдылар:

– Шак… шак… шак…. – Бу – Хатипнең әтисе шакывына охшаган иде. Басыйр абый ишетсен өчен шулай шакый. Басыйр абый эшеннән туктый:

– Кайдан килеп чыкты соң әле бу, шундый җаваплы чакта?! Бар, Хатип энем, кач әле. Мин ятып торыйм… Ул ятып өлгергән генә иде Хатипнең әтисе килеп тә керде. Керүгә, ялт-йолт үткен күзләрен уйнатып алды, янәсе, улы монда юкмы?

Басыйр абый яткан җиреннән торып утырып:

– Хуш килдегез, күрше, – диде.

– Исәнмесез! Улым синдә вакыт үткәреп ятмый микән, дип кергән идем. Ялгышып балчык әвәләп йөри, шайтан. Балчык изеп кеше булырга исәбе. Балчыктан сын ясап әле бездә баеган кеше юк, Басыйр туган, – дип куйды, Басыйр абыйга киная ясап.

– И, Сафуан, юкка туарыласың. Мин баюны күзалламадым, үзең беләсең…

– Һәй, Басыйр, син бит инде ул... син балчыктан туган.

– Сафуан, бәлки, улыңда да балчыкка хирыслык бардыр? Югалтмыйк без аны, күрше… Яшәүне байлыкка гына да кайтарып калдыру матур булмас.

– Басыйр туган, күп фәлсәфә сатканчы, әйт әле, шул кызыл балчык белән мавыгудан нинди тәм табасың?

– Ә беләсеңме, күрше, балчыкның җылысын тоям мин. Әвәләнәчәк үзле балчыкта булачак образымны күрәм. Күз алдыма килеп баса да, мине канатландыра ул. Аны әйтеп кенә бетереп булмый. Бәлки, синең, балтаңны кулыңа тоткач, буласы йортның күз алдына китергән кебектер.

– Кызык, елга ярыннан казып алган юеш балчыктан җылы тою… Ә инде күз алдына китерү дигәндә, дөрес әйтәсең, мин дә буласы йортны, аны кемгә ничек төзүемне күз алдыма китерәм, уйланып план корам.

Басыйр абый сүзләре туры килүгә шатланып нидер әйтәсе иде дә, Сафуан:

– Гафу ит, күрше, бүген ашыгам әле… Китим… – диде һәм чыгып киткәндә улы эшләп бетерә язган сын-скульптурага төртеп күрсәтте: – Шәп ясыйсың инде үзең, Басыйр, һәр сызыгы оста эшләнгән. Музыкаль…

– Менә бит, Сафуан, үзеңә дә ошап куйды.

– Басыйр туган, оста кул эшен әллә кайдан күрәм инде, анысы. Әлеге дә баягы балта остасы бит.

– Кулың алтын синең, Сафуан, улыңа рөхсәт итәр идең минем янда булырга. Балчыкны ярата ул…

– Сорама да, күрше. Балта эше белән мин кешеләрне йортлы итәм. Берәрсеннән йортыңны кем салып бирде, дип сорасалар, – Сафуан, диләр… Акчасы да юк түгел. Ярар, бәлки, уйлармын… Шулай да, синең белән сөйләшеп алгач, күңелгә җиңел булып китте. Кызык синең белән, Басыйр туган. Уңайсыз булса да, сорыйм әле күрше, хәлең ничек? Ярдәм кирәкмиме?

– Ничек дип әйтим, Сафуан, синнән яшермим, хәлем шәптән түгел…

– Борчылма, туган, улымны күрүгә, синең янга җибәрермен, синең яндарак булсын. Ни кирәк – сора. Без бит туганнардан да якынрак…

Әтисе чыгып китүне сизүгә, Хатип поскан җиреннән ялт итеп килеп тә чыкты.

– Мине ачуландымы әти, Басыйр абый? Качып яхшы эшләдек микән?

– И, энем, начар ният белән качмадык бит. Бүген көне шундый. Ә болай, сорады гына ул. Синең турыда да уйлап карармын диде…

– Ә мин орышыр дип курыккан идем?..

– Курыкма, әтиең сине минем янымдарак тотармын диде. Күргәч тә синең янга җибәрермен дип тә әйтте.

Басыйрның Кол Галие тарих төбеннән күтәрелгәндәй: куе чәчле, йөзе, күзләре, маңгае. Аның мәһабәт гәүдәсе борынгы Болгар хәрабәләре өстеннән калкып чыккандай. Хатип та соңгы штрихны куеп башын күтәрде. Аларның күзләре очрашты. Икесе дә елмаешып куйдылар.

– Шәп, шәп, энем…

Аннан соң, Басыйр абый остаханә эченә дә күз сирпеп алды. Остаханәсе иркен, якты. Аның карашы остаханәсен соңгы тапкыр күргәндәй күзәткәч, Кол Галиенә, Хатипнең адәм сынына төште. Хатипнең эшен карап әйләнде. Малайның башыннан аталарча сыйпап:

– Рәхмәт, Хатип энем, күңелне күрдең… Бу адәм затын әтиең күрсә, гаҗәпләнер әле… – диде.

Шулай дип, ул үзенең Кол Галие янына юнәлде һәм кинәт башы әйләнеп китте. Хатип аның янына йөгереп килеп җитте. Остазына урынга ятарга булышты. Басыйр абый кесәсеннән ниндидер дару сәдәфе алып кабып җибәрде.

– Басыйр абый, врач чакырыйммы?!

– Кирәкми, энем. Үтә ул… Бераз ял итәм дә рәхәтләнеп бер тәмләп чәй эчеп утырырбыз. Бәлки, кайткан булса, әтиеңне дә, әниеңне дә чакырырбыз. Бергәләп гөрләшеп, чәй эчәрбез. Бүген бит синең көн. Минем исемдә, энем, яр төбеннән агып чыккан чишмә янында синең су анасы ясап утыруың… Чәчен тарап утыра. Мин сине шуннан бирле беләм инде.

Шул арада Хатип, чәй кайнатып, тәм өчен чәйгә алма турап салды.

Әллә чәй шифасы тиде, әллә рухи көче аны күтәрде, хәл кереп, Басыйр абый торып утырды.

– Рәхмәт, кулың шифалы, энем.

Шулай диеп ул, Хатипнең янына килеп кочаклап алды, һәм өйрәнчеген читкәрәк этәреп, күзләренә карады:

– Ә, беләсеңме, энем, мин хәзер үлүдән курыкмыйм. Син бар минем, – диде.

– Алай димә, Басыйр абый, әби әйткәнчә, Ходай биргән гомерне яшәргә кирәк. Әле терелерсең. Урманнан үзеңә каен җиләге, нарат җиләге җыеп кайтырмын. Алар шундый тәмле булып пешкәннәр инде. Авызыңда ук эриләр. Зәңгәр, сары мәтрүшкәләр дә җыеп кайтырмын.

– Рәхмәт, энем. Табигать биргәнне мәгънәле яшәргә кирәк. Үткән гомер – агым су…

– Басыйр абый, әби адәм затын кызыл балчыктан яралган, диеп әйтә торган иде. Ничек булган икән ул? Аллаһы Тәгалә ничек балчыкка җан өргән икән?

Басыйр абый уйланып торды. Гүя ул Хатип соравына җавап эзли иде. Берара тынлык урнашты. Стенада эленеп торган күкеле сәгать кенә гомерне саный күк.

– Кызык бит бу дөнья, Хатип энем. Кызык. Мин дә бала чакта кызыл балчыкка җан өрергә тырышып ниләр генә эшләмәдем. Мин сиңа риваятьләрдәгесен сөйлим. Анда болай диелә:

Кайчандыр Аллаһы Тәгалә, җир-суларны, йолдызларны, нурлы Кояшны, Күкне, Айны, гомумән, галәмне яраткач, озак кына ялгызлыкта яши. Билгесезлектә була ул. Шулай бервакыт, ялгызлыктан бимазаланып, ул су буенда утырганда, кулына үзле кызыл балчык ала. Балчыкны озак кына үзләндерә. Әвәли, әвәли, изә. Тагын әвәли, тагын изә, ниһаять, ул балчыкның җылысын тоя.

– Басыйр абый, мин дә балчыкның җылысын тойганчы изәм…

– Ул да шулай, энем, онытылып китеп, илһамланып, хыялый күңелен балчыкка биреп изә, әвәли. Әвәли торгач, ни күрсен үзенә охшаган зат килеп чыга. Ул зат шундый камил була ки, аның бөтен җире килгән була, Аллаһы аңа җан өрә. Бу зат Адәм була.

Сөйли-сөйли, Басыйр абыйның хәле янә авыраеп китте. Аңа Хатип урынына барып ятарга булышты, мендәрен төзәтеп куйды. Басыйр абый, авыр сулап әйтте:

– Бар, Хатип энем, әтиеңне чакырып кил,– диде.

Хатип йөгереп чыгып китте. Күз ачып йомганчы, әтисен табып та килде. Ул керүгә, Басыйр абый:

– Күрше, Сафуан, мин китәм, ахры, улыңа эш куш әле,– диде.

– Улым, бар әниеңә әйт, түбән оч Сафура апасын чакырсын!

Хатип чыгып киткәч, оста әйтте:

– Сафуан, үлемем улың күңелендә авыр хисләр калдырмасын,– диде.– Ни әйтсәң дә, бала бит әле ул. Сафуан, барыгыз да бәхил. Туганнар кебек яшәдек. Бер үтенечем генә бар – улыңа ачуланма, балчыктан туган ул...

– Борчылма, күрше, теләсә каршы килмәм.

– Сафуан, әнә кара әле бая күрсәткән сынга. Аңа улың җан өрде...

Шунда алар икесе дә, башларын борып, шул сынга карадылар.

– Басыйр туган, әйтимме бер сүз, – диде Сафуан. – Сиңа да охшаган бит ул, Басыйр туган!

Сафуан шунда, Басыйрның китә баруын тоеп, аның кулына – янәшәдә яткан кызыл балчыкны тоттырды. Балчык җылысын тоеп, ул елмаеп куйды. Шуннан тынып калды һәм, янә хәл алып:

– Сафуан, мин бәхетле, сиздеңме балчык җылысын, анда тылсымлы көч бар... Аннан соң, Сафуан, таш куярсың...

Шулчак Басыйр абый тирән сулыш алды да тынсыз калды. Сафуанның күзеннән яшь бөртекләре тамды. Кәккүкле сәгать кенә, берни булмагандай, вакыт исәбен саный бирде...

РЕДАКЦИЯДӘН. Язучы, шагыйрь, табиб Нәкыйп Каштанов берничә көн элек 80 яшен каршылады. Аны матур бәйрәме белән, котлап озын гомер, сәламәтлек, иҗади активлык, тыныч көннәр телибез.

Үзе – табиб, – пациент

27 яшьлек табиб Леонид Рогозов – 1961 елны үз-үзенә операция ясап, сукыр эчәген кисеп ала алган талантлы табиб. Мондый, үзенчәлекле операция ясаган табибләр бар, әмма күп түгел. Әлеге вакыйга бар илләрдә дә мәгълүм булгач, аның булдыклыгына, түземлегенә ихлас сокланучылар саны арта. Шулар арасында җырчы В.Высоцкий да була. Ул аңа җыр багышлый. Ә Санкт-Петербугта, 1930 елда ук ачылган Рус Арктика һәм Антарктика музеенда Л.Рогозов үз-үзенә операция вакытында кулланган хирургия инструментлары да экспозицияләнә.

Ленинград дәүләт медицина институты ординаторы Леонид Рогозов бер көнне 6 нчы Совет Антарктика фәнни экспедициясенә кузгалу өчен энтузиастлар, хезмәткәрләр тупланулы хакында ишетә. Бу бит космоска мену белән бер дәрәҗәдә могҗиза! Һәм ике дә уйлап тормыйча, шунда бару өчен гариза яза. Унөч кешедән гыйбарәт командага бердәнбер медицина хезмәткәре итеп сайлап алына ул. Чемоданына китаплар сала. Герләрен дә ала.

1961 елны Новолазаревская совет Антарктика станциясендә була бу вакыйга... Бозлы материкта кыш чыккач, 29 апрель көнне ул үзен начар хис итә башлый. Күңеле болгана, температурасы югары, корсагының уң ягы авырта. Табиб аңлап ала: аның сукыр эчәге ялкынсынган... Бер станциядә дә очкычлар булмый. Станция ярдан сиксән км ераклыкта. Һава торышы да – очкычлар оча торган түгел... Башта консерватив терапия методларының һәркайсын кулланып карый ул: ятып тора, ашамый, хәрәкәтләнми, үзе салкын белән сыный, антибиотиклар кулана... Ләкин, ни кызганыч, берни дә булышмый. Табиб үз күңделегенә мондый җөмләләр теза: “Миндә аппендицит, ахрысы. Әлегә бу хакта беркемгә дә дәшмим. Хәтта елмаям да. Үз дусларымны нигә алдан ук куркытырга?! Алар миңа нәрсә белән булышлык итсен инде? Менә төне буе йокламадым. Коточкыч авырта! Карлы буран минем җанымны ашап тора, әйтерсең җаным аша ук уза, ул бит йөзләрчә шакаллар җыелгандай улый. Әле операция кирәк булачагын аныклаган симптомнар юк, әмма начар хәл булачагын сизмләвем күңелемә үтеп керә башлады... Бары да тәмам... Мин бердәнбер мөмкин чишелешне уйларга мәҗбүрмен: үз-үземә операция ясаячакмын... Бу бөтенләй мөмкин түгел кебек, ләкин мин кулларымны салындырып, моның белән килешә алмыйм”.

30 апрель көнне температурасы тагын да күтәрелгән Леонид Рогозов катгый карар кабул итә – үз-үзенә операция ясаячак! Ул медицинага бер генә катышлары да булмаган өч ассистентны әзерлек хәлнә кертә. Метеоролог Александр Артемьев, инженер-механик Зиновий Теплинский һәм станция начальнигы Владислав Гербович табибнең халәтен аңлый. Операция башлангач та, механик яктыртып, өстәл лампасын тотып тора, утны кирәкле итеп җайлап бора һәм зур булмаган түгәрәк көзгене табибнең эче янында тота. Ә метеоролог медбрат вазифаларын башкарып, инструментларны бирә. Станция начальнигы исә тагын нәрсә кирәк дип торучы ролендә. Һәм әгәр теге ике хезмәткәр куркып аңнарын югалтса (ә андый хәл килеп чыгу бик мөмкин), аңа начальник булышлык итәчәк. Ә инде табиб үзе үк аңын югалтса, аны аңга кайтарырлык дарулы шприц әзер. Леонидны коткару буенча башка вариант калмый. Вакыт та тар була инде. Ә кемнең генә күрәләтә торып, яшьли үләсе килсен?!

Көндәлегенә ул болай дип тә яза: “Үз язмышымда беркайчан да үз-үземне шушы кадәр авыр хис иткәнем юк иде әле. Өстәвенә...шушы бинаны уенчык урынына дер селкетүче каты буран купты. Егетләр хәлемне белешеп, мине тынычландырырга дип килеп тора. Минем кәефем юк – барысының да бәйрәмен боздым бит. Иртәгә – 1 май. Ә хәзер барысы минем тирәмдә йөгереп йөри, автоклав әзерли. Безгә караватны стерильләштерергә кирәк. Хәлем инде авырая бара. Бу хакта егетләргә әйттем. Кирәк булмаган бар әйберләрне булмәдән чыгара башладылар”.

Табиб үз кулларын һәм булышчыларының кулларын дезинфекцияли. Новокаин кадаганнан соң, яткан килеш, бик җайсыз итеп, сул яккарак борылып, скальпель алып, унике сантиметр итеп эченә кисем-яра сыза. Операцияне пирчәткә кимичә генә, кайчак көзге аша карап, кайчак капшап-капшап кына ясый. Тик күкрәк өлеше бар яссылыкны да күрсәтми шул. ... Ассистентларның йөзе агарынып ката. Барысы да укшый, барысының да башлары әйләнгәндәй була. Ләкин берсе дә артка чигенми. Кыю полярниклар бит! Табиб та паникага бирелми.Метеоролог аның барлык күрсәтмәләрен төгәл үти. Тагын акырын матшса, аны инде коткарып булмаячагын табиб үзе дә чамалый. Сукыр эчәге зур төгәллек белән кисеп алына. Киселгән җирне пәхтә итеп тегә. Операция бер сәгать тә кырык биш минут дәвам иткәч, төнге уникедә тәмамлана. Леонид ассистентларына күрсәтмәләр бирә. Эченә антибиотик кадый. Ә йокы уколыннан соң ук йоклап та китә.

Биш көн үткәч, югары температура түбән төшә. Тагын ике көннән соң табиб үзе теккән җирләрдәге җөйләрне ала. Эшләвен дәвам итә... Леонид Рогозов шуннан соң 2000 елга кадәр яши һәм Санкт-Петербургта вафат була. Әмма җаны-тәне никадәр борчу, сынау аша узган бу шәхеснең тормыш юлы ничек булган соң?

Леонид Иван улы, Юрий Гагарин кебек үк, 1934 елның мартында Чита өлкәсенең Борзинский районы Даурия станциясендә туган. Әтисе – машина йөртүче, әнисе – сыер савучы. Алар гаиләсендә дүрт бала булган. Бераздан бу гаилә башта Казахстанга, аннары Минусинскига күченгән. Булачак табиб мәктәпкә китә. Бөек Ватан сугышы башлангач, әтисе 1943 елны фронтта һәлак була. Әнисе дүрт бала белән берүзе кала. Көне-төне эшли, Леонид өчен дә җавапы көннәр килеп җитә. VII сыйныфтан соң ир бала тау эше мастерына укырга керә, әмма бу һөнәр аның күңеленә һич тә якын булмый. Әйе, укыган өчен стипендия түләнә түләнүгән... Училищедан соң ул яңадан урта мәктәпкә кайта һәм аны уңышлы тәмамлый. Армиядән соң 1953 елны Ленинградның педиатрия медицина институтының дәвалау факультетында югары белем ала башлый. Спорт, музыка, җәмәгать эшләре... Берсе дә аннан читтә калмый. Акыллы егетне кызлар да бик ошата. Институт тәмамлауга, 1959 елны ук ул хирургия буенча клиник ординатурада белем алуын дәвам итә. 1960 елның ноябрендә “Обь” дизель-электроходына утырып, Антарктикага юнәлә. Табиб булудан тыш, метеоролог һәм хәтта машина йөртүче булып та эшли. Операция барышын ул Совет Антарктикасы экспедициясе бюллетенендә дә тасвирлап нәшер итә: “Операциядән башка үземә берни турында да уйларга рөхсәт итмәдем... Әгәр дә аңымны югалтсам, Саша Артемьев миңа инъекция ясарга тиеш иде – мин аңа шприц биреп, нишләргә икәнен аңлаттым... Бичара ассистентлар! Соңгы минутта мин аларга карадым: алар ак халаттан басып тора, ә йөзләренең төсе халатлары төсеннән дә аграк инде. Аннары мин новокаинлы укол алып, үземә беренче уколны кададым. Ничектер, автомат рәвештә операция ясау режимына көйләндем һәм шул мизгелдән башлап, башка бернәрсәне дә күрми башладым. Сукыр эчәккә кадәр житү, көзге булса да, гади гамәл булмады. Капшап табарга туры килде. Кинәт башыма шундый уй килде: “Мин үземә тагын да күбрәк яра ясыйм һәм аларны сизмим дә...” Хәлем беткәннән-бетә бара, ә йөрәгем тигез типми башлады. Һәр 4-5 минут саен мин 20-25 секундка туктап, ял иттем. Ниһаять, менә ул, каһәр суккан сукыр эчәге!.. Аны кисеп алуның иң авыр стадиясендә күңелем төшә башлады: йөрәгем сизелерлек акрынайды, ә кулларым әйтерсең резинага әйләнде. Бу начар тәмамланачак дип уйладым шул чак. Ә бит сукыр эчәген кисеп алаcы гына калган иде! Әмма соңрак мин үземнең исән калуымны аңладым!”

Бу хакта совет халкына мәгълүм булгач, аның батырлыгына хәтта күпне күргән, беренче очучы-космонавтлар да соклана. Мәсәлән, СССРның очучы-космонавты Герман Титов үзенең “Голубая моя планета” китабында Александр Матросов, Николай Гастелло, Борис Пастухов һ.б. каһарманлыкларын санап, болай дип тә язган: “Безнең илдә каһарманлык – ул тормышның үзе... Без Антарктика экспедициясендәге катлаулы шартларда үз-үзенә операция ясаган совет табибе Леонид Рогозовның батырлыгыннан көнләшәбез. Кайчак, берүзем калганда, бу хакта үз-үземнән сорыйм: мин моны булдыра алган булыр идемме? Һәм һәрчак башыма шундый җавап килә: “Көчемнән килгәннең барысын да эшләргә тырышыр идем...”

1961 елның июнендә СССР хөкүмәте табибне Антарктика экспедицияләрендә катнашып, шунда аеруча да батырлыклар кылучылар белән бергә Хезмәт Кызыл Байрак ордены белән бүләкли. 1962 елның октябрендә генә әлеге экспедициядән яңадан Ленинградка әйләнеп кайткан Леонид бер елдан соң ординатураны тәмамлый. Аны яңадан Антарктикага баручы экспедицияләргә әйдәп карыйлар. Әмма табиб үзе риза булмый. “Мин анда нинди генә башка төр эшләр башкармадым, авыр әйберләр ташыдым, төзедем, буядым да... квалификацияле табиб кына буласым килә...” дип җавап бирә. 1963 елны шул ук институтның аспирантурасында укый башлый. Өч елдан соң үңәчтәге яман шешне дәвалау темасына багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. Бер ел табиб-хирург булгач, академик И.П.Павлов исемендәге Ленинград медицина институтының госпиталь хирургия кафедрасы ассистенты булып эшли, ә 1971 елны аны Болгариягә хезмәт командировкасына юллыйлар. 1979 елдан алып 1986 елга кадәр төрле сырхауханәләрдә, медико-санитар частьларда табиб-хирург булып хезмәт иткәч, 1986-2000 елларда Ленинградның фтизиопульмонология фәнни-тикшеренү институтының лимфоабдоминаль туберкулез хирургиясе бүлеген җитәкли. Бик талантлы табиб булса да, һәрчак тыйнак була.

Аллаһы Тәгалә бу бәндәгә күп сәләтләр биргән. Ул болгар, немец, инглиз һәм чех телләрендә дә яхшы сөйләшкән. Әмма үпкәдәге яман шеш сәбәпле операция кичергәннән соң, хәле катлауланып, нибары 66 яшендә вафат булган. Олы улы Василий хакында мәгълүмат юк. Ә менә Прага медицина студенткасы Марцела белән корган гаиләдәге балалары: кызы Елена – Чехиядә яши, гомуми практика табибәсе, улы Владислав – Бөекбританиядә, табиб-анестезиолог. Чех кызы Рогозовка үз сокланучы белдереп хат яза, дуслашалар, СССРда бик тату гаилә коралар. Әтиләренең үз-үзенә операция ясавын белеп үсә балалары! Әмма ул чакта көннән-көн авырая барган гаилә тормышы инде юкка чыга бара. Чөнки Леонидны күпләр таный. Аны еш сыйлыйлар, атаклы шәхес белән дуслашырга теләүче экчечеләр табылып кына тора, табиб рух ныклыгы күрсәтми, эчкән көннәрендә кызып китүчән була. Һәм Марцела Рогозова ике кечкенә баласын алып, үз туган иленә кайтып китә. Югары квалификацияле хирургны дан белән бәйле экчечелеге авыр хәлгә төшерә...

Улы Владислав әңгәмәләрдә үзенең ике бала үстерүен, аларның да дәү әтиләре Леонид Рогозов белән горурлануларын искәртә. “Әти яхшы күңелле кеше иде... Кызганыч, без аны җирләргә дә кайта алмадык. Вафат булуын соңрак белдек. Санкт-Петербургка берничә елдан соң гына кайтып, кабере янында баш идек”, – ди.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Дөньядагы бар осталар да аны күптән легендага тиңли! Шуңа карамастан ул башкаларга карата бик ихтирамлы. Инә очы чаклы да тәкәбберлеге булмаган зат ул!

МАКРОГАЛӘМЕ –

Салават Фидаи 1972 елның ноябрендә Башкортстанның Иглин районы Красный Восход авылында укытучылар гаиләсендә туган. Аның әнисе Лида Хөсәен кызы – сынлы сәнгать укытучысы, ә этисе Фидаги Тимергали улы коррекция мәктәбе директоры булып эшләгән. Бүген алар лаеклы ялда. Салават К.А.Дәүләткилдеев исемендәге Республика сәнгать мәктәп-интернатында укыган. 1995 елны Көнчыгыш икътисад-юридик гуманитар академиясен тәмамлаган. Егерме елдан артык төрле коммерция компанияләрендә җитәкче урыннарда эшләгән.

Искиткеч талант иясе Уфада яшәп иҗат итә. Аңлашыла булыр, шедеврлар иҗат итүчеләрнең холкы бераз үзгә була... Әмма Салават әфәнденең җавабы куандырды: «Үземне тыныч холыклы кеше дияр идем. Миниатюралар сәнгате түземлекне, эш сөючәнлекне таләп итә. Микроскульптураларны ясау процессы ул медитациягә тиң: мин үземнең микро-космосыма яисә макрогаләмемә чумам, кайчак сулышымны тоткарлап торырга да туры килә, һәм мин микроскоп аша үз кул бармакларым очларындагы пульсны да күрәм. Аеруча нәфис һәм катлаулы скульптураларны эшләгәндә, миңа графитка йөрәк тибешләрем арасында кагылып уярга туры килә».

Иҗат өлкәсенә кайту юлы аның өчен 2013 елның декабрендә башланган. Уфадагы бер сәүдә компаниясендә топ-менеджер вазифасын башкарудан туктаганда, С.Фидаигә инде 41 яшь була. Урта яшь кризисы, офиста эшләүдән талчыгу... Бу сәбәпләр дә тәэсир иткән. Ары аны ни көтә?! Һәм шул ук вакытта гаять югары хезмәт хакы алган эштән үз теләгең белән китү... Ә моны кем генә аңлар?! Гаиләдә өч бала да үсә бит әле. Әмма Салават үз карарында калган. Ул бу адымга җитди әзерләнгән, тормышының матди ягын кайгырткан. «Әлеге чорда мине тулысынча аңлаучы бер генә кеше булды. Хәләл җефетем Регина. Мин аңа моның өчен һәрчак рәхмәтле! Ул мине бернәрсә өчен дә игәүләмәде. Ул вакытта киләчәктә уңышлы иҗат итәчәгем дә алдан мәгълүм булмады бит әле. «Үзеңнең күңеленә нәрсә ошаса, шуңа алын!» – диде Регина. Мин күп уйландым һәм шуны аңладым: бары тик җәмгыять басымы булмаган, социум кагыйдәләре кысмаган хөр балачагымда гына,бары тик сынлы сәнгать белән шөгыльләнгәндә генә бик бәхетле булган идем бит! Рәсемнәрне һәр көн ясый идем һәм аларны ясаудан һич армый идем! Әти-әнием һөнәри рәссамнар, өйдә гел иҗади атмосфера гына. Мин хөр рәссам булуны сайлап, үземне сәнгатькә багышларга булдым», – ди әңгәмәдәшем.



Ниһаять, 2014 елдан башлап – Салават Фидаи бары тик рәссам һәм скульптор! Ул әүвәл дә, мәктәп-интернаттан соң Башкортстан дәүләт педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетына имтиханнар тоткан булган, әмма сызым буенча аңа түбәнрәк билге куелган... Шуннан соң гына ул юристлыкка укый башлаган. Дусларының: «Юриспруденция – яхшы һөнәр, ә менә рәссамлык җитди эш түгел», дигән фикерләре дә күңелгә кергән. Аннары ул укый башлаган чорда Интернетның бар мөмкинлекләре дә юк бит әле, ә ул булмагач, чын рәссам үз картиналарын күп итеп сата аламы инде?! Эштән үз теләге белән киткәч, бер елга якын үз-үзен эзләгән Салават... Берара фотография белән кызыксынган һәм үз фотосурәтләрен Мәскәү, Санкт-Петербург күргәзмәләренә дә элгән. Майлы буяулар белән импрессионизм һәм экспрессионизм юнәлешләрендәге картиналар да иҗат иткән. 2015 елны «Яңгырлы шәһәр» сериясе картиналары белән янә Санкт-Петербург күргәзмәсендә катнашкан. Әмма картиналарны чит илләргә сату, анда юллау гына һәрчак мәшәкатьле рөхсәт алулар белән бәйле. Шушы сәбәп аркасында картиналар язуын туктаткан. Чөнки картиналарны гадәттә чит ил кешеләре генә сатып ала. Укчы йолдызлыгы астында туган ир-ат картиналар язуда тукталып калмыйча, сәнгатьнең башка юнәлешләре белән кызыксынган. Һәм үз игътибарын миниатюралар ясауга юнәлткән.

Бер көн Салават Фидаи кечкенә кабак төшенә күренекле рәссам Ван Гогның (бу рәссамның эшләрен бик ошата) «Йолдызлы төн» картинасын күчереп ясаган һәм иҗат нәтиҗәсеннән канәгать калган. Рәсемнәр өчен көнбагыш төшләре һәм хәтта ки дөге бөртекләре дә кулай булып чыккан. Бераздан Ван Гогның башка картиналары да шырпы тартмалары өслекләренә язылган. Чөнки Салаватның балачагындагы шырпы тартмалары күңелләрәк рәсемнәр белән җитештерелгән бит. Ә бу гасыр шырпы тартмалары кызыклы түгел. Кабак төшенә язылган эшен 2015 елның апрелендә Амстердам каласында урнашкан Ван Гог музее үзенең Твиттер сәхифәсенә дә урнаштырган. Ләкин Салават болар белән генә тукталып калмаган. Аннары бер ел яшәргә дип тупланган акча да бетеп бара, шулчак аңа яраткан тау велосипедын да сатып җибәрергә туры килгән. Картиналарын да саткан... Беркөн планетакүләм мәшһүр булып китәчәк оста эшкә урнашырга туры килер инде дигән уйга калган, эшкә урнашу буенча әңгәмәләргә дә барып килгән. «Тик Регина: «Әйдә, үзеңне тагын берәр өлкәдә сынап кара, чөнки мондый иртәдән-кичкә кадәрге эшнең синең өчен түгеллеген сизәм. Әйдә, син рәссам бул!» – диде. Һәм мин аның, балаларымның да сүзләрен тыңлап, тагын иҗат юлыннан киттем», – дип аңлата Салават.

Рәссам 2014 елның ноябрендә үз иҗаты өчен туры килерлек өр-яңа материал ачкан. Кибетләрдә сатылган гап-гади каләмнәрнең графит очлыклары! Һәм 2015 елның февраленә кадәр беренче микроминиатюраларын иҗат та иткән! Аларның фотоларын Интернет сәхифәсенә кую белән үк иҗатына мөкиббән китүчеләр саны күз ачып йомганчы берничә меңгә җиткән, аннары да өстәлеп кенә барган. Бүгенге көндә аның Инстаграм сәхифәсен сигез йөз ун меңгә якын кеше укый. Әмма Инстаграм инде «ачый бара» төсле... Нишләргә? Шулчак оста үзенең төпчек кызыннан киңәш сорагач, TikTokта теркәлгән, Салаватның үз скульптураларын ничек ясау процессы төшерелгән видеоязмалары сәхифәсе пәйда булып берничә сәгать үтүгә, аның видеоязмасына бер миллион кеше сокланган. Башка көннәрдә укучылар саны кар өермәседәй арткан. Мондый каләмнәр сәнгать сөючеләр өчен бәяләре буенча да, ихтыяҗ буенча да, Интернеттагы фикер-бәяләмәләр буенча да бик вакытлы булып чыккан. Бүген Салават Фидаи TikTok сәхифәсен 12 миллион кеше күзәтә. Хәзер талантлы рәссамнарга уңайрак, аларның күбесенә арт-дилерларның, галереяларның, рәссамнар берлекләренең кирәге дә юк, чөнки заказчылар аларны Интернет аша үзләре таба. Менә, Салават Фидаиның видеоязмаларын да башкалар үз сәхифәләренә урнаштырып куя, кайчак аның исем-фамилиясен дә язып тормыйлар. Мәсәлән, кытай TikTokгында Салават Фидаиның әсәрләрен аныкы икәнен язмыйча гына урнаштыр-

КАЛӘМ ОЧЫНДА

ганнар һәм бу язманы ярты миллиард кеше караган... Әмма аның әсәрләрен язмада күпләр исем-фамилиясе булмаса да таный инде.

«Рәсемнәрне бик күп итеп ясасам да, үю сәнгатен дә балачактан ук үз итә идем мин. Башта акбурларны уйдым. Аннары агачтан, таштан әйберләр уеп караганым булды. Менә аннары инде графит сәнгатенә мөрәҗәгать иттем. Ә мондый беренче әсәрләрем 5 мм диаметрлы графит очлыкта ягъни каләмнең грифель өслегендә иҗат ителде, – дип аңлатты талант иясе. – Аннары мин 2 мм грифельле каләмнәргә күчтем. Аннары 0,5 һәм дә 0,35 мм грифельле каләмнәрне үз иттем. Бик югары сыйфатлы мондый сәнгати каләмнәрне планетада нибары өч, ә бәлкем дүрт кеше генә ясаган чак иде ул елларда. Иҗат юлымны әле дә дәвам итәм. 2021 елга миндә 500 үзенчәлекле әсәрем тупланды инде».

Краудфандинг проекты кысаларында, останың иҗатын ошатучылар тарафыннан акча туплангач, 2016 елны аның «The Pencilbook» фотоальбомы да нәшер ителде.

2017 елда 5 мм диаметрлы каләм очларына Д.Трамп һәм В.Путин бюстлары да уелган. Д.Трамп бюсты уелган каләм Инстаграмга куелып нибары бер сәгать үтүгә үк, минуты-секунды белән дигәндәй, Париждагы коллекционер тарафыннан сатып алынган. В.Путин бюстлы каләмне сатып алырга теләүчеләр саны да берничә дистәгә тулган. Ләкин Салават Фидаи үзе генә аның шәхси тупланмада саклануын теләмәгән. Нәтиҗәдә, каләм очындагы В.Путин бюсты Санкт-Петербургтагы «Русский Левша» музеенда саклана. Башка сәясәт эшлеклеләрен сурәтләргә дә күп тәкъдимнәр булган, ләкин оста бу темадан баш тарткан. «Иҗади кызыксынуым юк», – дип аңлата ул әлеге карарын.

С.Фидаи башта һәрбер каләмен сатып барган. Шуңа күрә дә шәхси күргәзмә ачу мөмкинлеге булмаган. Әмма чит ил сәнгатьсөярләре беркөн аңа бар ясалачак каләмнәрен дә берьюлы сатып алырга тәкъдим иткән. Билгеле, шул очракта гына күргәзмә ачарга җитешле әсәрләр туплана ала. 2016 ел – рәссам-оста өчен күргәзмәләргә иң бай ел! Салават Фидаиның иң беренче шәхси күргәзмәсе 2016 елны АКШның Калвер-Сити шәһәренең Launch галереясында ачылган. Икенче шәхси күргәзмәсен оста шулай ук 2016 елны Бөекбританиянең Virgin Trains тимер юл компаниясе үтенече буенча Лондонның Кингс-Кросс вокзалы территориясендә ачкан. Шул ук елны аның әсәрләре Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге Шарджа шәһәрендә узган Халыкара китап ярминкәсе кысаларында экспозицияләнеп, тамашачылар күңелен яулаган. Бу – баш әйләнгеч уңыш булырлык вакыйга, чөнки әлеге ярминкә-күргәзмәне бер миллионнан артык кеше караган бит!

«Тамашачылар барлык дәүләтләрдә дә бертөсле, – ди Салават. – Сокланалар, таң калалар. Билгеле, күргәзмәләр барышында каләмнәр пыяладан ясалган гөмбәзле колпаклар эченә беркетелә.Тамашачылар аларны лупалар аша карый.

– Скульптураларыгызны бернәрсә белән дә ныгытмыйсызмы?

– Юк. Каләмнәр махсус пеналларда саклана. Шулай да килеп чыга инде, микроскульптуралар, аларны каядыр күчереп алып барганда яисә күргәзмә вакытында, саксызлык килеп чыкса, сына да иде... Хәзер инде мондый күңелсезлекләр килеп тумасын өчен, бары да уйланылган. Пеналлар сыйфатлы.

С.Фидаиның 2017 елны HBO телеканалы заказы буенча Сингапурда ачылган шәхси күргәзмәсе дә зур уңыш белән узган. Анда катнашкан утыз әсәрнең уналтысын HBO телеканалы башка беркайчан да ясамау тәкъдиме белән сатып алган, ә калган ундүртен коллекционерлар күргәзмә бетүен дүрт күз белән көтеп, алып бетергәннәр. Шул ук елда останың башка күргәзмәләре дә Малайзиядә, Таиландта олуг уңыш белән үткән. 2017 ел ахырында АКШның Гринвич каласында узган күргәзмәсе дә барысын да сокландырган. Соңгы елларда С.Фидаиның микроскульптуралары Австралия, Польша һәм Румыниядә дә күрсәтелде. Останың үз Ватанындагы иң беренче шәхси күргәзмәсе 2021 елның көзендә Санкт-Петербургның «Титикака» рекордлар һәм фактлар музеенда ачылды. «Каләм очында» күргәзмәсенә иллedән артык әсәре урнаштырылды һәм аларны бихисап халык карады. Кызыксынган тамашачылар өчен оста бер каләм очына катлаулы әсәр уеп күрсәтте, тамашачыларның сорауларына җавап бирде. Гомумән, С.Фидаи – үтә дә зыялы, итагатьле шәхес, башкалар күңелендә туган сорауларга язма җаваплар бирергә дә кыенсынмый, шушы өлкәдәге нечкәлекләрне аңларга теләгән АКШ, Тайвань, Таиланд, Һиндстан осталарының сорауларын да җавапсыз калдырмый. С.Фидаи – бүген шушы сәнгать төре буенча дөнья лидеры!

Тагын шунысы да бар: 2018 елны С.Фидаи гаиләсе белән АКШка, Майямига күченгән. Ләкин анда нибары ярты ел гына яшәгән. АКШта илһамланып иҗат итә алмаган ул. Андагы кайбер тәртипләрне дә күңеле белән кабул итә алмаган. «Илебез энергетикасының куәтен читтә яшәп карап аңладым. Ватанга бик теләп кайттык. Безнең кешеләр аларга караганда ирекләрәк яши икән дигән фикергә килдем», – ди оста бу хакта сораучыларга. Ләкин АКШның берәр яхшы үрнәге бардыр бит? «Билгеле бар, – ди иҗатчы үз әңгәмәләрендә. – Миңа тиздән илле яшь. Мин – шушы илдәге СССР чорын да, яңа Россия төзелүен дә күргән буын вәкиле. Мин үз туган җиремне бик яратам. Әйе, бәлкем, башка чит дәүләткә дә китеп булыр иде, әмма миңа шушы илдә яшәү ошый. Ләкин без бирегә никадәр генә гомер кичерсәк тә, АКШта салынган юллар сыйфатына якын да килә алмабыз, ахрысы. Бу дәүләттәге юлларны күрдем, алар – искиткеч! Ләкин андагы мәктәпләрдәге тәртип, кешеләрнең йөзләренә ябышкан ясалма, ялагай елмаюлар, чит менталитет, америкалыларның бер-берсе өстеннән шикаять язырга әзер торыш, иминлек сакчыларының аларга рөхсәт ителгән катгый таләпләрне мизгел эчендә куллану мөмкинлеге – болар бары да АКШ чынбарлыгы. Мин анда килеп төшү белән үк күңелсезләндем. Елмаймас ук булдым. Бу чит илдә яңа тормыш башлаудан курку хисе түгел иде. Һич юк! Чөнки клиентларымның иң күбе шушы дәүләттән. Әмма минем күңелемә беренче мизгелләрдә үк шулкадәр салкынлык бәрелде, аны һичничек тә үземнән кире чыгара алмадым. Һәм АКШта иҗат өчен мөһим илһам югала барды дияр идем. Шушы тискәре хис-халәтләр Уфага кайткач кына юкка чыкты».

– Салават, сез Россиянең иң мәшһүр замана рәссамнарының берсе булып саналасыз. Сезне бар дөнья коллекционерлары хөрмәт итә. Аңлашыла ки, мондый четерекле, күп тырышлык таләп итүче әсәрләр һич арзан тора алмый...

– Әйе, алар чыннан да кыйммәт. Шуңа күрә сатып алучыларымның барысы да диярлек – чит ил кешеләре. Европа илләре, АКШ, Австралия коллекционерлары... Мәшһүр эшкуарлар. Яисә чит дәүләтләрнең эре корпорацияләре. «Forbes» исемлегенә керүчеләр дә...

(Дәвамы 16 нчы биттә).

ҖИҢҮГӘ АВЫР ЮЛЛАР

(Рейхстагчы Михаил Минин китабыннан)

Хәлиткеч штурм алдыннан «Гимлер йорты» подвалына, нигездә, ике частьның бүлекчәләре тупланды. Уң флангта – 674 нче укчы полктан майор В.И.Давыдов, сулда – 756 нчы укчы полктан капитан С.А.Неустроев батальоннары. Аларның арасында – составында уннан артык кешесе калган безнең штурм төркеме. (Әлеге операция 1945 елның 26 апрелендә башлана).

Сул флангта К.Я.Самсонов батальоны һөҗүмгә әзерләнә, ул 380 нче укчы полк җитәкчелегенең нияте буенча (полк командиры – майор В.Д.Шаталин), сулыкны уң яклап узарга һәм С.Неустроев батальоныннан сулдарак һөҗүм итәргә тиеш. Алдагы сугышларда өч батальон да зур югалтулар кичерде, ә хәлиткеч штурм алдыннан башка бүлекчәләр хисабына тулыландырылды. Әмма, барыбер бу батальоннарның составы штатның 70-80 процентын гына тәшкил итә. Шундый зур булмаган көчләр белән рейхстагны танклар һәм артиллериядән башка гына алырга кирәк иде.

Җирле вакыт белән 21 сәгать 30 минутта артиллерия әзерлеге башланды. Төп ут көчен орудиеләр һәм авыр минометлар тәэмин итте. Бу чараларда безнең 136 нчы артбригада да катнашты, күзәтү пункты иртән генә «Гимлер йорты»нда җиһазландырылган иде.

В.Маков боерыгы буенча, А.Бобров, Г.Заһитов, А.Лисименко һәм мин, куенга ике Кызыл байрак кыстырып, иң кырыйдагы тәрәзә уемы аша чыктык һәм каналга таба йөгердек. Заһитов теләсә кайсы җирлектә яхшы ориентлаша. Бу юлы да безне алдан ук билгеләнгән кичү урынына алып килде.

Артиллерия һәм минометлар утын Тиргартен тирәлегенә күчергәч, һавага яшел ракеталар күтәрелде – штурм башлану билгесе. Бу вакытта без дүртәү каналның икенче ярында идек инде. Калын торба буйлап йөгереп чыктык: беренче Г. Заһитов, аннары мин, А. Лисименко һәм А. Бобров.

Шундук парад ишегенә таба йөгердек. Г.Заһитов бу маршрутны көндез үк бинокльдән өйрәнгән икән. Уңда да, сулда да дошманның исән калган ут нокталары телгә килде. Ләкин безне кирпеч, балчык өемнәре һәм рейхстаг янында урнашкан вакытлы корылмалар саклады.

Рейхстагка якынлашкач, төп керү ишегенә таба автоматлардан ут ачтык һәм, тоткарланмыйча, кирпеч кыйпылчыклары белән тулган киң гранит баскычтан күтәрелә башладык. Ике якка ачыла торган зур авыр ишек эчтән бикле булып чыкты. Уң якта да, сулда да элекке ишек урыннары бар, тик алар кирпеч белән томаланган. Озакламый безнең янда бер взвод солдат җыелды. Күмәкләшеп, иңбашларыбыз, аякларыбыз, мылтык түтәләре белән дә ачарга тырышып карадык, ләкин ишек бирешмәде.

● М.Минин.

● Г.Заһитов.

Г.Заһитов белән Лисименко йөгерә-атлый түбәнгә төште һәм тиз арада бүрәнә алып килде. Дистәдән артык кеше күмәкләшеп бәргәннән соң, ишек ачылып китте. Бина эченә тоташ ташкын булып совет сугышчылары агылды. Барысыннан да алда коммунист Гази Заһитов. Аның артыннан рейхстаг тупсасын беренче атлаучылар арасында капитан В.Н.Маков коммунистлары – А. Бобров, А. Лисименко һәм мин. Алгы шеренгалар автоматлардан ут ачты. Рейхстагта дөм караңгы – ориентлашуы кыен. Кул фонарьларының утлары ялтырап китте.

Тәҗрибәле сугышчылар коридорларга һәм подвалдан чыгу юлларына граната ыргытты. Дошман җир астына куып кертелде. Беренче һәм өске катларда аз гына көчләр калды, аларны рейхстагка бәреп кергән совет хәрбиләре юк итте. Дошман контрһөҗүмгә күчеп өлгергәнче, рейхстагка 380 нче укчы полкның алгы бүлекчәләре һәм С.Неустроев, В.Давыдов батальоннары килеп керде. Совет сугышчылары, фашистларның каршылыгын җиңеп, бүлмәләрне бер-бер артлы азат итте.

Безнең төркем командиры рейхстаг өстенә үтәргә булды. Тоташ шау-шу, автомат чиратлары һәм гранаталар шартлавы астында капитан В.Маков боерыгын ишеттек:

– Минин, барысын да җый һәм, флагны алып,түбәгә мен!

Минем янәшәдә Г.Заһитов, А. Бобров, А.Лисименко бар иде. Караңгыда фонарь ярдәмендә Г.Заһитов тапкан баскычтан югарыга омтылдык. Алдан җимерек баскычны фонарь белән яктыртып, Г.Заһитов йөгерде. Аның артыннан мин – байрак белән, минем арттан А.Лисименко һәм А.Бобров. Баскычка чыга торган барлык коридорларны да Ф-1 гранаталары һәм автомат чиратлары белән «чистартып» алдык. Без әле икенче катта гына идек, астан безгә ярдәмгә башка укчы-сугышчылар килеп җитте. Аларның бер өлеше, дошманның баскычка үтеп керүенә юл куймас өчен, шундук коридор ишеге төбендә ятты, ә калганнары безнең арттан өскә йөгерде.

Чорма каршында мин стенадан чыгып торган нечкә торбага тап булдым. Кулым белән каты итеп каерган идем, ул бик җиңел сынып чыкты. Мин аны байрак сабы сыйфатында кулланырга булдым һәм үзем белән алдым. Чормага җиткәч, тизрәк түбәгә чыгу юлын табарга кирәк иде. Автомат чиратлары белән чорманы «чистартып» алганнан һәм караңгылыкка берничә граната ыргытканнан соң Г.Заһитов кабат кулындагы фонарьны кабызды һәм ерак түгел генә йөк лебедкасын, өскә таба сузылган пластинка сыман массив чылбыр тапты. Гигант чылбырның буыннары шундый зурлыкта иде ки, аларга аяк табаннары белән иркенле басып була.

Бер-бер артлы чылбыр буйлап менеп киттек. Һәрвакыттагыча, алда – Гази Заһитов, ә аның артында – мин, байрак белән. Җайлы булсын өчен, «байрак сабы»н авызга каптым, автоматны аркама элдем, уң кулыма пистолет тоттым. Чылбыр буйлап дүрт метр чамасы үрмәләдек, ишетү тәрәзәсе аша түбәгә чыктык. Караңгыда манара шәүләсе күренә иде. Заһитов белән икәүләп Кызыл байракны шуңа беркетә башладык.

Кинәт түбәдә снаряд шартлады. Ут яктысында А. Лисименко безнең көндезге ориентирны – «Җиңү алиһәсен» күреп алды (без ул скульптура төркемен шулай атый идек). Туктаусыз артиллерия атуына карамастан, Кызыл байракны шушы сын өстендә беркетергә булдык. Шунда ук түбәдә, караңгыда, мин үз исемемне һәм дусларым – рейхстаг өстенә 1945 елның 30 апрелендә 22 сәгать 40 минутта беренче Җиңү Байрагын беркеткән Бобров, Заһитов һәм Лисименко исемнәрен язып куйдым.

Байракны металл «таякка» бәйләр өчен, Заһитов үзенең кульяулыгын тасмаларга ертты. Алар белән полотноның ике почмагын торбага бәйләдек. Мин иптәшләр булышлыгы белән бронза атка мендем. Атка атланган хатын-кыз сынының таҗында бер тишек таптым һәм торбаны шунда урнаштырдым. «Сап»ны Заһитов биргән тасмалар белән таҗга бәйләп куйдым.

Аттан төшү белән, без барыбыз да кочаклаштык һәм кичекмәстән В.Маковка Җиңү Байрагын урнаштыру турында хәбәр итәргә булдык. Мин, Заһитов һәм Лисименко түбәдә калдык, ә Бобров төшеп китте.

Тиздән капитан В.Маков килде, һәркайсыбызны кочаклап үпте. Аннары, Бобров белән бергә төшеп, рация буенча корпус командиры генерал-майор С.Н.Переверткинга сугышчан бурычның үтәлүе турында хәбәр итте: «Иптәш генерал, минем егетләр рейхстаг өстендәге ниндидер хатын-кыз таҗына Җиңү Байрагын кадап куйды!»

Бу докладны 3 нче удар армиянең политбүлек башлыгы полковник Ф.Я.Лисицын да тыңлап торган. Соңрак ул моны 1961 елның ноябрь аенда, рейхстаг штурмында катнашучылар киңәшмәсендә дә раслады.

Артиллеристларның (ул вакытта безнең төркем шулай йөртелә иде) Җиңү Байрагын кадавы турындагы хәбәр, тиз арада рейхстагны штурмлаучы барлык сугышчыларга таралып, аларда зур патриотик күтәрелеш уятты.

Рейхстаг өчен сугыш һәр сәгать саен киеренкеләнә барды. Без контрольдә тоткан баскычны дошман берничә тапкыр кире тартып алырга тырышып карады, ләкин совет сугышчылары автомат һәм пулемет чиратларының ут яктысына һәм иптәшләренең тавышларына ориентлашып, кыю адымнар белән бүлмәләргә бәреп керде һәм дошманны гранатлар белән «сыйлады». Шундый бер бәрелеш вакытында безнең батыр разведчик Газетдин Казыйхан улы Заһитов каты яраланды.

Дошман пулясы, соңыннан табибләр ачыклаганча, йөрәктән бер сантиметр гына читтән үткән, партия билетын һәм «За отвагу» медале колодкасының бер читен тишкән. Ләкин каһарман егет сугышны ташламады.

Якын дусты Саша Лисименкодан һәм өлкән сержант Ткановтан беренче медицина ярдәме алгач (алар аның ярасын үзләренең шәхси пакетлары белән бәйләп куйды), Г.Заһитов полк санчастена барудан баш тартты һәм сугышчан бурычын үтәүне дәвам итте. Яралы булса да, ул беренче Җиңү Байрагын саклау өчен өч тапкыр чормага менде.

Җиңү Байрагына үтү юлын һәм баскычларны без, чиратлап, 1945 елның 1 маена, иртәнге 5 сәгатькә кадәр саклдык, радистлар белән бергә рейхстагның беренче катындагы бүлмәләрнең берсендә урнашкан, һәм берничә тапкыр дошман контрһөҗүмен кире кагуда турыдан-туры катнашкан төркем командиры белән өзлексез элемтәдә тордык.

1945 елның 1 май төнендә рейхстагта мин, капитан С.Неустроевка мөрәҗәгать итеп, «Беренче Җиңү Байрагын кая кадап куюыбызны күрегез», – дип әйтергә теләгән идем, ләкин батырчылык итмәдем, чөнки рейхстагның беренче коменданты һәрвакыт бик дулкынланган хәлдә иде, кулына маузер тотып, бина эчендә каты тәртип урнаштырып йөрде. Монда төрле частьлардан һәм төрле бүлекчәләрдән сугышчылар бар иде. Шуңа күрә, солдатлардан берәрсенә боерык биргәнче, С.Неустроев һәрвакыт: «Мин рейхстаг коменданты булам», – дип әйтә торган булды.

Немецларның подвал бүлмәләреннән һөҗүм ясарга ниятләвен белеп алгач, С.Неустроев подвалга гранаталар ыргытырга кушты. Аның командасы буенча мин дә беренче катның баскыч мәйданчыгыннан бер Ф-1 гранатасын түбәнгә ыргытып өлгердем, аннан соң икенче гранатаның чекасын тартып алдым, ләкин шул мизгелдә С.Неустроевның икенче командасы яңгырады: «Гранаталар ташлауны туктатыгыз!» Мин саклык чекасы тартып алынган гранатаны уң кулыма тотып, шактый вакыт караңгыда рейхстаг буйлап йөрергә мәҗбүр булдым. Безнең төркем генерал С.Н.Переверткин әмере белән иртәнге сәгать алтыда рейхстагтан чыккач кына бу куркыныч йөктән котылдым – гранатаны су тулган каналга ыргыттым.

Юл уңайлый «Гимлер йорты» подвалына кердек һәм сәгать ярым элек В.Н.Маков боерыгы буенча рейхстагтан аңсыз хәлдә шунда китерелгән Г.Заһитовны үзебез белән алдык. Аз гына ял итеп алган героебызга бераз хәл кергән. Мин автоматын күтәрдем, ә Саша Лисименко аны култыклап алды. Ике дошман пулеметы ут ачуга карамастан, Мольтке күперен уңышлы гына үттек. 79 нчы укчы корпусының команда пункты янында тукталыш ясадык. Хәрби бурычны үтәү турында генерал С.Н.Переверткинга доклад биргәннән соң, безнең янга капитан В. Маков килде һәм, беренче Җиңү Байрагын беркеткәндә күрсәткән батырлыклары өчен корпус командирының В.Н. Маков, А.П.Бобров, Г.К.Заһитов, А.Ф.Лисименко һәм М.П.Мининны Советлар Союзы Герое исеменә, ә штурм төркемендә катнашкан башка кешеләрне Ленин орденына тәкъдим итәргә кушуын әйтте.

1 май көнне иртәнге сигезләр тирәсендә 136 нчы артбригада штабына җиттек. Анда бригада штабы башлыгы подполковник А.Л.Бумагин каршылады. Аның боерыгы буенча дүртебезне дә фотога төшерделәр. Иртәнге аштан соң разведка дивизионының штаб башлыгы капитан В.А.Абрамов чакырды һәм дүртебезне дә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итү өчен бүләкләү кәгазьләре тутырды (бу документлар Оборона министрлыгы архивында саклана – фонд 33, оп.686196, л.л.6078, 168, 189, 205, 212).

● Сулдан уңга: сержант М.Минин, өлкән сержант Г.Заһитов, А.Бобров, А.Лисименко. Берлин. 1 май 1945 ел.

Капитан В.Н.Маков төркеменең батырлыгын бу документны үз имзалары белән беркеткән разведка дивизионы, бригада, корпус командованиесе, 3 нче удар армиянең артиллерия командующие, армиянең Хәрби Советы әгъзасы, 3 нче удар армия командующиеның никадәр югары бәяләве турында белү өчен, архивта Г.К.Заһитовка язылган бүләкләү кәгазе белән танышу да җитә.

«Безнең гаскәрләр Берлин үзәгенә - рейхстагка якынлашканда, – диелә анда, – Заһитов, шәхси инициативасы буенча, аны штурмлауда катнашу һәм Җиңү Байрагын рейхстагта беренче булып кадау теләген белдерде. Сержант Минин, өлкән сержант Бобров, өлкән сержант Лисименко белән берлектә, Заһитов хәрби биремне үтәүгә юнәлде. Һөҗүм итүче пехота алдыннан барган Заһитов, рейхстагка якынлашу юлын эзләп табып, безнең пехотаның алга хәрәкәт итүенә зур ярдәм күрсәтте. 28 апрель көнне разведчиклар, немецларның тылына кереп, немец сакчысына тап булды, аны юк итте һәм, подвалга бәреп кереп, 25 немец солдатын әсир итте. 29 апрель көнне Заһитов һәм аның иптәшләре немецлар ягына бәреп керде һәм безнең артиллерия утын рейхстаг тарафына юнәлешләп торды. Алар урнашкан йорт немецлар тарафыннан чолгап алынган иде, ләкин геройлар бирешмәде. Автоматлар һәм гранаталар ярдәмендә кырык гитлерчыны юк иттеләр һәм безнең пехота килеп җиткәнче йортны саклап калдылар.

Г.Заһитов рейхстагтан 100 метр ераклыкта картада күрсәтелмәгән билгесез каналны тикшереп, аның аша узучы үткелне тапты. Разведка нәтиҗәләре турында, радио аша, 79 нчы корпус командирына җиткерделәр. 30 апрель көнне рейхстаг штурмы вакытында Заһитов беренче булып рейхстагка бәреп керде, күкрәгенә үтәли яра алды, ядрә партбилетын тишеп чыкты. Яраланса да, сержант Заһитов һәм сержант Минин рейхстаг манарасына менделәр һәм беренче Җиңү Байрагын беркеттеләр. Рейхстагны штурмлау вакытында күрсәткән кыюлыгы, батырлыгы өчен иптәш Заһитов «СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ» исеменә лаек».

Ирекле штурм төркеме командиры В.Н.Маковның 79 нчы укчылар корпусының штаб башлыгы полковник Летунов һәм корпус командиры генерал-майор Переверткин имзалаган бүләкләү кәгазендә исә болай дип язылган: «Иптәш Маков беренчеләрдән булып рейхстаг өстенә Кызыл Байрак – Җиңү Байрагын кадады. Командование бурычларын бик яхшы үтәгәне өчен, иптәш Маков «СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ» исеменә лаек» (Оборона министрлыгы архивы, ф. 317, оп. 4334, д. 277, л. 205).

Соңгы сүз урынына: сугышчыларга Герой исеме түгел, Кызыл Байрак (18.05.1945) орденнары тапшыралар, ә рәсми байракчылар итеп Михаил Егоров (рус, ВКП(б) әгъзасы) һәм Мелитон Кантария (грузин, партиясез) билгеләнә, алар 1946 елда Советлар Союзы Герое исеменә лаек була.

P.S. Кайбер тарихчылар фаразынча, Михаил Петрович Минин Россияне поляк басып алучыларыннан саклап калуга зур өлеш керткән татар Кириша Миңнебаев (Кузьма Минин) нәселеннән булуы ихтимал.

Язманы
Амур ФӘЛӘХ
әзерләде.

Атнаның сәяси мизгелләре

КИСӘТҮЛЕ ЯҢА ЕЛ

Күпләр игътибар иткәндер, 2022 ел безләр өчен икътисади вә сәяси планда да, рух күтәренкелеге һәм әхлак торышы ягыннан да, ул гына түгел, санитар вә эпидемиологик хәлебез җәһәтеннән дә зур тотрыксызлык шартларында башланып китте. Ил күләмендә алсак, әйтик, инфляция хәтта «Росстат» мәгълүматлары буенча да 2021 елда 8,39% тәшкил иткән (2020 елда ул 4,9% кына иде). Эчке сәясәтне алсак, парламентта кабул ителгән законнарның зур күпчелеге илдә хакимият вертикален тагы да ныгыту, димәк, төбәкләрнең һәм ил халкының хокукларын чикләүгә юнәлдерелгән. Тышкы сәясәттә эшләр тагы да мөшкелрәк: Россияне бөтен дөньяга диярлек каршы куйган хәлдә, режим күрше славян дәүләте белән «кайнар сугыш» чигендә баланс саклый, Европада «кызыл сызык»лар билгели, соңгы мөмкинлекләрен җыеп, бөтен өметен күмәк Көнбатыш исеменнән эш итә торган АКШ Президенты Джо Байден белән сөйләшүләргә баглый. Казахстанда башланган чуалышлар һәм анда тәртип урнаштыру өчен ОДКБ исеменнән гаскәр кертелүе тышкы сәясәттәге хәлләрне тагы да катлауландырды. Пандемия дә коронавирусның яңадан-яңа штаммнары белән котырына. Ни гаҗәп, шундый шартларда 2022 ел илдә «Халыкларның матди булмаган мәдәни мирасы һәм халык сәнгате елы» дип игълан ителә.

Эшләр исә Татарстанда да куанырлык түгел. Республиканың сәяси вә хокукый статусы чикләнүе генә җитмәгән, аның милке һәм җирләре дә отыры шул ук кавем кулына күчеп бара. Хокукый диктат шартларында, Татарстан Төп Законына аның бүгенге хокуксыз статусын беркетә торган үзгәрешләр кертергә җыена. Комплекслы басым барганда, республикада узган гасыр азагында кылынган кайбер җинаятьләрне тикшерүнең яңартылуы исә, җитәкчелектәге бәгъзеләрнең чамасыз «тыпырчынуын» кисәтү адымы булып та күренә. Әлеге шартларда, Татарстанда пандемиягә каршы көрәш буенча оештырылган оператив штаб республикада прививка ясаткан ярты миллион кешенең иммунитеты бик тиз кимүе турында белдерә һәм, моны кисәтү өчен, 2022 елны «Ревакцинация елы» дип игълан итә.

Фоат УРАЗАЙ.

Үткән елга нәтиҗә

Мәдәният министрлыгы карашынча, мәдәният тармагында 2021 елның кайбер казанышлары:

«Казан гастрольләре» кысаларында Казандагы мәдәният йортларында 70 спектакль күрсәтелгән. Аларны 20 000 тамашачы караган. Проектның икенче этабында мәдәният учреждениеләре 45 районда 90 мәдәният йортында чыгыш ясаган.

XVIII Кече шәһәр театрлары фестивалендә гран-прины «Көзге сер»е белән Әлмәт театры алды.

«Yenfest» балаларның традицион уеннары фестивале кысаларында 2000 уен тамашасы ясалган, дүрт җиңүче команда Мәскәүгә барган. Тамашаларны онлайн форматта 650000 кеше караган.

Болгарда «Ага базар» I этномәдәни фестиваль оештырылган. Анда 450 кеше катнашкан, 6 меңнән артык тамашачы булган. Министр бу фестивальнең перспективасы бик зур, дип бәяләде.

«Тормыш стиле – мәдәни код» этно-fashion I халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать фестивале. 32 төбәктән 400 катнашучы. Фестиваль Россиянең Сәнгать һәм сәүдә министрлыгы белән эшләнгән.

Традицион бәйрәмнәр онлайн һәм оффлайн форматта күрсәтелә. 58 онлайн бәйрәмне 18 илдән 40 миллион кеше караган. «Комментарийларны укыдым – кешеләр безнең заманча шартларда үзтәңгәллегебезне сакларга омтылуыбызга соклана», — диде министр.

«Уйнагыз, гармуннар!» традицион фестивалендә 750 кеше катнашкан. Хәтерләсәгез, быел әлеге чарага популяр җырчы Фирдүс Тямаев җәлеп ителде. «Гармунчылар белән аз булса да урамнан үтү өчен мин бөтен эшемне ташлыйм. Эмоцияләр ягыннан бу искиткеч тойгылар», – дип аңлатма бирде министр.

Tat cult fest яңа татар мәдәнияте фестивале: 40 шәһәр, 40 мең тамашачы, 30 мең карау.

Грантлар. Президент грантлары фондына 487 проект тәкъдим ителгән. Бирелгән проектлар саны буенча республика дүртенче урында, җиңүчеләр саны буенча – икенче урында.

Татарстан «Пушкин картасы»на билетлар сату буенча беренче өлкәкә кергән. Сүз уңаеннан, быел «Пушкин картасы» 5 мең сум булачак.

«Алтын битлек» театр премиясе лауретлары арасында Казаннан Динә Сафинаның «5 mm/һ» пьесасы да бар.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Макрогаләме – каләм очында

(Ахыры. Башы 12 нче биттә).

Мин инде безнең экраннар өчен блокбастерлар ясаучы күп кенә абруйлы телекомпанияләрнең барысы белән диярлек хезмәттәшлек иттем. Marvel, Warner Bros, 20th Century Fox... Гадәттә, алар өчен өр-яңа мультфильм, кинофильмнар персонажларын уйдым. Гомумән, әсәрләрем җитди сыйфатлы булу белән үк, аларны саттым. Гаилә тормышын алып барырга, өч балабызны үстереп, аякка бастырырга кирәк бит. «Тормыш авырайган саен, рәссам да остара гына бара», дигән фикердә мин. Бездә шундый шартлар, алар авыр, кайбер кешеләр аннан сәнгатькә китеп кенә сулыш ала. Әмма безнең илдә мондый әсәрләрне сатып алучылар гаять дәрәҗәдә аз. Юк диярлек. Әйтик, йөз чит ил коллекционерына бер безнең ил коллекционеры туры килә. Сатып алучыларым төрле. Арада үтә байлар бар, аларны инде бернәрсә белән дә гаҗәпләндереп булмый. Алар бер-берсенә бик үзгә бүләкләр бирүне генә ошата, шуңа күрә мондыйлар минем каләмнәремне бүләк өчен ала. Кайберләре каләмнәремне даими сатып ала да, шкафларда, сейфларда саклый. Ә мин каләмнәремнең кайда сакланулары белән кызыксынам, сорыйм. Андыйлар: «Син әле яшь, син аларны фәлән бәһагә генә саттың, әлеге каләмнәр – минем өчен инвестиция. Синең перспективаң бар. Хәзер алар ун мең доллар, ә берничә елдан соң, бәлкем, алар бер миллион доллар тора башлар!» – диләр. Кайчак каләмнәргә имзамны да салам. Ә аны бары тик микроскоп аша гына укып була. Бар шундый килешүләр: алар буенча мин бер уйган әсәремне башка һичкайчан да уймаска тиешмен, чөнки заказчы әлеге әсәрнең планетада бер генә экземплярда булуын тели. Беренче тапкыр шундый заказ шартын ишеткәч, бу таләп күңелемә бер дә ошамаган иде... Шунысы да бар: ул чакта каләмнең бәясе тагын да арта.

– Сез иҗатыгызда нинди эш кораллары кулланасыз?

– Алар күп түгел. Пирчәткәләр киеп эшлим. Стереомикроскоп һәм лезвиелары алышына торган үткен һәм үтә дә нечкә пычак кулланам. Эш урынымны гел чисталыкта тотам, графит тузанын калдырмыйм. Каләмнәр тирә-юнемдә тулып ятмый. Ясап бетерү белән һәрберсе коллекционерларга юллана бара.

– Мондый каләмнәрне ясау өчен ким дигәндә ничә сәгать вакыт сарыф итәсез? Күзләрегезгә килгән киеренкелекне ничек бетерәсез?

– Бер әсәр аз дигәндә 15 сәгать вакыт эчендә уела. Катлаулырак әсәрләрем ун көн эчендә иҗат ителә. Кеше тәкъдиме буенча гына түгел, күбесенчә күңелемә илһам килгәндә ясыйм. Кайбер катлаулы, әйтик, киноэпопея каһарманнары образларын берничә тапкыр ясарга туры килгәне булды. Мәсәлән, Дарт Вейдер образын җиде тапкыр уйдым. Чөнки материал – нәфис, инде уелып бетте генә дигәндә, сына.

Каләмнәрне гадәти кибетләрдән алам. Берәр яңарак тауар житештерелсә, андый каләмнәр белән дә кызыксынып куям. Кайсыберләренең графитлары күпсанлы детальле образлар уяр өчен күбрәк туры килә. Каләмнәр бит каты яисә йомшак сыйфатлы итеп житештерелә, аларны уярга теләгән сюжетыма карап сайлыйм. Төсле каләм грифелендә бары тик гади әйберләр генә уеп була. Чөнки микроскоп аша карагач та, аның сыйфаты башка төрле булуы ачык күренә. Төсле каләмнәргә буягычлар, полимер матдәләр, балавыз да кушыла. Алар нәфисрәк составта. Эксперментлар яратсам да, гади әйберләр ую – минем өчен һич кызык түгел. Әгәр дә заказчы тулы бер серия иҗат итүемне тели икән, каләмнәр ясау вакыты арта. Мәсәлән, «Игра престолов» телесериалы хакында ишетсәм дә, аны караганым юк иде. Аны иҗат итүчеләр миңа үзләре шалтыратты. Аларның тәкъдимнәрен кабул иткәч, бу сериалны карап, өч ай буе аның эчтәлегенә кергән бихисап персонажларны, символларны уйдым. Әйтик, күп кылычлы «Тимер тәхет»не өч атнага якын ясадым...Тора-бара сериалдагы кайбер песонажлар һәм аның гомуми атмосферасы да күңелемә ошап китте.

Күзләр, билгеле, ара. Көнгә берникадәр ял итеп алам. Әсәр тәмамлангач та, берничә көн ял итә алам, игътибарымны башка әйберләргә юнәлтәм, күзләремә килгән киеренкелекне бетерү өчен фокус ераклыкларын да үзгәртәм... Урамнарда, табигатьтә йөреп керәм...

– Салават, ә менә кайсы төр әсәрне иҗат итү кыенрак: кеше образынмы яисә Эйфель башнясынмы?

–Барысы да детальләр санныннан тора. Эйфель башнясы үзенең челтәрле конструкциядә булуы белән катлаулы. Портретларны иҗат итү дә бик җиңел түгел. Шушындый кече масштабта охшашлык тудырырга кирәк.

С.Фидаиның гаҗәеп матурлыктагы әсәрләре күләмен аңлар өчен аның әсәрләре ясалган каләм очының диаметры 0,5 миллиметрдан алып 2 миллиметрга кадәр икәнен күз алдына китерергә кирәк! Шуңа күрә скульптураларының биеклеге дә 1-2 миллиметрдан артмый!

– Сезнең инде башка төр материалда иҗат итәсегез килмиме әле?

– Кайчан да булса таштан уярмын яисә күләме зуррак булган сәнгать әсәрләрен металлдан иҗат итәрмен дип тә уйлыйм. Ләкин әлегә иҗатым бары каләмнәр белән бәйле. Бу төр сәнгатькә ихтыяҗ булган кадәр уярмын инде.

– Салават, шушы үзенчәлекле иҗатыгыз белән Казанда үз күргәзмәгезне ачар идегезме?

– Бик теләп!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.



«Биючеләр бии-бии остара...»

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең берничә буын музыкантлары, балетмейстерлары һәм биючеләре төрле уникаль характерлы милли образларны өйрәнү, саклап калу һәм киләчәк буыннарга тапшыру өчен дистә еллап гомерләрен багышлады. Бүген Ю.Муко, Г.Таһиров, Ф.Гаскәров, Ә.Нарыков, Ә.Кәлимуллин, М.Гатиатуллин, Р.Гарипова, А.Хәмитов кебек балетмейстерларга, һ.б. бик күп биючеләргә рәхмәтлебез. Ансамбльнең алтын фондын танылган сәнгатькәрләр һәрдаим баетып торды. Татар халык биюе борын-борын заманнардан ук, еллар аша узып, милли мәдәниятебезнең уникаль сәнгать төре булып тора. Ул халкыбызның тарихын, холкын һәм гореф-гадәтләрен саклый.

Чаллыда туып-үскән Айрат Заһидуллин шәһәрнең 23 нче мәктәбендә беренче класстан ук хореография дәресләренә йөри. Бию хәрәкәтләре күңеленә яткач, җитди максат белән шөгыльләнә башлый. Айрат бишенче класстан ук гимнастика белән дә шөгыльләнә. Чаллыдагы сәнгать училищесының хореография бүлегендә төрле укытучылардан классик һәм халыкча бию серләрен өйрәнә. Укуын тәмамлагач, Чаллы шәһәрендә танылу алган "Болгар" бию ансамблендә иҗат юлын башлый.

Талантын таныйлар, күрәсең, 2007 елда Айратны Россиянең үндүрт коллективына эшкә чакыралар. Шулар арасыннан ул Төньяк флотның җыр һәм бию ансамблен (Североморск шәһәрендә) сайлый һәм анда ел ярым армия хезмәтен дә үти. Кайткач, Чаллының "Болгар" бию театрында эшләп ала да, күп тә үтми, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә чакырыла. Казан Сабан туенда ансамбльнең сәнгать җитәкчесе А.Хәмитов белән очрашып, алар белән Кытайга гастрольгә китә һәм ансамбльдә бөтенләйгә кала.

А.Заһидуллин 2011 елдан Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балет артисты һәм коллективның төп солистларының талантлы вәкиле. Ул профессиональ осталык, сәхнә өчен ихтыяҗлы тышкы кыяфәте, затлы пластикасы, актерлык сыйфатлары, эш сөючәнлеге һәм иҗади активлыгы белән аерылып тора. Хореографиянең теләсә кайсы жанрын – классиканы да, халыкчаныкын да, шулай ук хәзерге заман биюләрен дә югары кимәлдә башкара ала. Аңа биюнең идеясенә тирәннән кереп, милли колоритын саклап, һәр хәрәкәтнең вак нюансларын төгәл итеп осталарча башкару хас.

Ансамбльнең һәр постановкасында аның югары биеклеккә профессиональләре тышкы кыяфәте белән гармоник тәңгәл килүе, катлаулы хореографик техникасы, җиңел виртуоз сикерү һәм музыкаль материалны аңлап эш итүе сокландыра. Актерлык талантының колачлыгы да төрле пландагы образларның характерын ачып салырга ярдәм итә. А.Заһидуллин үзенең геройларының эчке дөньясын аңлап иҗат итүе белән тамашачы күңеленә үтеп керә һәм үзен яраттыра белә.

Репертуарындагы "Минзәлә" вокаль-хореографик куелышында гармунлы шаян-зирәк егет, атаклы хореограф Фәйзи Гаскәров куйган "Кияү" шаян биюендә тотнаклы, сын-сыйфатлы кияү егете, рус биюләрендә югары техникалы солист, А.Хачатурян музыкасына "Егетләр" хореографик куелышта заманча пластика, сылу кыз белән дуэт биегәндә, Айрат үзенең ышанычлы, горур, ныклы характерын күрсәтә. Аның башкару диапазонының киңлеге һәр катлаулы биюләрне уникаль югарылыкта башкарырга ярдәм итә. Айратның биюләре затлылыгы һәм нәфислеге, егетләрчә егәрлеге, дәрте, зирәклеге һәм кешелеклелеге белән күңелләрне әсир итә.

Бию – халык күңеленең көзгесе, дибез. Биюләрдә халык күңеле, зәвыгы көзгедәгедәй чагыла шул. Табигате белән бәйле халык холкындагы иң матур якларны күрә белеп, иҗатында чагылдыра алган Айрат та биюләрендә татар халкының затлылыгын, тарихын, фикер байлыгын, казанышларын сәнгатьчә чагылдырырга омтыла.

Татар опера театры залында "Изге бакча" вокаль-хореографик премьерасы (хореограф Г.Кофтун) башланып, 20 минут үткәч тә, төп рольне башкарган Айратның аягы таеп сына. "Шул көе беренче бүлекне биеп бетерергә мәҗбүр булдым, чөнки алмаш юк иде. Тәнәфестә миңа укollar ясап, күз яшьләре, авыртулар аркылы икенче бүлекне эшләп чыктым, – дип искә алды Айрат Фәһимович. – Ябык сыну булган, гипсламадылар. Чөнки алты ай гипста йөрергә туры килер иде. Табибләр буын-сеңгерләрем көчле булгач, гипссыз гына өч айдан аякка бастырды".

Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов: "Айрат - ансамбльнең затлылык бөркелеп торган биючеләреннән. Сәхнәдә ир-егетнең бөтен уңай сыйфатларын күрсәтә торган артистларның берсе. Биегән вакытта аның хәрәкәтләренең тамашачыны үзенә тарта торган тылсымлы көче – сөйкемле сөягә бардыр, мөгаен, дип куясың. Техник яктан да бик көчле. Айрат һәрбер хәрәкәтне камиллеккә җиткермичә туктамый. Камиллекнең чиге юк, ул тәҗрибә белән килә. Ул бик тырыш, эш ярата, һәр хәрәкәтне төбенә төшенеп эшли торганнарның берсе. Безнең коллектив өчен зур байлык, горурлык. Артистларыбыз да аны ихтирам итә. Үзе бик ачык, һәркемгә ярдәмгә килергә әзер. Ансамбльнең күренекле биючесе ТРның халык артисты Равил Габдрахмановлар кебек биючеләрнең иҗатын дәвам итүче шәхес булып үсәр дип ышанабыз. Һәр программаның биюләрендә ул – солист. Классиканы да, халык биюләрен дә, техник биюләрне дә югары осталыкта башкара. Киләчәктә бик яхшы репетитор да булыр дип ышанабыз", – диде.

Күптән түгел Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Мәдәният министрлыгы, Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятkә ярдәм фонды җитәкчеләре "Мирас" дип исемләнгән татар биюенең барлык матурлыгын танып белергә омтылучылар өчен мультимедияле белем бирү проектын чыгарды. Проектта татар милли хореографиясенең нигезен һәм үзенчәлекләрен ачып бирә торган мастер-класслар куелган. Проектны оештыручы осталар белән берләттән язмабызның герое Айрат Заһидуллин да Равил Габдрахманов белән осталык дәресләрендә катнаша. Бию сәнгатенә карата яңаяңа проектлар тагын да дөнья күрер дип ышанабыз.

Филүсә АРСЛАН.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

15 гыйнвар (шимбә). ***Җомәдел ахир аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,12.45 сәгатьтә калка, 8.12 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.39 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Фасоль чистарта

Хроник пиелонефриттан интеккәндә, бөерне болай чистарту файдалы. 1 стакан фасольне 1 литр суга салып, эмальләнгән кәстрүлдә, капкачын ябып, 2 сәгать пешерәләр. Суын сөзеп, фасольне төяләр, көн буена шуны гына ашыйлар һәм фасоль пешкән суны эчәләр. Сихәтләнү курсы – көнаралаш шулай дәваланып, 1 атна.

16 гыйнвар (якшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,13.35 сәгатьтә калка, 8.21 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.42 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына биргәк тә бирешүчән. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Баланлы бал

Бронхит интектергәндә, 1 аш кашыгы балан җиләген изеп, ярты стакан балга кушып болгаталар, яхшылап төреп, 5-6 сәгать тәнәтәләр, көненә 4-5 тапкыр 1 әр аш кашыгы кабалар. Каты ютәлне басу өчен, 100 г баланны 2 стакан кайнар суга салып, сүрән утта ярты сәгать пешерәләр, 1 сәгать тәнәткәч, чирек стакан бал кушып, болгаталар, ашаганнан соң ярты сәгать үткәч, 2 шәр аш кашыгы эчәләр.

17 гыйнвар (дүшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,14.33 сәгатьтә калка, 8.55 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.45 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

18 гыйнвар (сишәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,15.44 сәгатьтә калка, 9.18 сәгатьтә бата. 2 сәгать 48 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 7.49 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Радикулит интектерсә

Радикулит интектергәндә, махсус шулпа ашау файдалы. Бер бәрәңгене яхшылап

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

юып, мөмкин кадәр вак итеп турыйлар, 3 л суда сүрән утта 1 сәгать пешерәләр. Аннары күп итеп вак туралган петрушка, укроп, кинза, сельдерей салалар да, 1-2 минуттан сүндерәләр. Мондый ашны 7-10 көн рәттән ашарга кирәк.

19 гыйнвар (чәршәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 17.02 сәгатьтә калка, 9.35 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.52 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Безләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

20 гыйнвар (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 18.23 сәгатьтә калка, 9.48 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 7.55 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Өрек сихәте

Абрикос согы организмда тоз әйләнешен яхшырта һәм шуңа бәйле рәвештә йөрәк эшчәнлеген нормага сала. Кан басымы югары булган кешеләргә өрек ашарга кирәк. Көнгә 100-150 грамм күрәгә ашау йөрәк аритмиясе һәм ишемия авыруыннан бик файдалы. Тәмәке тартасы килгән чакта бер күрәгә ашап кую тарту теләген бетерә. Эчәкләрнең кыскаруын яхшыртып, өрек эч катудан саклый. Тик менә симерү һәм шикәр чиреннән интегүчеләргә әлеге җимешне чикләнгән күләмдә генә куллану зарур. Шулай ук ашказанында җәрәхәт булган кешегә дә өрек ашарга киңәш ителми. Шешенкелекне бетерү үзлегенә бәйле рәвештә, өрекнең куе төнәтмәсе - йөрәккан тамырлары системасын дәвалаганда алыштыргысыз чара.

21 гыйнвар (җомга). ***Җөмәдел ахир аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,19.44 сәгатьтә калка, 9.58 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.59 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

Карабодайлы десерт

150 г карабодай ярмасы, 200 г күрәгә, 300 г эремчек, 1 йомырка, 2 аш кашыгы бал кирәк. Карабодайны пешерәләр. Күрәгәне кайнар су белән юып, яртысын блендерда издерәләр, яртысын саламлап турыйлар да, кабат икесен бергә кушалар. Эремчекне бал һәм йомырка кушып яхшылап болгаталар (баллырак кирәксә, 1-2 аш кашыгы шикәр өстәргә була), аннары карабодайны да кушалар. Табаны атланмай белән майлап, сохари оны сибәләр, эремчекле карабодайның яртысын тигезләп җәяләр, өстенә күрәгәне сылап, аннары калган эремчекле масса белән каплыйлар. Форманы фольга белән яхшылап ябалар, 170 градуслы мичтә барлыгы 25 минут пешерәләр (15 минуттан соң фольгасын ачалар). Суынгач, өстенә шикәр оны сибәләр.

Шигърияттә Разил Вәлиев

(Ахыры. Башы 6 нчы биттә).

Синең күзләр төсле сагышлы төн,
Синең шәүләң кебек ялгызлык.
Кайт син миңа. Уртак ялгызлыкны
Гөрләвектә бергә агызыйк.
(«Кайт син миңа»)

Мәхәббәт дигән олы хис кешелек тормышында бөек могҗизалар ясаган. Әдәбиятта Фәрһад батырлыкларын гына искә төшерик. Реаль тормышта да андый мисаллар аз түгел. Разилнең лирик каһарманы да гайрәт һәм тәвәккәллеккә әзер тора:

Көз сагышы миңа күчә, дисең...
Телисеңме? – Хәзер яз ясыйм!
Чәчәк белән күмәм йөрәгеңне –
Мәхәббәтнең алсу вазасын.
(«Сине озатканда»)

Метафорик сурәт биредә өр-яңа һәм гаять тә нәфис. Дәүләт эшлеклесе булган шагыйрьдә Ватан, милләт һәм батырлык төшенчәсе янәшә йөри. Мәзкүр каләм иябездә әлеге тема эзлекле рәвештә һәм үзенчәлекле сурәтләрдә яктыртыла. Патриотик батырлыкны ул кешелекле хискә төрә белә:

Кабереннән күтәрелгәнме ул,
Җимереп чыккан мәллә төрмәне?!
...Һәйкәл булып тәне кайткан илгә,
Мәңгелек ут булып – йөрәге.
(«Мәңгелек ут»)

Батырлык, фидакярлек темасын күтәргәндә, шагыйрьнең күз алдында Җәлил сыны пәйда була. Яңа гына булып үткән вакыйгалардан ул, тарихка тирәнәеп, драматик ассоциацияләр ясый. Милли музеебызда дөрләгән янгын уңаеннан үтә җитди гомумиләштерүләргә килә, ижади ачышлар ясый. Әлеге вакыйга аны милләт язмышындагы фаҗигаләр, тетрәнүләр хакында уйлануга этәрә:

Безнең тарих ничә тапкыр янып
Күтәрелгән көлдән, күмердән,
Патшалардан чыккан янгыннарны,
Утка кереп, халык сүндергән.
Янәшәдә – Җәлил. Кул – богаулы,
Күзләрендә – халкым газабы,
Богауларын өзеп ташланыр күк...
Саклар өчен уттан Казанны.
(«Музейда янгын»)

Шагыйрь, гарасатлы вакыйгаларның афәт тирәнлеген ачу өчен, бәйрәм һәм сугыш антитезасын ала. Европа һәм ил өстенә килгән канлы өермәне ул «Кырык беренче ел Сабан туе» шигырендә гәүдәләндерә, бәйрәмнәрнең эчтәлегендәге фаҗигале метаморфозаны чагылдыра.

Европада – канлы Сабан туе,
Җирдә бүген – ялкын, көл исе.
Җиңү байрагыдай янып калды
Сабантуйның биек сөлгесе.

Шагыйрьләрнең барлык әсәрләре үзләре һәм чор турындагы ихлас икърарларыннан тора. Гаять үзенчәлекле һәм кабатланмас сыйфатларга ия булса да, Разил иҗаты да монда чыгарма була алмый. Ул да барлык шигырьләрендә дә дөньяга үзе һәм дәвере турында сөйли. Без югарыда күздән кичереп узган шигырьләрдә дә бу шулай. Әмма шагыйрьнең үз карашларын ачыграк чагылдырган һәм шәхсән үзенә генә караган шигырьләре бар:

Кеше атлы нәни бер кыйтга мин...
Матурлык бар миндә, батырлык.
Күпме тырышсаң да булмый мине
Хәят диңгезендә батырып!
(«Кеше»)

Лирик каһарманның үз-үзен күрүе һәм үзенә ышануы әнә шундый. Шигырьдәге метафорик төсмер һәм гайрәт рухы гомуми-абстракт яссылыкта гына калмыйдыр, чөнки шагыйрьне хәят диңгезендә батыру омтылышлары шактый булып алды. Аның дошманы булуда да уңай мәгънә күрүе юкка түгел. Монда, күрәсең, парламенттагы эшчәнлегенең дә роле бардыр, чөнки гел «оппозиция кирәк», «оппозиция кирәк» дигән сүзләр яңгырый. Менә Разилнең диалектик фикерләвен чагылдырган бер шигыре:

...Дошманыма карап юлга салам,
Үзгәртәм мин тормыш агышын.
Ул булмаса, каян белер идем:
Кайсы дөрес, кайсы ялгышым.
(«Минем дошманым»)

Үзгәрү дигәннән, Разилнең хрестоматик мәгънәгә ия шигырьләрендә үзгәрү идеясе ассызыклана. Бу тикмәгә түгел. Үзгәрү, яңару ихтыяҗы аның туктаусыз эзләнүләрен күрсәтә. Шушы дәрт, шушы иман аңарда үз-үзен кабатлауның булмавына, күрәсең, төп шарттыр. Башкаларны кабатлау да юк.

Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам,
Матурлыкны күреп тезләнәм.
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса
Үзем үзгәрәм.

Разил Вәлиев шигърияте, – гомумән, көчле идея-фәлсәфи егәргә ия, кешегә ярдәм, дөнья көтү өчен кыйммәтле гыйбрәтләргә бай, җырлап торган төзек, камил ритмлы, аһәңле рифмаларга корылган зур сәнгати дөнья ул. Безнең хәзерге талантлы һәм кабатланмас үзенчәлекле шагыйрьләребез сафында аның да матур һәм мәртәбәле урыны бар. Бу зур иҗатны махсус укып өйрәнергә алынгач, минем игътибарны Марсель Галиевнең шагыйрьнең күптомлыгына язылган күләмле кереш мәкаләсе җәлеп итте. Үзе дә шагыйрь булган зат сафташының шәхес һәм иҗат дөньясын киң һәм тулы итеп ачкан. Шунлыктан әлеге язмама йомгак итеп, аның Разил хакындагы сүзләрен китерик.

«Ни генә булмасын, аңа халкыбыз күз уңында, заманыбызның мәртәбәле шәхесе, әдибе булып яшәү һәм яшьнәү бәхете бирелгән».

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,
филология фәннәре докторы.

Тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

14 гыйнвар – «Исәнмесез?!.» (М.Гыйләҗев).
15 гыйнвар – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
16 гыйнвар – «Өйләнәм. tat» (И.Зәйниев).
18 гыйнвар – 14.00 – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин). 19.00 – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
19 гыйнвар – 14.00 – «Бию пәрие» (И.Зәйниев). 19.00 – «Килмешәк» (С.Гаффарова).
20 гыйнвар – «Тормышмы бу?» (Г.Исхакый).
21 гыйнвар – «Санаулы кичләр» (А.Володин).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

14 гыйнвар – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
15 гыйнвар – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
16 гыйнвар – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).
17 гыйнвар – «Нәзер» (Т.Миңнуллин).
18 гыйнвар – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
19 гыйнвар – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
20 гыйнвар – Зөлфирә Зарипованың иҗат кичәсе.
21 гыйнвар – «Галәм. Әгъләм» (М.Әгъләмов).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

14 гыйнвар – «Мио, минем Мио» (А.Линдгрен).
16 гыйнвар – «Озын-озак балачак» (М.Кәрим).
19 гыйнвар – 13.00 – «Бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.30 – «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла).
21 гыйнвар – Премьера. «Арыну» (Т.Кулов, А.Әхмәдиев).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

14 гыйнвар – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
15 гыйнвар – зур залда – «Подарки Деда мороза» (Н.Абрамцева). Кече залда – «Әлфия» (И.Зәйниев).
16 гыйнвар – 10.00 – «Один день из жизни улитки». 12.00, 14.00 – «Снежная королева» (Г.Х.Андерсен). 13.00 – «Кыш бабай бүләкләре» (Н.Абрамцева).
18 гыйнвар – SHURALE: яңа фантазия (Ф.Яруллин музыкасы, И.Зәйниев либреттосы).
19 гыйнвар – «Мырау батыр» (Н.Исәнбәт).
20 гыйнвар – «Снежная королева» (Г.Х.Андерсен).
21 гыйнвар – 10.00, 12.00 – «Идет коза рогатая» (М.Протасова). 18.30 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

16 гыйнвар – Александр Гиндин концерты (фортепиано).
20 гыйнвар – Татарстан дәүләт халык музыка уен кораллары оркестрына кушылып С.Осокин (аккордеон) һәм В.Мясоедов (волынка, дудук, жалейка, окарина, сопилка) уйный.
21 гыйнвар – Алиса Мамина концерты.

Борынгылар әйткән сүзләр

(Мәкальләр һәм әйтемнәр тарихыннан)

Хуҗи МӘХМҮТОВ

(Дәвамы. Башы 2021 елның 40-42 нче саннарында).

БҮРЕНЕҢ АВЫЗЫ КАН БУЛСА ДА, ЙОСЫФНЫ УЛ АШАМАГАН

Янә «Бүренең авызы ашаса да – кан, ашамаса да – кан» диләр. «Бер яманаты чыккан кешегә нахак бәла тагу җиңел» дигән мәгънәдәге гыйбарәләр.

Йосыф һәм аның туганнары турындагы сюжет дөнья мәдәниятендә бик борынгыдан һәм төрле чыганакларда чагыла килә. Ә татар халкына ул, беренче чиратта, Коръәндәге «Йосыф» сүрәсе һәм XIII йөз болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы аша яхшы таныш. Кол Гали әсәренең бездә халыклашкан кырыкка якын варианты бар. Алар, башлыча, «Йосыф китабы» дигән исем астында билгеле.

Хәзер «Йосыф китабы»ннан югарыдагы гыйбарәләрнең эчтәлеген ачкан кайбер өзекләр белән танышып үтик:

«Якуб пәйгамбәрнең унбер улы, бер кызы – барысы унике баласы була. Шул унбер улы арасында иң сөеклесе Йосыф икән...

Бервакыт Йосыф төш күрә, төшен әтисенә сөйли:

– Әтием, мин бер төш күрдем, миңа унбер йолдыз сәҗдә кылды, – ди.

Әтисе Йосыфка мондый сүз әйтә:

– Йосыф, балакаем, бу төшеңне башка туганнарыңа сөйли күрмә... Бу төшеңне мин болай юрыйм. Син һәр туганнарыңа караганда да бөек кеше булырсың. Менә синең унбер туганың сиңа сәҗдә кылырлар, синең алдыңда тезләнеп торырлар...

Бу сүзләрне ишеткән бер туганы тыңлап торган. Ул моны башка туганнарына сөйләп биргән:

– Әти Йосыфны безгә караганда артык ярата, без һәммәбез аңа сәҗдә кылабыз икән.

Башка туганнары бу хәбәрне ишеткәч көнләшеп калалар:

– Без ауга барган вакытта, Йосыфны үзебез белән алып барыйк та аны үтерик, – дип сөйләшәләр.

Әтиләренә килеп әйтәләр:

– Әти, без кырга, болынга ауга чыгабыз. Йосыфны да үзебез белән алырга уйлыйбыз.

– Юк, мин рөхсәт итмим, – ди аталары.

– Ул кечкенә әле, арыр...

Теге туганнары, ничек булса да ялынып, әтиләрен күндерәләр.

Шуннан олы ир туганнары һәм Йосыф, авылны чыгып, сахрага җиткәннәр. Йосыфны бер тирән кое янына алып килгәннәр, күлмәген салдырып, үзен кое төбенә ташлаганнар. Очып барган бер карганы үтереп, аның канын Йосыф күлмәгенә сөрткәннәр дә әтиләре янына кайтып киткәннәр. Әтиләре, Йосыф кайтмавын күргәч, бик куркынган.

– Кая китте Йосыфым? Кайда калды? Нигә алып кайтмадыгыз? – дип сораша башлаган.

Туганнары алдан килешенгәнчә сөйләп биргәннәр: «Без ауга киткән идек, ераграк киткәнбез. Кайтуыбызга Йосыфны бүре ашап киткән. Менә канлы күлмәге генә калган», – дигәннәр».

ИКЕ АЯГЫННАН (АЯКЛАРЫННАН) ТОТЫП СЕЛКЕСӘҢ, ӘЛИФ (БЕР ХӘРЕФ) ТӨШМӘС

Мәгънәдәше: Эчен ярсаң, әлиф чыкмас.

Укымышсыз, грамотасыз, надан кешеләргә карата әйтелә торган гыйбарә. Ягъни андыйлар хәтта әлифбаның (бу очракта гарәп алфавитының) иң беренче һәм иң гади язылышлы хәрефен дә белмиләр.

«[Галимҗан Ибраһимов]:

– Бүген вокзалда мин берничә татар ханымнарын күрдем. Башларында калфаклары булмаса, аларны рус ханымнарыннан аерырлык түгел иде. Димәк... – дип сүз башлаган иде, Габдулла әфәнде тотнаксызланып кунагының сүзен бүлдерде.

– Алар бит тышкы, ясалма кыяфәт белән генә күзгә күренергә тырышалар, ә үзләренең аякларыннан тотып селексәң, белем түгел, әлиф хәрефе дә төшмәс!» (Гөлсем Мөхәммәдова. Эзләнүләр).

Ачы көлүле бу әйтелмәне шагыйрь Зиннур Мансуров тарихи бер фактка бәйләп файдалана. Танылган китап басу остасы, озак еллар Казан һәм Петербург матбагаларында эшләгән Шаһингәрәй Бикколовның (1846-1920) шөһрәте Ташкентка да барып җитә. Аны бирегә эшкә чакыралар. Шул рәвешчә, Шаһингәрәй үзбәк милли матбагасына нигез салуга да зур өлеш кертә.

...1881 ел. Ш.Бикколов, аның хезмәттәшләре Г.Яушев һәм Б.Биктимеров, өчәүләп, Ташкентка сәфәргә кузгала. Үзләре белән күп кенә типография кирәк-яраклары да алалар. Юл озын, хәвефле, юлбасарлар белән очрашу куркынычы да бар. Хәер, ул җаһилләрнең матбагачылар алып бара торган йөккә исләре бик китмәс иде дип уйларга кирәк... Шушы ихтимал ситуацияне күз алдына бастырып, шагыйрь әлеге әйтелмә ярдәмендә сүз уйната:

«Озын-озак сәфәрләрдә йөртә, диләр,
берен хыял, берен нужа, берен мал.
Унлаган пот хәреф тәяп юлга чыккан
Шаһингәрәй, Габделлатыйп,
Борынгал.
Зур хәзинә икәнлеген баскыннарга
аңлаталмас хәтта «зирәк» курбашы.
Хәрефләрне учка алып әйтер генә:
«Пугачка» да ярамый бит кургашы...»
Ә үзенең, кем әйтмешли, ике аягын
Тотып селек – бер хәреф тә төшмәстер.
Кургашынның кайчан көчле икәнлеген
Бик тә яхшы аңлап бара өч фәкыйрь». -
(Ваем. – Казан, 1988. -Б. 63).

ДИСБЕНЕҢ МӘРЬЯМ АНАСЫ

Дисбе (яки тәсбих) – муенса кебек итеп җепкә тезелгән төймәләр. Зикер әйткәндә, ягъни Аллаһыны зурлау, мактау, аңа шөкер кылу сүзләрен (Аллаһе әкбәр, сөбхан Аллаһы, әлхәмде лилля) кабатлаганда, шул төймәләрне берәмберәм тарта баралар.

Тәсбих дини максатларда б. э. к. X гасыр тирәсендә Һиндстанда килеп чыккан дип уйланыла. Аны борынгы греклар да кулланган. Тәсбих тарту католикларда, буддачылар да динен тотучыларда да бар.

Мөселман тәсбихләре, Аллаһының гүзәл исемнәре санынча, 99 төймәле итеп ясала. Алар 33 әр төймәдән торган өч бүлемгә аерыла. Бер төр дога сүзен 33 мәртәбә кабатлагач, икенчесенә күчү кирәклеген искәртү өчен бүлемнәр арасына зуррак төймә куела. Аны тәсбих анасы (яки мулласы) диләр. Тәсбих җебенең ике очын беркетеп торучы озын төймәне дисбенең Мәрьям анасы (яки имамы) дип йөртәләр. Гайсә пәйгамбәрнең анасы Мәрьям исеме белән аталуы бу төймәнең башка төймәләр арасындагы хөрмәтле урынын искәртеп тора.

«Дисбенең Мәрьям анасы» әйтелмәсе телебездә күчерелмә мәгънә дә хасил иткән. Ул бертөрле, бериш әйберләр (күренешләр, затлар һ. б.) теземендә аеруча әһәмиятле урын тота торган әйберне белдерү өчен файдаланыла.

«Толстой вафат!..

Андреев, Максим Горький, Потапенко, Куприн, Сологуб, Мережковский, Григорий Петров, Скиталец вә гайре, вә гайре бөтен Русиянең мөхтәрәм мөхәррирләреннән тезелгән мөбарәк тәсбихнең очындагы... Мәрьям анасы, яки имамы, өзелде» (Габдулла Тукай. Әсәрләр: дүрт томда. – Казан, 1977. -Т.4.-Б. 82-83).

«...Беренче бүлекне... «Болгар вә Казан төрекләре» әсәре ачып җибәрә. Китапта урнаштырылган һәрбер бабны шартлы дисбенең төймәләре дип кабул итсәк, монысы аның нәкъ «Мәрьям анасы» булыр, чөнки сурәтләнгән вакыйгаларның әһәмияте һәм колачы ягыннан китапның «умыртка сөяген», безнеңчә, нәкъ шул тәшкил итә» (Равил Әмирхан. Иманга тугрылык. – Казан, 1997. – Б. 84).

«Татарча газета-журналларның «Мәрьям анасы», «шаһы», «йөзек кашы», һичшиксез, «Казан утлары»дыр. Ул 1922-1985 еллар аралыгында «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты» исемнәре астында чыккан. Инде менә 40 елдан артык хәзерге атамасын йөртә. Исем, графика-алфавит үзгәреп килсә дә, аның мәсләге, кыйбласы тотрыклы калган: ул да булса үз халкына тугрылыклы хезмәт итү, аның барлыгы, теле, яшәеше өчен көрәш» (Хатыйп Миңнегулов. Мең китаптан бер китап //Мәдәни җомга. – 2007. – 2 март).

«КӘФ»ЕН «КӘФ»КӘ, «КАФ»ЫН «КАФ»КА КИТЕРҮ

Гарәп язуына нигезләнгән татарча әлифбада кәф (кяф) һәм каф сүзләре нечкә һәм калын к авазларын белдерүче хәрефләрнең исемнәре булып торалар. Бу ике хәрефне кирәкле урында, тиешле сузыклары белән куллана белү, татар телендә мөһим роль уйнаучы сингармонизм кагыйдәләрен нечкә сиземләүне һәм төгәл үтәүне таләп итә.

Инде әйтелмәнең күчерелмә мәгънәсенә килсәк, әдәби телебездә ул «эшне бик пөхтә итеп, җиренә җиткереп башкару» дигәнне аңлата. Үз көнкүрешебездән тегем-салымнан алынган синонимы – җөен җөйгә китерү.

Әйтелмә, бездә гарәп язуы кулланылыштан чыккач та, өлкән буын әдипләр телендә әле байтак сакланып килде.

«Әйе, аның һәрвакыт эше бар. Шуның өстенә, ул эшне һич тә тартырга-сузарга, соңга калдырырга ярамый, һич! Аннары аны кәфен кәфкә, кафын кафка китереп, бөтен ягыннан килештереп, тәмам җиренә җиткереп эшләргә кирәк. Шунсыз булмый!» (Гомәр Бәширов. Тынгысыз җан: Хәмит Ярмигә 60 яшь // Совет әдәбияты. – 1964.-№ 5.-Б. 112-113).

(Дәвамы бар).

Яңа закон әзерләнә

Финляндия Хөкүмәте яңа закон әзерли, ул хезмәттәшләргә һәркайсының күпме акча алып эшләвен белүне рөхсәт итәчәк. Кабул ителгән очракта закон 2023 елның апреленә, ягъни илдәге яңа парламент сайлауларына кадәр гамәлгә керәчәк. Әлеге чара хезмәт мөнәсәбәтләрендәге женси тигезсезлекләрне юкка чыгаруны максат итә. Премьер-министр Санна Марин фикеренчә, бу закон ирләр һәм хатын-кызларның эш хакларындагы аерманы киметү мөмкинлеген бирәчәк. Хәзер Финляндия хезмәт хакларының тигезлеге дәрәҗәсе буенча Икътисади хезмәттәшлек һәм үсеш оешмасы илләре арасында 37 нче урында тора – 2020 елда илдә хатын-кызларга ирләрнекенә караганда 17,2 процентка кимрәк эш хакы түләнгән. БМО мәгълүматлары буенча, гәрчә хезмәткә тигез түләү принцибы күп кенә халыкара һәм илкүләм документларда теркәлсә дә, хәзерге вакытта дөньяда эш хакын билгеләүдә женси аерма уртача 23 процент тәшкил итә – барлык илләрдә дә хатын-кызлар ирләрдән азрак акчага эшли. Һичшиксез, Финляндия Хөкүмәте әзерли торган канун җәмәгатьчелек таләбенә җавап бирә, әмма дөньяда әлеге проблеманы закон дәрәҗәсендә хәл итүнең күпкә нәтиҗәлерәк мисаллары да бар. Мәсәлән, 2018 елда Калифорния “Хезмәткә тигез түләү турында” закон кабул иткән, ул һәркемгә гадел эш хакы билгеләүне күздә тота. Мондый закон илнең кайбер башка штатларында да кабул ителгән. Россиядә исә хезмәткә түләүдә женси аерма 27,9 процент тәшкил итә, бу дөньядагы уртача күрсәткечтән шактый артык.

(“РБК”).

Келәмнәр патшасы

Дөньяда иң зур келәмнең мәйданы 5627 квадрат метр тәшкил итә. Аны Иранда 1200 тукучы бер ел буе кулдан тукыган, аларның һәркайсына 1 миллион 160 шар мең төен ясарга туры килгән. Иңе – 48, буе – 133 метрлы искиткеч матур йон келәмнең авырлыгы 48 тоннага тәңгәл. Аны Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Әбү-Даби шәһәрендәге берьюлы 7 мең кеше сыйдырышлы Зәед мәчете өчен махсус тукыганнар. Тугыз аерым кисәкне самолетта алып килеп, бизәкләрен туры китереп, мәчет эчендә бер-берсенә теккәннәр. Келәм 8,2 миллион долларга төшкән, тукучыларның барысына бергә 2 миллион 300 мең доллар акча түләнгән, алар аны тигезләп бүлгән. Фарсы келәмнәре дөньяда иң матурлардан санала, планетадагы барлык келәмнәрнең дүрттән өчесе Иранда җитештерелә. Гигантлык белән мавыгучы гарәп шәехләре исә тагын берничә зур келәмгә заказ биргән. Тарихта мондый гигант тукучылык җәүһәрләре мәгълүм инде: берничә тонна авырлыктагы легендар “Язгы” келәм фарсыларның римлеләрне җиңеп Гарәп ярымутравын яулавы хөрмәтенә иңе - 30, буе 122 метрлы итеп тукылган булган. Уникенче гасыр уртасында Персиягә гарәпләр һөҗүм иткәч, солдатлар, затлы келәмне кискәләп, ганимәт (трофей) итеп үзләре белән алып киткән.

(“Goldengod.ru”).

Тизлекнең сере нидә?

Статистика бөтен нәрсәне белә. Спорт статистикасы исә дөнья ярышларындагы барлык казанышларны туплап бара. Мәсәлән, алар санап чыгарганча, 2010 елда планетабызда барлыгы 156 халыкара марафон йөгереше булган, шулардан 126 сында Кения спортчылары җиңгән. Алай гына да түгел, җиңүчеләрнең күбесе календжин кабиләсеннән икән. Әлеге кабиләдә барлыгы 3,5 миллион кеше исәпләнә, төп шөгыльләре – терлекчелек. Дөньяда иң тиз бу халыкның сере нәрсәдә соң? Галимнәрнең кайберләре, эш аларның тән төзелешендә, дип саный – янәсе, календжиннарның балтыр һәм тубыклары нечкә. Икенче берәүләр кениялеләрнең искиткеч чыдамлыгы аларның яшәү рәвеше белән бәйле, дип уйлый: терлек асрау күп хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә, көтүчеләргә тәүлегенә дистәләрчә чакрым юл үтәргә туры килә. Диетологлар исә тизлек серен туклану үзенчәлекләреннән эзли, тик йөгерешчеләр бернинди махсус диета да тотмый, кайчан ашыйсылары килсә, шунда ашый. Төп ризыклары – кукуруз боткасы. Тагын бер теория буенча, Кения йөгерешчеләренең организмы кислород белән яхшырак туендырылган, чөнки календжин кабиләсе диңгез өсте тигезлегеннән 2 мең метр биектәрәк урнашкан таулы җирдә яши. Әмма скептиклар бу теорияне бәхәслегә саный, чөнки тагын да югарырак тауларда яшәүчеләр дә бар бит, ә алар шулай тиз йөгерми. Егерменче гасыр ахырында Кения йөгерешчеләрен Копенгагендагы Мускулларны тикшерү фәнни үзәгендә дә өйрәнгәннәр. Галимнәр, кениялеләргә йөгерүдә өстенлек генетика буенча бирелә, дигән нәтиҗәгә килгән.

(“Мир новостей”).

Маңгайга язылган язмыш

Никадәр баш ватсалар да, галимнәр һаман төшенә алмый: кемгәдер гомере буена уңыш елмая, кемгәдер исә кайгы өстенә хәсрәт килеп кенә тора. Эше уңучан кешеләр арасында иң танылганы – Уинстон Черчилль. Менә бер мисал. 1941 елда ул, сугыш кырыннан зенит батареяларын тикшереп кайтканда, һәрвакыттагыча машинасының алгы утыргычына түгел, ә артка утыра. Аңа әчке тавышы шулай куша. Машина алдына бомба төшеп шартлый да, Черчилль урынына утырган адъютанты шундук һәлак була. Америка физигы Роберт Вуд та гел җай килеп торучан кеше була. Бервакыт ул яшенле яңгырдан соң йөреп кайтырга җыена, тик кинәт кызының тавышы ишетелеп, аңа туктарга куша. Галим бер ун секундлап туктап тора, аннан соң юлын дәвам итмәкче була. 2 генә адым алдарак җиргә яшен ата. Әгәр туктап тормаса, Вудны һичшиксез яшен сугачак була. Шулай итеп, кызының тавышын ишеттереп, фәрештәләре физикны үлемнән коткарып кала. Ә менә Авраам Линкольнны язмыш гел рәнҗеткән. 31 яшендә ул бөтен байлыгын югалткан, 32 яшендә судта оттырган, 34 яшендә кабат хәерчелеккә төшкән, 35 яшендә яраткан кешесенең гомере өзелгән, 36 яшендә нервлары какшаган. 38 яшендә сайлауда оттырган, ике тапкыр конгресска, ике тапкыр сенатка эләкмәгән, аннары АКШ вице-президенты була язып калган. Һәм, ниһаять, АКШ Президенты итеп сайланган! Тик дүрт елдан соң театрда спектакль караганда башына пистолеттан атып үтерелгән.

(“The Mirror”).



Җир тирәли - җәяү

2000 елга кадәр Жан Беливо ике баласы һәм хатыны белән Канаданың Монреаль шәһәрендә яшәгән, үз бизнесы белән шөгыльләнгән. Фирмасы бөлгәч, җитди психологик кризис кичергән, шунлыктан җәяүләп Нью-Йоркка киткән. Максатына ирешкәч, юлын дәвам итәргә булган: бөтен Американы, төньяктан көньякка бөтен Африканы һәм көнбатыштан көнчыгышка Европаны кичкән. Көньяк Кореядән – Японияга, аннары Индонезия, Австралия һәм Яңа Зеландиягә киткән, шуннан самолет белән өенә очкан. Шул рәвешле, ул 11 ел буе дөнья гизгән. Берничә авиаочышны һәм диңгездән баруны санамаганда, Беливо гел җәяү йөргән, бөтен әйберсе өч көпчәкле арбасына сыйган. Юлга чыкканда 4 мең Канада доллары булган, шул акчасы беткәч, бөтен кием-салым, ризык белән юлында очраган яхшы кешеләр тәэмин иткән, хатыны җыйган хәйрия акчасын ул бик саклап кына тоткан. Жан Беливо 11 ел да 2 ай эчендә барлыгы 64 ил буйлап 75554 километр юл үткән, 54 пар аяк киеме тузырган, 1600 гаиләдә кунак булган. Хәтта дүрт Нобель бүләге иясен дә очраткан, шулардан берсе Нельсон Мандела аңа: “Дөньяга сезнең кебек кешеләр бик кирәк”, – дигән. Өенә кайткач, “Үземне эзләгәндә” дигән китап язган.

(“Moya-planeta.ru”).

*Газета өчен
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.*

Дүшәмбе

17 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2, ЯКИ КУНАК АШЫ КАРА КАРШЫ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Акыл баттл» һәм «Сәйлән».
16.30 Хоккей. «Барыс» - «Ак Барс». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.00, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40 «Башваткыч». 6+
9.50 «Яшәргә дә әле, яшәргә». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 Хоккей. «Барыс» - «Ак Барс». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
23.05 «Башваткыч». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «Город.». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «В ЛЕСАХ СИБИРИ». 16+
14.40 «Наукограды». 12+
15.10 «Это лечится». 12+
15.40 «Инсайдеры». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ГУРЗУФ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.00 Вечерние новости.
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ИЩЕЙКА». 16+
23.35 «Познер». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Николай Миклухо-Маклай.
7.35, 18.35 «Тайны Нила».
8.35 «Первые в мире».
8.50, 15.50 «ДОЛГАЯ ДОРОГА В ДЮНАХ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Времена года. Четыре интервью с зимой».
12.25 Линия жизни. Александр Клюквин.
13.25 «Забытое ремесло».
13.45 «Леонид Канторович».
14.30 «История русского быта».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Испания. Теруэль».
17.05 «Запечатленное время».
17.35 К 100-летию Московской филармонии. Михаил Плетнёв и Большой симфонический оркестр Центрального телевидения и Всесоюзного радио.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 «Человек с неограниченными возможностями».
21.35 «Сати. Нескучная классика...»
22.20 «РОССИЯ МОЛОДАЯ».
23.50 «Магистр игры». «Житие великого грешника. Гофман. Гоголь. Достоевский».

«НТВ»

5.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС». 16+

Сишәмбе

18 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2, ЯКИ КУНАК АШЫ КАРА КАРШЫ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Оныта алмыйм...»
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Ватандашлар». 12+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Чёрное озеро». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40, 16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Тамчы-шоу». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «КОРСИКАНЕЦ». 12+
14.40 «Наукограды». 12+
15.05 «Клинический случай». 12+
15.30 «Погоня за вкусом». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.00 Вечерние новости.
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ИЩЕЙКА». 16+
22.35 «Док-ток». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 18.35 «Тайны Нила».
8.35 Цвет времени. Павел Федотов.
8.50, 15.50 «ДОЛГАЯ ДОРОГА В ДЮНАХ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Страницы большого искусства. Рассказывает Ираклий Андроников». 1966 г.
12.35, 22.20 «РОССИЯ МОЛОДАЯ».
13.45 «Игра в бисер» «Алан Александр Милн. «Винни- Пух».
14.30 «История русского быта».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
17.05 «Запечатленное время».
17.35 К 100-летию Московской филармонии. Легендарные концерты в историческом зале. Первый сольный концерт Муслима Магомаева.
19.45 Главная роль.
20.35 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Искусственный отбор.
21.35 Вспоминая Сергея Соловьева. «Белая студия».
23.50 XX век. «Прежде всего театр. Владислав Стржельчик».

«НТВ»

5.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС». 16+

Чәршәмбе

19 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2, ЯКИ КУНАК АШЫ КАРА КАРШЫ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00, 0.50 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Таяну ноктасы». 16+
14.45 «Шома бас» һәм «Калеб».
15.30 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
17.00 Хоккей. «Салават Юлаев» - «Ак Барс». 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.00 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан-ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 19.30, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
17.00 Хоккей. «Салават Юлаев» - «Ак Барс». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ВОЗВРАЩЕНИЕ В БУРГУНДИЮ». 16+
15.00 «Эпидемия». 12+
15.30 «Зов крови». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.00 Вечерние новости.
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ИЩЕЙКА». 16+
22.35 «Док-ток». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Прежде всего театр. Владислав Стржельчик».
12.05 Лето Господне. Святое Богоявление. Крещение Господне.
12.35, 22.20 «РОССИЯ МОЛОДАЯ».
13.45 «Тамара Макарова. Свет Звезды».
14.30 «История русского быта».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 Спектакль «Дядя Ваня».
17.20 Цвет времени. Караваджо.
17.40 К 100-летию Московской филармонии. Легендарные концерты в историческом зале. Ицхак Перельман.
18.35 «Тайны Нила».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Абсолютный слух.
21.35 Власть факта. «Викторианская цивилизация».
23.50 XX век. «Страницы большого искусства. Рассказывает Ираклий Андроников». 1966 г.

«НТВ»

5.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «Поздняков». 16+
23.50 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС». 16+

Пәнҗешәмбе

20 гыйнвар

Вниманию телезрителей! В связи с профилактическими ремонтными работами 20 января с 2.00 до 9.00 передачи телеканала ТНВ и «ТНВ-Планета» не транслируются.

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

9.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2, ЯКИ КУНАК АШЫ КАРА КАРШЫ». 12+
10.00, 23.15 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.25 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.30, 19.30, 21.45 Новости Татарстана. 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
17.00 «Ком сәгате». 12+
18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Шәймиев». 12+
22.15 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

9.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Халкым минем». 12+
19.10 «Шәймиев». 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
23.05 «Кәмит Җәвит». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ВЕЧНОСТЬ». 16+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Вокруг света. Места силы». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.00 Вечерние новости.

18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ИЩЕЙКА». 16+
22.35 «Большая игра». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 18.35 «Тайны Нила».
8.35 Цвет времени. Леон Бакст.
8.50 «ПРОСТИ НАС, САД...»
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Махмуд Эсамбаев».
12.05 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
12.35, 22.20 «РОССИЯ МОЛОДАЯ».
13.45 Абсолютный слух.
14.30 «История русского быта».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «По пути к коми-зырянам».
15.50 Спектакль «Дядя Ваня».
17.05 «Запечатленное время».
17.35 К 100-летию Московской филармонии. Легендарные концерты в историческом зале. Элисо Вирсаладзе и Джансуг Кахидзе.
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Да будет!»
21.35 «Энигма. Соня Йончева».

«НТВ»

5.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

21 гыйнвар «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 18.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2, ЯКИ КУНАК АШЫ КАРА КАРШЫ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+
23.10 «ОДНОКЛАССНИЦЫ» и «ОДНОКЛАССНИЦЫ. НОВЫЙ ПОВОРОТ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 14.00, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 16.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «РАЗВОД ПО-АМЕРИКАНСКИ». 16+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Это реальная история». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.00 Вечерние новости.
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.30 «Голос - 10 лет». Юбилейный концерт в Кремле. 12+
23.40 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35 «Тайны Нила».
8.35 Цвет времени. Леонид Пастернак.
8.45 «ПРОСТИ НАС, САД...»
10.20 «АКТРИСА».
11.50 «Борис Покровский. Недосказанное».
12.45 «РОССИЯ МОЛОДАЯ».
13.50 Власть факта. «Викторианская цивилизация».
14.30 «Павел Флоренский. Русский Леонардо».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Соня Йончева».
16.15 «НЕМУХИНСКИЕ МУЗЫКАНТЫ».
17.25 К 100-летию Московской филармонии. Легендарные концерты в историческом зале. Государственный академический ансамбль народного танца им.Игоря Моисеева. «Кудесники танца».
18.45 «Царская ложа».
19.45 Линия жизни.
20.40 «МАКАРОВ».
22.20 «2 Верник 2».
23.30 «КОЛЛЕКЦИОНЕР».

«НТВ»

5.20 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.20 «Своя правда». 16+

Шимбә

22 гыйнвар «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.35 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Әйләнә дөнья». 6+
15.00 «Шәймиев». 12+
17.00 «Әдәби хәзинә». 6+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «С ВЕЩАМИ НА ВЫЛЕТ!» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Шәймиев». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 Равил Харисовны искә алу кичәсе. 6+
22.10 Спектакль «Гаугалы гаилә». 12+
23.50 «60 яшь тә узып китте, 61 килеп житте». Виталий Агаповның юбилей кичәсе. 12+

«ЭФИР»

5.00 «Наукограды». 12+
5.30 «БОЛЬШАЯ НЕФТЬ». 16+
7.00 «Лео и Тиг».
8.00 «Чужие в городе с Дмитрием Губерниевым». 12+
8.50 «ДВЕ ЖЕНЫ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ ПОЗНАЛ БЕСКОНЕЧНОСТЬ». 16+
15.00 «Все, кроме обычного». 16+
16.15 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БЫТЬ АСТРИД ЛИНДГРЕН». 16+
23.10 «ЧЕЛОВЕК - НЕВИДИМКА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00 Новости.
10.15 К 80-летию со дня рождения Валерия Ободзинского. «Вот и свела судьба...» 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 6+
13.25 К 110-летию со дня рождения Кима Филби. «Тайная война». 16+
15.40 «Угадай мелодию 1991-2021». 12+
16.30 «Кто хочет стать миллионером?»
18.05 «Точь-в-точь». 16+
21.00 «Время».
21.20 «Сегодня вечером». 16+
23.05 «НЕ ВСЕ ДОМА». 12+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
12.35 «Доктор Мясников». 12+
13.30 «ТЕОРЕМА ПИФАГОРА». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
20.00 Вести в субботу.
21.00 «ВСЁ, ЧТО ЗАХОЧЕШЬ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Маугли».
8.40 «НЕМУХИНСКИЕ МУЗЫКАНТЫ».
9.50 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.15 "Передвижники. Николай Дубовской».
10.45 «ТРАКТИР НА ПЯТНИЦКОЙ».
12.10 «Первые в мире».
12.25 «Эрмитаж».
12.55 «Дом ученых». Алексей Осадчий.
13.25 «Торжество дикой природы. Национальный парк Биг Бенд».
14.20 «Эффект бабочки».
14.50 «КОШКА БАЛЛУ».
16.30 «Отцы и дети».
17.00 «Энциклопедия загадок».
17.25 «Мой век».
18.15 «Бег». Сны о России».
18.55 «БЕГ».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб шаболовка 37.

«НТВ»

4.55 «ЧП. Расследование». 16+
5.20 «ДУЭЛЯНТ». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.45 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели…». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 Ты не поверишь!. 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

23 гыйнвар «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Гармунлы сәяхәт». Айзат Мәрдәновның иҗат кичәсе. 6+
8.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Хайкю». 12+
9.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Синең өчен». Зәйнәб Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов. 6+
12.00 «Видеоспорт». 12+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.00 Творческий вечер композитора Эльмира Низамова. 6+
15.00 «Юлчы». 6+
16.00, 0.45 «Ком сәгате». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Чёрное озеро». 16+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «В ПЛЕНУ НАДЕЖДЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35, 23.20 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Алдым-бирдем». 12+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Әлфия Айдарская турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе. 6+
16.50 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
17.50 «Кәмит Җәвит». 16+
18.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Концерт «Шурале». 6+
22.55 «Ватандашлар». 6+
23.45 Спектакль «Артист». 12+

«ЭФИР»

5.00, 8.50 «Наукограды». 12+
5.30 «БОЛЬШАЯ НЕФТЬ». 16+
7.00 «Лео и Тиг».
8.00 «Чужие в городе с Дмитрием Губерниевым». 12+
9.20 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БЫТЬ АСТРИД ЛИНДГРЕН». 16+
15.10 «Евромакс. Окно в Европу». 16+
15.45 «ДВЕ ЖЕНЫ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ ПОЗНАЛ БЕСКОНЕЧНОСТЬ». 16+
22.50 «Шерлоки». 16+
23.40 «ОБЪЕЗД». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

4.45, 6.10 «ГАЛКА И ГАМАЮН». 16+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 6+
14.05 «Детский КВН». 6+
15.15 Балет на льду Татьяны Навки «Лебединое озеро». 6+
16.55 Праздничный концерт, посвященный 60-летию Государственного Кремлевского Дворца. 12+
19.10 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.00 «ХРУСТАЛЬНЫЙ». 16+
0.00 «ВИД НА ЖИТЕЛЬСТВО». 16+

«РОССИЯ»

5.20 «ВАРЕНЬКА». 16+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «Парад юмора». 16+
13.30 «ТЕОРЕМА ПИФАГОРА». 16+
17.50 «Танцы со Звёздами». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
8.35 «СЕРДЦА ЧЕТЫРЕХ».
10.05 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.35 «НА ПОДМОСТКАХ СЦЕНЫ».
12.00 Письма из провинции.
12.30 «Глухариные сады».
13.10 Невский ковчег. Теория невозможного. Лев Гумилев.
13.40 «Игра в бисер» «Артур Конан Дойл. «Собака Баскервилей».
14.20 «Архи-важно».
14.50 «КАЖДЫЙ ВЕЧЕР В ОДИННАДЦАТЬ».
16.10 Линия жизни. Михаил Ножкин.
17.05 «Пешком...»
17.35 «Геннадий Селюцкий. Рыцарь танца».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ТРАКТИР НА ПЯТНИЦКОЙ».
21.35 Мария Былова, Алла Михальченко, Ирек Мухамедов, Гедиминас Таранда в балете Юрия Григоровича «Легенда о любви». Большой театр. Запись 1989 г.
23.30 «В тени больших деревьев».

«НТВ»

5.00 «ВО ВЕКИ ВЕЧНЫЕ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.50 «Дачный ответ».
14.00 «НашПотребНадзор». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Звезды сошлись». 16+
21.40 «Основано на реальных событиях». 16+

Урсалабашта Фарук картның таушалган керле киемнән йөрүенә күнеккәннәр инде. Шуңа күрә 23 майда аның өр-яңа шакмаклы күлмәктән булуына очраган һәркем игътибар итә. Гадәттәгечә авылдашларына булышып, бәрәңге утыртышып, җыелган чүп-чарларын чүплеккә ташып узган ошбу якшәмбе 71 яшьлек Ф.Галәветдиновның соңгы көне була. Әйтерсең абзый сикәлтәле тормыш юлын матур күлмәк киеп төгәлләргә уйлаган...

Фарук картның актык көне

Гомер көзендә ялгыз калган Фарук 2008 елда Урсалабашка килеп 1952 елгы Рәисә белән аның өендә тора башлый. Кайбер күргән-белгәннәр әйтүе хак булса, документлары булмаганга, пенсия дә алмый ул. Ләкин авыл җирендә эш бетми, эшче кулларга сорау да бар. Урсалабашта тырыш, эшчән Фарук ярдәменнән бик күпләр файдалана. Бирәүләр акча бирсә, икенчеләре ярты белән түли. Гомумән, аның турында мактап кына сөйлиләр анда, эчсә дә зыянсыз иде, ярдәм итәргә һәрвакыт әзер игелекле кеше булды, диләр.

Шул рәвешле ун ел чамасы ярыйсы гына гомер итә алар. Кыенлыклар 2019 елда, Рәисә аягын сындырып, күрәсең, тиешле ярдәм күрсәтелмәгәнгә, йөри алмый, урын өстендә ята башлагач барлыкка килә. Аңа ярдәм итү өчен хәтта социаль хезмәткәр дә билгеләнә. Ошбу ярдәм нинди булгандыр, әмма дүшәмбе көн буе, сишәмбе төшкә кадәр авыру карчык йортына аяк басучы табылмый. Фарук карт үзе дә, аның һәрвакыт аралаша торган авылдашы Фаил дә күренми.

Сүз уңаеннан 61 яшьлек Фаил Яруллинда (кайбер исемнәр үзгәртелә) тукталып үтик. Ун ел тирәсе элек аерылышкан хатыны, ике малае белән аралашмыйча ялгызы гомер итә ул. Еш кына Әлмәттә яшәүче апасы килеп берничә көн торып йортын тәртипкә салып китә. Фаил элегрәк нефть чыгару өлкәсенә хезмәт күрсәтүче төзү оешмасында эшләгән, 2020 елның җәендә авырып китеп катлаулы операция кичергән, язга таба гына больничныен япкан да, башка эшкә чыкмаган. Җитәкчеләре унай бәяли аны, вазифаларын җиренә җиткереп башкарды, эчеп эшкә чыкмый калган көннәре булса да, эштә исереп йөрмәде, диләр.

Фарук карт белән шешәдәшләр буларак кына аралашмый алар. Гомумән алганда, Фаил эчү ягыннан тотнаклырак, үзенең ВАЗ-2110 машинасында йөргәли, мәсәлән, икәүләп җыйган тимер-томырны Җәлил бистәсенә илтеп тапшыралар. Таныш-белешләр операциядән соң Фаилгә авыр күтәрергә ярамаганга аның бөтен эшен Фарук эшләвен, шешә бирсп исәп-хисап ясалуын әйтәләр, мисалга 21 майда бәрәңге утыртуларын китерәләр, Әлбәттә, хәмергә хирыс ирләр еш кына бергәләп эчәләр, ошбу мәҗлесләр, гадәттә, Фарук белән Рәисәнең газ кертелмәгәнгә электр миче белән җылытыла торган уңайлыклар вә тәртип булмаган өендә уза. Кайбер күршеләр хуҗаларның еш кына кычкырышуларын әйтәләр, Фаил исә ошбу шаукымның ир белән хатынның аракы-сыраны бүлешә алмаудан чыгуын да искәртә.

25 майда каршы йортта яшәүче Галия күршеләренең кәҗәләре бик яман кычкыруына игътибар итә. Ханым моның бичара малкайлар ач булу нәтиҗәсе икәнен чамалый. Монысы ишегалдына узгач ук раслана, ә өйгә кергәч үзенчәлекле ис сизелә, коточкыч күренеш хасил була, ягъни түр яктагы караватта билгә кадәр ялангач канга баткан һәм җансыз икәнә күренеп торган Фарук ята, аның янында өнө киткән Рәисә утыра. Куркынган ханым урамга атылып чыга, авыл башлыгына хәбәр сала, Әлмәттән полиция, тикшерүче, ашыгыч ярдәм килеп җитә.

Соңгысының хаҗәте булмый. Эзләү-тикшерү төркеме җинаять урынында тиешле чаралар үткәрә, дәлилләр, шул исәптән, канга манчылган яңа күлмәк, иң мөһиме, кухня идәнендә яткан агач саплы чапкы (тяпка) алына. Шушы яшелчә турагычның җинаять коралы икәне алдан ук фаразлана, суд-медицина эксперты мәрхүм башындагы үлемгә китергән бердәнбер ярының 3 мм калынлыктагы тупас әйбер белән ясалуын белдергәч, ышаныч ныгый. Ягъни үтерүче башка шул чапкы белән суккан, дип санала. Эксперт шулай ук мәрхүмнең 22-24 май арасында үлүен дә белдерә.

Тикшерә башлау белән, әлеге срок бер тәүлеккә кыскара. Инде әйтелгәнчә, 23 майда чиста, пөхтә киенгән бабайны күрүчеләр күп була бит. Моны күршедә генә яшәүче авыл фельдшеры, бурычка бер шешә сыра алып чыгып китте, дип кибетче кыз һәм тагын берничә кеше сөйләп тора. Димәк ки, фаҗига 24 майга каршы төндә булган дигән фикер өстенлек итә. Гаҗәп, ләкин беренче мәлдә аяныч хәл гаилә низагы нәтиҗәсе дип, урын өстендәге Рәисәдән шикләнелә. Хәер, ошбу фараз бик кыска гомерле була, чөнки иренең вафаты турында хәбәр итү өчен телефонга кадәр барып җитә, тәрәзә ачып тавыш чыгара алмыйча, кимендә бер тәүлек буе мәет янында яткан карчыкны гаепләп булмый. Чапкының икенче бүлмәдә табылуы да өйдә, ким дигәндә, тагын бер кеше булуына ишарәли.

Шундый мәхшәрне кичергән авыру карчык ул чакта әлеге мәсьәләгә ачыклык кертерлек хәлдә булмый әле. Кайбер авылдашлары соңгы вакытта сөйләшүенең рәте-чираты калмады дип, аның акылдан тайпылу мөмкинлеге турында сөйлиләр. Ләкин соңрак тулы һәм эзлекле күрсәтмә биреп ошбу фикернең нигезсез икәнен раслый ул. Әлеге мәгълүматлар шактый вакыт узгач алына. Ул чакта төп шикләнелүче тотып ябылган була инде.

Аңлы рәвештә кеше үтерү очрагы буенча мәет табылган көнне үк кузгатылган җинаять эшен аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче Раил Зарипов алып бара. Фаил Яруллин шаһит буларак биргән күрсәтмәләрендә 23 майда өендә булуын, кичкә таба машинасында күрше авылда яшәүче сөйгән яры янына китүен, аннан иртә белән генә кайтуын, 24-25 майда авыл зиратында эшләвен, якын дустының үлүен полиция хезмәткәрләреннән генә белүен әйтә. Ул көннәрдә Урсалабашта булган апасы аның көндез хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүен раслый, бары тик төнлә кайчан кайтканын белмим, иртән мин йокыдан торганда өйдә иде, дип белдерә.

Ф.Яруллинның нәкъ хәвефле төндә читтә идем дип сөйләве шик уята. Бу җәһәттән, күрше авылдагы гүзәл зат белән әңгәмә корыла, билгеле. Һәм шунда ук Фаил өстендә болытлар куера башлый. Чөнки ханым 26 майда, ягъни мәет табылганның икенче көнендә үк Яруллинның шалтыратуын, каушап-кабаланып ялган сөйләргә кушуын, ягъни полиция хезмәткәрләренә 23 майда кунып калды, дип сөйләргә әйтүен җиткерә. Бактың исә, ул кичтә аларның гыйшыклы вә коньяклы очрашуы Җәлил бистәсе ягындагы урманлыкта узган, рульдәге Фаил эчмәгән, сәгать төнге 11 тулганда сөйгән ярын озатып куйгач, авылына кайтып киткән икән. Чынлыкта, фашиткеч бәян була бу, чөнки гаепсез кеше мондый алиби оештырып маташмый.

Ф.Яруллинны әлеге сөйләшү булган көнне үк тикшерү комитетының Әлмәт районы бүлегенә чакырып китерәләр. Һәм ул Ф. Галәветдиновны үтерүен танып беркетмә төзи, ошбу тәүбәле чара видеога яздырып барыла. Икенче көнне Урсалабашта ул явызлыкның ни рәвешле кылуын сөйләп һәм күрсәтеп йөри, ике тапкыр язма күрсәтмә бирә. Аларның эчтәлегенә кыскача гына тукталсак, күрше авылдан кайткач, төн уртасы якынлашканда, ул дусты Фарук янына керә, кухняда икәүләп сыйланырга керешәләр, әйтүенчә, алдан да салмыш булган хуҗа исерә, ул утырган урындыкны бәреп чыгарырга тотына, шул сәбәпле низаг куба, Фарук кулына чапкы тота, ул ошбу хәтәр әйберне тартып алып, дустының башына ора һәм җәрәхәттән гөрләп кан ага башлагач, куркып чыгып китә.

Әлеге гамәлен чапкы тоткан Фаруктан саклану чарасы итеп күрсәтергә дә тырышмыйча, өйдән чыгып качарга мөмкинлегем бар иде дип бара ул. 29 майда Әлмәт шәһәр суды аны сак астына алырга карар кыла. Суд утырышында да гаебен тануын әйтеп тора ул. Ләкин 10 көннән фикерләр үзгәрә, Ф.Яруллин алдан биргән күрсәтмәләрен, димәк, гаебен кире кага, аларны басым ясау нәтиҗәсе дип белдерә, хәтта моңа кадәр яхшы гына аңлап, сөйләшеп килгән кеше, русча белмим дип, тәрҗемәче таләп итә һәм өстәмә мәшәкать чыгара. Хокук саклау органнарында әлеге кискен борылышны килешүле, ягъни түләүле адвокат яллаудан күрәләр.

Инде яңа бәянгә тукталып үтәргә кирәк. Әйтүенчә, 23 майда ул бәрәңге утыртырга чакыру ниятеннән Фарук янына килгән, әмма ирле-хатынлыларның икесенең исереп караватта ятуын күреп кире борылган, кичкә таба безгә мәгълүм очрашуга киткән, төнге сәгать 12 нчедә өенә кайткач калган коньякны эчеп бетереп йокларга яткан, өч көннән полициягә «ташый» башлаганнар, анда ун кешелек зинданга ябу, гомерлек төрмәгә утырту белән янаганнар, ул сөйләгәннәрне ишетмичә, гаебен тануын таләп иткәннәр, бирешергә, алар кушканны үтәргә туры килгән аңа.

Яңадан сорау алулар барышында аңа ни өчен «явка с повинной» яздыгыз, шаһитлар алдында үткәрелгән тикшерү чараларында һәм суд утырышында хөкемдарга гаепсез икәнеңне әйтмәдегез, килешүле адвокат белән барлыкка килгәч кенә, күрсәтмәләрне үзгәрттегез, тәрҗемәче таләп итә башладыгыз һәм башка туры сораулар бирелә, ялган алиби уйлап чыгарырга маташу һәм башкалар искә алына. Ләкин Ф.Яруллин үзенекен сөйләвен дәвам иттерә, Фарук өендә булуын, элек чүпрәк белән канны сөртеп ташладым дигән чапкыны кулына тотуын да, башкасын да кире кага.

Аларга полиграф дип аталган ялган детекторы узарга тәкъдим ителгәч тә ризалашалар. Баш тартсалар, чөнки шик көчәячәген беләләр. Ләкин ике конвой полициясе, тәрҗемәче, адвокат белән Казанга кадәр барып уздырылган тикшеренү куелган сорауларга җавап бирә алмый. Полиграфолог Е.Рудакова моны Ф.Яруллинның тиешле кагыйдәләргә үтәмәве, тын гына утырырга тиешле адвокатның еш кына кычкырып үз фикерен белдерә башлавы һәм башка каршылыклар нәтиҗәсе булуын әйтә.

Инде яклау ягы файдасына булмаган бер күрсәтмәгә – ул вакытта өйдә булган Рәисә Денисова сөйләгәннәргә тукталып үтик. Авыру карчык түр якта ятканга, кухняда ниләр булганын күрми үзе, әмма ул төндә Фаилнең килүен, аның белән исәнләшүен, бер стакан аракы тәкъдим итүен, икенче бүлмәдә эчеп утырган ирләр арасында тавыш чыкканын ишетүен, шаукым тынгач, канлы башын тоткан иренең аның янына кереп егылуын һәм башка кузгалмыйча җан биргүен ачык итеп бирә ул. Кызганычка, судта төп шаһит булырга тиешле 1952 елгы Р.Денисова үзе дә тиздән бакыйлыкка күчә. Ире үлгәннән соң, аның янында 45 яшьлек улы Александр яши. Ләкин җәй азагында авырып китеп Рәисә әби дә дөнья куя. Тикшерү барышында һәм судта мәрхүм Ф. Галәветдиновның рәсми вәкиле булып, өлкән яшьтәге сеңлесе чыгыш ясый, абыйсын җирләүне дә ул оештыра.

Телгә алынган тоткарлыклар нәтиҗәсендә тикшерү эшләре октябрь азагында гына төгәлләнә. Әлбәттә, Ф.Яруллинга кеше үтерүдә гаепләү белдерелә. Ләкин яклау ягы бирешергә теләми, җинаять эшен присяжныйлар суды карамагына бирүне сорый, күрәсең, гади утырышчылар мәрхәмәтлелек күрсәтер дип өметләнә. Ләкин, еш кына, киресенчә килеп чыга, утырышчылар гаепле, дип белдергән затларга хөкемдар гадәттәгедән кырысрак җәза билгеләп куя.

Наил ВАХИТОВ.

ЧӘЧӘКЛЕ КИНДЕРЛӘР

Оренбург рәссамы Венера Салават кызы Әбрамованың иҗатында ихласлык күзгә ташлана! Аның гади каләм белән ясалган портретларын, майлы буяулар белән язылган диңгез пейзажларын һәм алсу чәчәкле картиналарын бик ошатып сатып алалар.

Милләттәшебез Венера Әбрамова Оренбургта яшәп иҗат итә. «Рәсем ясауга балачактан бирле тартылдым, – ди ул. – Төсле буяуларны да, графиканы да ошаттым. Берникадәр рәсемнәрне карап ясадым, күбрәк эшләрем өчен үз сюжетларымны уйлап таптым. Урта мәктәпнең V сыйныфында укыган чакта, мине шәһәребездәге сәнгать мәктәбенә бирделәр. Әмма анда нибары бер ел укыдым һәм сәнгать мәктәбеннән үзем теләп киттем. Ни өчен?! Сәбәбе исемдә дә түгел инде хәзер... Күпләрнең сәнгать мәктәбенә шундый караш формалашып алган чаклары буладыр ул. Аннары анда яңадан әйләнеп кайттым, чөнки IX сыйныфтан соң инде бары тик рәссамлыкта, иҗади һөнәрдә генә булачакмын дип ниятләп куйдым».

Хәзерге көндә Венера башка хәйран күп яшь иҗатчылар төсле үк, үз эш көнен үзе хәл итә: ул – ирекле рәссам. Жанрларга килгәндә, портретлар ясауга өстенлек бирә. Болар: гаилә портретлары да, кечкенә балалар, кызлар портретлары да... Венерага кем генә заказ бирсә дә кәгазь битендә гаҗәеп мөлаем булып килеп чыга. Рәссамның төсле пастель буяулар белән ясалган хезмәтләре дә бар һәм алар да бик нәфис эшләнештә! «Заказ биргән кешеләрнең үз портретларыннан канәгать калуларын ошатам! – ди әңгәмәдәшем. – Ә андыйлар, чыннан да, житәрлек. Рәхмәт сүзләрен ишетү җаныма илһам өсти, тагы да яхшырак, тагы да сыйфатлырак, тормыш энергиясен чагылдырырлык итеп ясарга көч бирә. Илһам бит ул һич көтмәгәндә килә. Мин аны болай дип аңлатыр идем: илһам күңелемә тын төн томаныннан арынган, чык бөртекләре белән ямьләнгән, юеш яфраклар шавы белән кушылган нурлы җәйге иртәдәй керә... Тик ясыйсы килми башлаган чаклар да була шул. Мондый сүлпән көннәрдә каләмнәремне, кыл каләмнәремне, буяуларны читкә куеп торам. Ял итәм. Гадәттә, әлеге халәт тиз уза. Ә, бәлкем, бу бездә кояшлы көннәрнең аз булуы белән дә бәйледер. Мин Оренбург өлкәсе сәнгать көллиятен тәмамладым. Белгечлегем буенча – тирә-юнь мохит дизайнеры. Көллияттә укыганда, сәгатьләр буе рәсемнәр ясап, түземлеккә өйрәнелде. Гомумән, рәссам тырыш булырга тиеш. Картина – беренче чиратта, ул – энергия чыганагы. Кешеләр картиналарны үз зәвыклары буенча сайлап ала... Соңгы елларда алсу, аксыл төсләрдәге шау чәчәкләр иҗат итү сәнгатьтә трендларның берсе булып тора. Аларны, гадәттә, кара төстәге фон белән берләштерәләр һәм мондый контраст, төсләрдәге капма-каршылык чәчәкләрнең нәфислеген тагы да ныграк ача төшә.

Чәчәкләр ясарга өйрәтү буенча осталык дәресләре күп, ләкин Венера үз юлы белән бара. Ул: «Майлы буяулар белән картиналар язуны үзлегемнән өйрәнәм», – ди. Тоташ чәчәкле картиналарының теләсә кайсы диварны бизиячәкләре күзаллана. Чәчәкләрне гадәти рәвештә, ягъни зиннәтле вазаларга куеп ясалмавы да күңелләргә хуш килерлек!

Венераның яратып сурәтләгән тагы бер темасы – сулыклар. «Диңгезләр – алар үз тирәнлекләрендәге бик күп төрле тормыш формаларындагы җан ияләре һәм ләмгә чумган борынгы байлыклары белән кызыклы... Аларда азык бәрәкәте дә бар... Диңгез-океаннар киңлек һәм ярлары күренмәүче, офык белән тоташучы чиксезлек символы булып та торалар. Алар, бик тын булып күренсә дә, барыбер даими динамикада... Шуңа күрә диңгезләрне язуга күңел биргән иҗатчылар һәркайчан булачак. Аларның даһи картиналары миңа бик ошый! Киндерләрдә диңгез халәтен, аның төс-төсмерләрен, йөгерек дулкыннарын сурәтләү теләге минем күңелемдә дә еш туа...» – ди рәссам. Венера Салават кызы холкына житдилек һәм тыйнаклык хас, әлеге сыйфатлар аркасында тәнкыйтьне дә авырсыныбрак кабул итә. Шунысы куанычлы: аның иҗатын инстаграм аша күзәтеп баручылар яшь рәссамга мактау сүзләре генә юллый!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 14.01.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2700 данә

Заказ 2790

16+